ТРның Министрлар Кабинеты

ТР Дәүләт Советының
Мәдәният, фән, мәгариф һәм
милли мәсьәләләр комитеты

Казан дәүләт архитектура-
төзелеш университеты

Кабинет Министров РТ

Комитет Государственного Совета
РТ по культуре, науке, образова-
нию и национальным вопросам

Казанский государственный
архитектурно-строительный
университет

ЮГАРЫҺӨНӘРИ БЕЛЕМ БИРҮ СИСТЕМАСЫНДА ИКЕТЕЛЛЕЛЕК: ФӘННӘРНЕ ТАТАРЧА УКЫТУ

Республика фәнни-гамәли конференциясе материаллары

ДВУЯЗЫЧИЕ В СИСТЕМЕ ВЫСШЕГО ПРОФЕССИОНАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ: ПРЕПОДАВАНИЕ ДИСЦИПЛИН НА ТАТАРСКОМ ЯЗЫКЕ

Материалы Республиканской научно-практической конференции

Казан
Казань
2006

УДК 378.016 (470.41)
ББК 74.58 (2Рос. Тат.)
Ю15

Ю15 **Югары һөнәри белем бирү системасында икетеллелек: фәннәрне татарча укыту** / Республика фәнни-гамәли конференциясе материаллары. – Казан: ООО «Центр Оперативной Печати», 2006. – 96 б. = **Двуязычие в системе высшего профессионального образования: преподавание дисциплин на татарском языке** / Материалы Республиканской научно-практической конференции. – Казань: ООО «Центр Оперативной Печати», 2006. – 96 с.

ISBN 5-94541-045-4

Бу җыентыкта «Югары һөнәри белем бирү системасында икетеллелек: фәннәрне татарча укыту» дип аталган Республика фәнни-гамәли конференциясендә катнашучыларның доклад тезислары басыла. Конференция Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетында ТРның ике дәүләт телендә эш алып барырлык төзүче инженерлар укыта башлауның 15 еллыгына һәм татар телендә югары техник белем бирүне оештыручы профессор Вагыйз Фәтхуллинның якты истәлегенә багышлана.

В сборнике публикуются тезисы докладов участников Республиканской научно-практической конференции «Двуязычие в системе высшего профессионального образования: преподавание дисциплин на татарском языке». Конференция посвящается 15-летию подготовки в Казанском государственном архитектурно-строительном университете инженеров-строителей, профессионально владеющих двумя государственными языками РТ и светлой памяти организатора обучения технических дисциплин на татарском языке профессора В.Ш. Фатхуллина.

УДК 378.016 (470.41)
ББК 74.58 (2Рос. Тат.)

ISBN 5-94541-045-4

© КГАСУ, 2006

Дөньяда күп нәрсә белдем
син туган тел аркылы.

Габдулла Тукай.

ТАТАРЧА ЮГАРЫ ТЕХНИК БЕЛЕМ БИРҮ УЧАГЫ

Р.Ә. Шакирҗанов
(Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты)

Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетында (КДАТУда) татар телендә укыта башлауга быел 15 ел тула. Үз вакытында Казан дәүләт төзүче инженерлар институты дип аталган бу югары уку йорты әлеге эшчәнлеген республикабыздагы техник югары уку йортлары арасында беренче булып һәм зур оешканлык белән башлап җибәрде. Тарихка әйләнеп караганда, моның шактый тирән тамырлары бар икән.

Төзелеш фәннәрен татарча укыту иң тәүдә «Татар телен гамәлгә кертү» законы нигезендә Казандагы политехник институтның төзелеш факультетында 1922 елны башлана. Шул елларда милли мәктәпләрне тәмамлаучыларга һәр яктан ярдәм күрсәтелә башлый, абитуриентлар имтиханнарны татарча бирәләр, күп кенә фәннәр (математика, физика, төзелеш материаллары һ.б.) татарча укытыла.

1930 елны Казан коммуналь төзелеш институты ачылгач, татарча укыту киңрәк җәелеп китә. Төзелеш факультетының бер төркемендә (10нчы группа) дәресләр татарча алып барыла, татарча укыту буенча методик кабинет ачыла, геодезия, теоретик механика, физика, югары математика, төзелеш материаллары буенча татарча дәреслекләр языла. Укыту процессын оештыруга татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире доцент Вәли Хангилдин, архитектура кафедрасы доценты Фәтхелислам Хәкимов, геодезия кафедрасы доценты Зәкүан Богданов, теоретик механика кафедрасы доценты Хәмит Мөштәри, төзелеш конструкцияләре кафедрасы доценты Ибраһим Сафин һ.б. зур өлеш кертәләр. Репрессия еллары җитеп, интеллигенция вәкилләре кулга алына һәм юк ителә башлангач кына бу эшчәнлек туктап кала.

1990 елны Казан дәүләт төзелеш институтында төзүчеләрне татарча укытуның яңа этабы, яңарышы башланды. Бу хәлнең

сәбәпләре илдә вазгыять үзгәрү, чын демократия җилләре исә башлау, халкыбызның мөстәкыйль яшәү турындагы күптәнге хыялы тернәкләнеп китү, милли белем бирү системасын төзү идеясе яңару белән генә түгел, институтта студентларның составы (55%-тан артыгы татарлар, шактые татар мәктәпләрен тәмамлаган булу) белән дә билгеләнә. Шунысы да кызыклы – халкыбызның фидакяр уллары күп еллар элек башлап җибәргән эшнең чаткылары нәкъ менә төзүчеләр институтында сакланып калган була. Шуңа күрә ул биредә тиз арада дөрләп, ялкынланып китә дә.

Татарча укытуны оештыру эшләре 1991 елны башланды. Март аенда укытучыларның гомуми җыелышы булды, эшчәнлекнең төп юнәлешләре билгеләнде, татар телен тирәнрәк өйрәнү өчен курслар оештырылды, методик һәм терминологик комиссияләр төзелде.

Укытуга әзерлек студентларны җентекләп сайлап алудан башланды. Кабул итү имтиханнары өчен алдан ук татарча билетлар әзерләнде. Татарча уку өчен гариза биргән 78 абитуриент арасыннан төзелеш факультетының беренче курсына ике төркем (барлыгы 42 студент) кабул ителде. Шуннан башлап ел да ике төркем кабул ителә.

Һичшиксез, һәр эшнең үз әйдаманы, лидеры булырга тиеш. Төзелеш институтында татарча укытуның инициаторы һәм җитәкчесе – төзелеш факультеты деканы профессор В.Ш. Фәтхуллин булды. Бу эшкә тулысынча бирелгән, җигелеп эшләүче галимнәр аңа зур терәк булдылар. Вагыйз Шәйхулла улы күп еллар ТР Фәннәр академиясе гуманитар бүлегенең «Югары уку йортларында фәннәрне татарча укыту» фәнни-методик советы рәисе иде. Аның җитәкчелегендә методик һәм нәшер итү советлары, терминологик комиссия һәм методик кабинет эшләде.

Университет җитәкчелеге – шәхсән ректор Валерий Николаевич Куприянов һәм укыту эшләре буенча беренче проректор Владимир Николаевич Сучков бу эшләрнең мөһимлеген аңлап, һәрдаим ярдәм итеп тордылар.

Булган мөмкинлекләрне исәпкә алганнан соң, бездә татарча укыту эше Татарстан Республикасының ике дәүләт телен (татар һәм рус телләрен) камил белгән төзүче инженерлар хәзерләү лозунгы астында бара башлады. Шуңа күрә безнең студентлар иялэшү чорында (1-2 курсларда) башлыча татар телендә укысалар да, төрле фәннәрнең русча терминнары белән дә танышып баралар. 3-4 курсларда укыту акрынлап русчага күчә. Ә 5нче курста уку, дәүләт

имтиханнарын бирү, диплом яклау рус телендә алып барыла.

1996 елда татарча укучыларның беренче чыгарылышы (17 кеше) булды, ә 2005 елда – унынчы чыгарылыш (20 кеше) булды. Гомумән алганда, 1991-2005 еллар эчендә Татарстан Республикасының ике дәүләт телен дә һөнәри дәрәҗәдә куллана торган югары белемле 177 төзүче инженер әзерләнде. Шуларның алтысы аспирантурада укыдылар, ә өчесе (Хәсәнов Р.Р., Сибгатуллин М.Т. һәм Сафин Д.Р.) кандидатлык диссертацияләрен якладылар. Бүген алар университетның төрле кафедраларында укыталар.

2004-05 елларда университетта барлыгы 124 студент татар төркемнәрендә укыды. Төзүче инженерлар әзерләүнең уку планына кергән 77 фәннең 23е татар телендә укытыла. Алар буенча 24 укытучы лекцияләр укый, гамәли дәресләр алып бара, курс эшләрен һәм проектларын җитәкли. Төп фәннәр буенча лекцияләрне профессорлар: Камалов А.З. (теоретик механика), Миңнуллин С.М. (сызма геометрия), Мөхәммәтшин Р.М. (философия), Туктамышов Н.К. (югары математика); доцентлар: Гыйлаҗев Д.Г. (җылылык, газ белән тәэмин итү һәм җилләтү), Җаббаров А.Н. (су белән тәэмин итү), Заһидуллин Э.Х. (төзү машиналары), Зәкиев М.И. (югары математика), Ибәтов Р.И. (гамәли математика), Камалова З.А. (төзелеш материаллары), Кафиатуллина В.И. (немец һәм инглиз телләре), Миңнеханов Ф.Г. (тарих һәм культурология), Муратов Л.М. (югары математика), Мортазин Н.З. (физика), Низамиев В.Г. (материаллар каршылыгы), Сөләйманов А.М. (төзелеш материаллары), Порфирьева Р.Т. (химия), Урмитова Н.С. (су белән тәэмин итү), Шакирҗанов Р.Ә. (корылма механикасы) һ.б. алып бара.

Төзелеш университетында татар телендә укыту буенча методик кабинет актив эшли. Аны күп еллар доцент Альберт Нарбеков җитәкләде. 2003 елдан кабинетны доцент Рәшит Шакирҗанов җитәкли. Методик кабинетның эшчәнлеге татарча укытыла торган фәннәр буенча укыту-методик документация әзерләү, дәреслекләр язу, методик кулланмалар һәм сүзлекләр төзүгә юнәлгән. Мәсәлән, 2004 елда «Мәгариф» нәшриятында безнең университет галимнәре катнашында 2 академик сүзлек, КДАТУның үзендә 3 уку кулланмасы, 8 методик кулланма нәшер ителде. Гомумән алганда, 1991-2005 елларда 138 исемдәге, күләме 807 басма табактан артык укыту-методик әдәбият (алар арасында 6 дәреслек, 35 уку кулланмасы, 17 терминологик сүзлек бар) нәшер ителде, табигать,

техник һәм кайбер махсус фәннәр буенча 25 программа һәм методик комплекс эшләнде.

КДАТУда күп еллар техник фәннәр буенча терминологик комиссия эшләп килде. Казанның төрле уку йортлары мөгаллимнәре катнашында татар телендә югары белем бирү өчен кирәкле терминнар туплау эшен ул бүген дә алып бара.

Бездә «Югары мәктәптә фәннәрне татарча укыту» дигән тема буенча фәнни-методик эш тә алып барыла. Университетның ел саен үтә торган фәнни конференциясендә бу тема буенча фәнни-методик секция эшли, анда татар телендә укытучы мөгаллимнәрнең фәнни һәм фәнни-методик эзләнү нәтиҗәләре, методик хезмәтләре тикшерелә. Алар төрле җыентыкларда, «Фән һәм тел» журналында бастыру өчен тәкъдим ителәләр. Кайбер тикшеренү нәтиҗәләре ТР Фәннәр академиясенең грантларына лаек булдылар. Галимнәребез Министрлар Кабинеты заказы буенча «Татар телендә югары белем бирү концепциясе»н төзеделәр (авторлары Фәтхуллин В.Ш., Шакирҗанов Р.Ә., Нарбеков А.И.), ул төрле форумнарда һәм киңәшмәләрдә хупланды. Югары математика кафедрасы профессоры Туктамышов Н.К. тарафыннан «Билингвизм шартларында югары техник мәктәпләрдә укытуның социаль-педагогик нигезләре» дигән монография дә зур бәя алды.

Университетыбыз галимнәре татарча укыту өчен укыту-методик әдәбият булдыру өстендә дә зур эш башкаралар. Югары мәктәпләр өчен язылган дәреслекләр – Садрислам Миңнуллинның «Сызма геометрия», Абрик Камаловның «Теоретик механика», Галим Хисамиевнең «Гомуми химия», Расих Сәлимов һәм Наил Туктамышовларның «Математика» дәреслекләре һ.б. Татарстанның югары уку йортларында татарча укыту өчен күп еллар кулланыла.

Бездә терминология, сүзлекләр төзү өлкәсендә дә зур эш алып барыла. Моңа мисал итеп Рәшит Шакирҗановның «Русча-татарча төзелеш атамалары сүзлеге»н һәм «Төзүчеләр өчен русча-татарча сүзлекчә»сен, Алмаз Юлдашев, Әнәс Әфләтонов һ.б.ларның «Русча-татарча техник терминнар сүзлеге»н, Галим Хисамиев, Альберт Нарбеков һ.б.ларның «Химиядән русча-татарча аңлатмалы сүзлеге»н, Фәрит Хәкимҗанов, Рәшит Шакирҗанов һ.б.ларның «Русча-татарча нефть сәнәгате сүзлеге»н, башка сүзлекләрне атарга мөмкин.

Татар телендә нәшер ителә торган фәнни-хәбәри «Фән һәм тел»

журналын чыгаруның инициаторлары һәм башкаручылары да КДАТУ галимнәре. Казан шәһәре администрациясе, ТР Фәннәр академиясе, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты һәм Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты журналны оештыручы булып торалар, соңгысы журналның редакциясен дә үз канаты астына алды. «Фән һәм тел» журналы фәнни тикшеренүләр алып баруга, татар теленең фәнни терминологиясен һәм фәнни стилен үстерүгә, татар телендә югары белем бирү системасын төзүгә, табигый-техник һәм гуманитар фәннәр өлкәсендә эшләүчеләрне берләштерүгә булышлык итүне үзенең төп максатлары итеп куя.

Йомгаклап шуны әйтергә мөмкин: Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты һәм аның галимнәре татар телендә югары техник белем бирү өлкәсендә әйдәп баручы булып торалар, күп еллар дәвамында бу юнәлештә зур эш башкардылар, төрле кыенлыклар туута да карамастан аны бүген дә уңышлы дәвам итәләр.

ТАТАР МӘГЪРИФӘТЧЕСЕ ВАГЫЙЗ ФӘТХУЛЛИН

А.И. Нарбеков
(«Фән һәм тел» журналы редакциясе)

Соңгы елларда башкарылган олы эшләрнең күбесе, әлбәттә, 1990 елның 30 августында кабул ителгән «Татарстан ССРның дәүләт мөстәкыйльлеге турында декларация»дән башланып китә. Шул ук елның көзендә Казан төзелеш инженерлары институтының төзелеш факультеты деканы Вагыйз Фәтхуллин, бер төркем татар мөгаллимнәрен җыеп, болай дигән иде: «Татар теленә чын-чынлап дәүләт теле статусы бирергә уйлыйбыз икән, без мәктәпкәчә тәрбияне дә, урта белем бирүне дә, югары белемле белгечләр хәзерләүне дә ана телендә алып барырга тиешбез. Шунысын да ассызыклап әйтергә кирәк: шушы изге эшнең төп өлешен бүген, безнең буын үтәп чыга алмаса, алдагы елларда бербөтен татар мәгариф системасын төзеп булмас». Һәм 1991 елда ул төзелеш факультетында татар төркемнәре оештыра, төгәл һәм техник фәннәр татар телендә дә укытыла башлый, ягъни Татарстанның ике дәүләт телендә дә эш алып барырлык белгечләр хәзерләнә.

Татар мәгарифе өлкәсендә яңа юнәлеш ачып җибәргән бу олы шәхеснең тормыш юлына күз салсак, аның гел белемгә, яңалыкка

омтылганын күрәбез.

Вагыйз Шәйхулла улы Фәтхуллин Азнакай районы Мәсгут авылында 1937 елда туа. Шунда җидееллык мәктәпне, аннан соң Әлмәт шәһәренең 1нче урта мәктәбен тәмамлагач, Башкортстанның Октябрьск шәһәрендәге нефть техникумының төзелеш бүлегендә укый. Ике ел хәрби хезмәттә булып кайткач, 1964 елда Казан төзүче инженерлар институтын тәмамлый һәм төзелеш конструкцияләре кафедрасында укыта башлый. 1973 елда Ленинградта җыелма-монолит конструкцияләрнең ныклыгын өйрәнүгә багышланган кандидатлык диссертациясен яклый. 1979 елда Вагыйз Фәтхуллинга доцент, 1994 елда профессор дигән гыйльми дәрәҗәләр бирелә. 1980-83 елларда, югары белемле мөгаллим буларак, Алжирның Аннаба университетында укыта. 1984-2005 елларда – төзүче инженерлар институтының (хәзер архитектура-төзелеш университеты) төзү факультеты деканы.

Вагыйз Шәйхулла улының туган телебезне саклау-үстерү буенча алып барган күпкырлы эше аеруча игътибарга лаек. Аның җитәкчелегендә «Татар телендә югары белем бирү концепциясе» төзелә. Ул – Татарстан Министрлар Кабинеты каршындагы «Татарстан телләре турында»гы Законны гамәлгә ашыру комитеты әгъзасы, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының Фән һәм мәгариф буенча комиссия рәисе, Татарстандагы югары уку йортларның ректорлар советы каршындагы татарча укыту буенча фәнни-методик үзәкнең рәис урынбасары, Татарстан Фәннәр академиясе Гуманитар бүлегенең «Югары уку йортларында фәннәрне татар телендә укыту» буенча гыйльми-методик советы рәисе буларак та зур һәм нәтиҗәле эш алып барды. «Фән һәм тел» журналын аякка бастыручыларның берсе иде.

В.Ш.Фәтхуллинның фән һәм укыту өлкәсендәге уңышлы эшчәнлеге «Татарстан Республикасының атказанган фән һәм техника эшлеклесе» исеме, «Югары белем бирү өлкәсендә уңышлары өчен» билгесе һ.б. дәрәҗәле бүләкләр белән билгеләнде.

Инде бүген, ул башлап җибәргән эшкә 15 ел тулуны билгеләп, аның якты истәлегенә багышлап үткәрелгән бу конференция дә – халкыбыз өчен янып йөргән, ачык йөзле, сабыр холыклы, акыллы сүзле татар мәгърифәтчесе Вагыйз Шәйхулла улы Фәтхуллинга бер бүләк булсын.

ТУГАН ТЕЛНЕ САКЛАУ ҺӘМ ҮСТЕРҮНЕҢ ӘҺӘМИЯТЛЕ ЮНӘЛЕШЕ

М.З. Зәкиев
(Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты)

XX гасырның 90нчы елларында милләтне тергезү, саклау һәм үстерү дигән әһәмиятле проблема татарлар арасында да урнашып ныгый башлады. Дәүләт башында тормый торган милләтләрнең яшәү-үлем проблемаларына карый торган бу мәсьәлә безгә Евросоюз идеяләре буларак килеп керде.

Мәгълүм булганча, Икенче бөтендөнья сугышыннан соң капиталистик илләрдә дәүләт башында торган милләтләр бөтен уңайлыкларны үзләренә генә алу сәясәтен үткәрделәр, дәүләт башында тормаган ваграк милләтләр әкренләп бетүгә, ассимиляцияләнүгә дучар ителгәннәр иде. Менә бу хәл 60нчы елларда “вак халыкларның эре милләтчелеге” дигән иҗтимагый хәрәкәтне тудырды: вак милләтләр, үз хокукларын яклап, көрәшкә чыктылар. Бөек Британиядә төньяк ирландлылар, Бельгиядә – фламандлар һәм валлоннар, Испаниядә – басклар һәм каталоннар, Франциядә – корсикалылар һәм бретоннар, Канадада – квебеклылар, әгәр безнеке кебек милләтләргә үсү өчен шартлар тудырылмаса, без бу илләрдән аерылып чыгачакбыз, үзебезгә аерым суверен дәүләт төзиячәкбез, дип күтәрелделәр.

Бу хәрәкәт Евросоюзга да тынгысызлык китерде, һәм Евросоюз әкренләп вак милләтләрне саклау һәм үстерү сәясәтен эшли башлады. 90нчы еллар башында аның беренче халыкара документлары дөнья күрде. Россиядә дә, Татарстанда да вак милләтләрне һәм милли телләрне саклау, үстерүне оештыру эшләре актив рәвештә хәл ителә башлады.

Евросоюзның региональ телләр турындагы хартиясенең беренче проектлары белән танышкач, Телләр турындагы Татарстан законы кабул ителгәч (1992), татар телен куллану сфераларын киңәйтү эше башланды. Иң элек татарларның үз араларында ана телен куллана алырлык кешеләрне арттырырга кирәк иде. Бу эш үзе күп юнәлешләр буенча алып барылды. Икенчедән, Татарстандагы рус телледәргә татар телен өйрәтү бурычы алга куелды.

Рус телледәрне татарчага өйрәтү Татарстандагы рус мәктәпләрендә алып барыла, аерым оешмаларда татарчага өйрәтү

түгәрәкләре дә эшли. Рус мәктәпләрендә төрле фәннәрне татарча укыту проблемасы алда тормый.

Татарстанның махсус урта белем бирү йортларында һәм вузларында рус телледәргә татар телен өйрәтү ике юнәлештә алып барыла: 1) телне өйрәтү өчен татар теле дәресләре кертү, 2) телне гамәли куллануны тәэмин итү өчен фәннәрне татар телендә укыту.

Рус телледәргә татар телен өйрәтүнең тулы бер системасы барлыкка килде. Башта Казан дәүләт университетында, соңрак Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетында татар телен башка телледәргә өйрәтү кафедралары оештырылды. Күп кенә башка вузларда рус телледәргә татар телен өйрәтүчеләр чит тел кафедраларына кабул ителә тордылар.

Вузлар системасында татар телен гамәли үзләштерүгә юнәлтелгән, төрле предметларны студентларга татарча укыту эше вузлар өчен, андагы татар доцентлары һәм профессорлары өчен гаять катлаулы мәшәкать булып чыкты. Әйтергә кирәк: Казан дәүләт педагогика институтында (хәзерге Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты) аерым төркем студентларга төрле фәннәрне татарча укыту 1920нче еллардан хәзерге көнгә кадәр дәвам итеп килде. Бурыч – бу эшне башка вузларга да кертүдән гыйбарәт булды.

Төрле фәннәрне татарча укытырга әзер торган инициативалы галимнәр беренче булып Казан дәүләт төзелеш институтында күренделәр. Бу катлаулы, ләкин милләтне саклауга юнәлдерелгән изге эшне төзелеш факультеты деканы профессор Вагыйз Шәйхулла улы Фәтхуллин башлап җибәрде. Бик озак еллар ул Татарстан фәннәр академиясенең гуманитар бүлегендә бу эшләрне координацияләү советының рәисе дә булды, Министрлар кабинеты каршында телләр законын гамәлгә ашыру комитетының актив әгъзасы да иде.

Архитектура-төзелеш академиясе белән параллель, яки аннан үрнәк алып, Авыл хуҗалыгы академиясендә, Ветеринария-медицина академиясендә, Техник университетта, Технологик университетта, Дәүләт университетында, Медицина университетында, Мәдәният-сәнгать университетында һәм башка вузларда төрле фәннәрне аерым төркем студентларга татарча укыту очраклары әкренләп гадәткә кереп китте. Һәр вузда бу эшнең осталары үсеп чыкты.

Вузларда аерым фәннәрне татарча укытуның татар әдәби

телен үстерүгә тагын да уңайрак тәэсир итә торган ягы ачылып китте: бу – студентлар өчен татарча кулланмалар һәм дәреслекләр төзү һәм бастыру. Табигый, техник һәм гуманитар фәннәрдән мәктәп дәреслекләре төзү яисә аларны русчадан татарчага тәрҗемә итү эшенең татарларда тукталганы юк иде. Ләкин вузлар өчен бу фәннәрдән татарча дәреслекләр төзү татар телен, бигрәк тә аның терминологиясен үстерүгә югары дәрәҗәле өлешен кертә башлады. Төрле фәннәрдән җентекле русча-татарча һәм аңлатмалы терминологик сүзлекләр төзү тормыш таләбенә әйләнде. Алар да берсе артыннан берсе чыга тордылар. Без Ветеринария-медицина академиясендә һәм Медицина университетында мондый сүзлекләрне җәмәгатьчелеккә тәкъдим итүнең шаһитларыы булдык.

Төрле фәннәр буенча вуз дәреслекләрен чыгаруга мин үзем Фәннәр академиясендәге гуманитар бүлек академик-сәркатибе буларак мөмкин кадәр ярдәм итәргә, бүлек акчасыннан аларны финансларга тырыштым.

Вузларда төрле фәннәрне татарча укытуның олы тәҗрибәсен гомумиләштереп, докторлык диссертациясен язып яклаган галим дә Архитектура-төзелеш академиясеннән иде. Бу очракта сүз хәзер инде доктор, профессор Наил Туктамышов турында бара.

Югары уку йортларында табигый, техник һәм гуманитар фәннәрне студентларга татарча укыту, техник һәм табигый фәннәрдән гыйльми эшләр нәтиҗәсен татарча гомумиләштерү, татарча укыту гамәлләрен реальләштерүдә бик зур роль уйнаган “Фән һәм тел” журналын оештырып чыгаручыларга да бүген җәмәгатьчелекнең зур рәхмәтен җиткерергә телибез. Бу очракта без ул журналның баш редакторы Фаил Әхмәдиев, баш редактор урынбасары Рәшит Шакирҗанов, җаваплы сәркатип Альберт Нарбеков, редакторлардан Абрик Камалов, Галим Хисамиевләрнең исемнәрен мактап телгә алырга тиешбез.

Әле генә саналган мактаулы эшләрне башкарырга, бүгенге конференцияне үткәрергә барлык мөмкинлекләрне дә булдырган өчен Архитектура-төзелеш академиясе ректоры профессор Куприянов Валерий Николаевичка татар җәмәгатьчелегенең олы рәхмәтен җиткерүне дә үзебезнең бурычыбыз дип санайбыз.

Бүген конференциядә уртага куеп сөйләшә торган проблемалар буенча шактый гына эшләр башкарылса да, әле

кимчелекләр дә һәм тормышның яңа таләпләре дә күп. Безнең бу конференция шул кимчелекләрне бетерүнең, яңа таләпләрне тормышка ашыруда яңа юнәлешләрне билгеләүнең яңа бер баскычы булыр дип ышанасы килә.

ЦЕЛИ ДВУЯЗЫЧНОГО ОБРАЗОВАНИЯ В СОВРЕМЕННЫХ УСЛОВИЯХ ТАТАРСТАНА

Н.К. Туктамышов
(Казанский государственный архитектурно-строительный университет)

Высшая школа решает три основные задачи: 1) подготовка элиты общества, т.е небольшого количества людей, которые со временем будут принимать стратегические решения в различных областях; 2) массовая подготовка специалистов, которая состоит в передаче профессиональных стандартов большому количеству людей; 3) сохранение и передача « «генетического кода» общества, под которым понимается передача поколениям моральных, этических норм, языка, образов, принятых в обществе.

Основной приоритет в развитии высшей школы сегодня – соответствие содержания обучения и его уровня технологическим, экономическим, социальным проблемам, которые будет решать наша цивилизация в 21 веке.

Здесь нужно отметить два обстоятельства: 1) отсутствие реальных и соответствующих финансовых вливаний в систему образования. В настоящее время, по оценкам экспертов, 75-85% работников высшей школы живут за чертой бедности. Россия имеет систему образования, которая на протяжении последних 15 лет финансируется на одну треть от потребностей; 2) существуют противоречия между сторонниками концепции государственной ответственности за образование и сторонниками либеральной концепции.

Эти два фактора привели к тому, что отсутствует внятная общенациональная концепция образования с ясно обозначенными целями и задачами. Присоединение к Болонскому процессу не упрощает задачу реформирования системы образования, а делает решение ее еще более сложной. Внешние интеграционные образовательные процессы должны проходить на фоне понимания

важности качественного образования и с учетом многоязычия ее населения. В связи с этим перед системой высшего образования встает фундаментальный вопрос о соотношении между местным и глобальными ценностями, создании сбалансированной общекультурной миссии вуза с функцией достаточной прикладной специализации. В статье 10 «Всемирной декларации о высшем образовании для 21 века» подчеркивается необходимость усиления внимания к конкретным национальным и региональным условиям с тем, чтобы учитывать многообразие и избегать унификации высшего образования, а также актуальность требования международного измерения высшего образования как одной из неотъемлемых характеристик современного качества.

Один из способов вписаться в мировые тенденции развития образования, связанных с интернационализацией жизни народов – это переход к билингвальному (полилингвальному) обучению.

Успешность реализации билингвального образования зависит во многом от языковой политики государства. Вместе с тем, не возникает ясности в понимании стратегических языковых целей (от этого зависит выбор вида двуязычия): идет ли речь о полной и равной языковой компетентности или о чем-то другом. Татарский язык отличен от основного языка обучения, но ему уделяется специфическое внимание, он является даже языком обучения, однако подчиненным главному (русскому) языку; создавая систему двуязычного образования государство должно ясно сформулировать свою цель. Необходима отдельная государственная программа (не в рамках программы развития языков РТ) функционирования двуязычия в системе образования; нет ясности и в определении того, какое место должно занимать двуязычное обучение в рамках системы образования РТ. Пока оно очень мало. Так, в КГАСУ выпускников с двуязычным обучением около 20 человек в год, а моноязычных около 400, хотя выпускников национальных общеобразовательных школ Татарстана 47%.

Определение целей билингвального образования представляет собой сложную задачу, включающую в себя: овладение предметным знанием на двух языках; формирование у обучаемых знаний о сущности культуры как интегрирующего социально-исторического феномена; формирование у студентов знаний о гражданско-правовых, исторических, этнических особенностях, этнической дифференциации и глобализации человечества; воспитание

культуры речи, межнационального общения, толерантности.

Кроме того, требуется глубокий анализ социокультурного уровня обучения, социолингвистических аспектов, оценки языковых целей и т.д.

Реализация вузовского двуязычия основана на школьном образовании, которое находится сейчас в состоянии ценностного разоружения. Татарское национальное возрождение может и должно идти через создание престижных учебных заведений (гимназий, лицеев и т.д.), в которых обучение ведется на двуязычной основе (татарском, английском).

Для достижения отмеченных целей необходимо создание научной лаборатории при Академии наук Татарстана по комплексному изучению проблем двуязычия (не только татарско-русского). Кроме того, она могла бы участвовать в разработке, рецензировании, в выпуске дидактической литературы; в оценке учебных результатов; в подготовке и переподготовке соответствующих кадров.

ЮГАРЫ УКУ ЙОРТЛАРЫНДА ТАТАР ТЕЛЕНДӘ УКЫТУ ПРОБЛЕМАЛАРЫ

Д.Г. Галимов, Г.Ю. Даутов, Б.А. Тимеркәев
(Казан дәүләт техника университеты)

Казан дәүләт техника университетында инде 10 ел дәвамында ике белгечлек – «Физика» һәм «Физик электроника» буенча студентларга татар телендә белем бирелә. Бу студентларга төп фәннәр: механика, молекуляр физика, термодинамика, электродинамика, оптика, квант механикасы, каты җисем физикасы, атом төше физикасы, линеаль алгебра, аналитик геометрия, математик анализ, дифференциаль тигезләмәләр, электротехника фәннәре беренче һәм икенче курсларда татар телендә укытыла. Өченче курстан башлап укыту барлык фәннәр буенча да рус телендә алып барыла. Бүгенге көнгә югарыда санап узылган барлык фәннәр өчен татар телендәге дәреслекләр бар. Башлыча алар Казан дәүләт техника университеты профессорлары Г.М. Мөбәрәкҗанов, Д.Г. Галимов, Г.Ю. Даутов, Б.А. Тимеркәев, Ч.И. Мастюков авторлыгында язылганнар һәм «Мәгариф», «Казан

дәүләт техника университеты» нәшриятләрендә нәшер ителгәннәр.

Югары уку йортларында татар телендә белем бирү юнәлешендәге төп проблемаларның берсе – студентларның татар телен камил белмәү проблемасы. Бер үк төркемгә татар мәктәбендә фәннәрне татар телендә өйрәнгән укучылар да һәм, шул ук вакытта, рус телендә өйрәнгән укучылар да эләгә. Соңгыларына яңадан татар телендәге фәнни терминнарга күнегү, татар телендә фикерләүгә күчү беркадәр көч куюны таләп итә. Шуңа да карамастан, студентлар татар телендә бик теләп укыйлар һәм яхшы гына уңышларга ирешәләр.

Икенче проблема – татар телендә алган белемнәрне киләчәктә куллану. Бүгенге көндә татар телендә белем алган белгечләр бары тик авыллар өчен генә кирәк, ә андый белгечлекләрнең яшьләр арасында популярлыгы бик үк югары түгел.

Татар телендә укытуның төп максаты нидән гыйбарәт соң? Татар мәктәбен тәмамлаган балаларга туган телендә югары белем алу мөмкинлеге тудырудамы, яки Татарстан Республикасы өчен кирәк булган ике дәүләт телен дә камил белгән белгечләр әзерләүдәме? Бәлки болар икесе дә төп максаттыр. Тик хәзергә татар телле белгечләргә Татарстанда аерым шартлар тудырылмаган. Күрәсең, Министрлар Кабинеты республика өчен кирәк булган һәм ике телне дә камил белгән белгечлекләрнең исемлеген төзеп, югары уку йортларына мондый белгечлекләргә заказ бирергә тиештер. Бу эш татар телендә укытуны тагын да җанландырып җибәрер иде.

МИЛЛИ-РЕГИОНАЛЬ КОМПОНЕНТ – ДӘҮЛӘТИ ПРИНЦИП

Р.Ә. Вәлиев

(Кама дәүләт инженер-икътисад академиясе)

Белемгә хокук – Россия Федерациясе гражданнарының төп конституцион хокукларының берсе. Бу хокук «Мәгариф турында» федераль закон ярдәмендә тормышка ашырыла. Әлеге Закон аша мәгариф өлкәсендә дәүләт политикасының биш принцибы игълан ителә. Шуларның берсе – күпмилләтле дәүләт шартларында милли мәдәниятне һәм үзенчәлекләрне мәгариф системасы ярдәмендә

яклау һәм үстерү.

Объектив сәбәпләр аркасында федераль үзәк бу принципны турыдан-туры үзе тормышка ашыра алмый. Федерация составындагы көчле милләтләр үз милли мәгарифе өчен үзе кайгырырга тиеш. Дәүләтчелеге булмаган милләтләр өчен генә үзәк үзен җаваплы саный.

Татарстан өчен исә мәгарифтә бу төп принцип булырга тиеш. Ягъни республика федераль үзәкнең мәгариф өлкәсендәге милли политикасын уздыручы гына түгел (андый политика юк та бит әле ул), татар милләте өчен шундый политиканы булдыручы һәм оештыручы да булырга тиеш. Игътибар итик, бу республиканың хокукы гына түгел, бу аңа үзәк тарафыннан үз ихтыяры белән тапшырылган дәүләт бурычы. Әлбәттә, бу бурычның үтәлүен Мәскәү тикшермәячәк (сәбәпләре аңлашыла), нәтиҗәдә субъектның дәүләт һәм хөкүмәт органнарына моны үтәмәсә дә була. Һәм бу шулай килеп чыга да.

Шул ук федераль Законның 3нче маддәсендә федерация субъектлары мәгариф өлкәсенә кагылышлы үз законнарын һәм норматив актларын кабул итә ала дип язылган, ә 29нчы маддәсе нигезендә исә субъектның вәкаләтләренә мәгарифне үстерү буенча милли-мәдәни үзенчәлекләрне исәпкә алган республика программасын эшләү һәм тормышка ашыру керә. Шулай итеп, федерация республикага мәгариф өлкәсендә аерым бер вәкаләтләр бирә. Безне кызыксындырган төп ике юнәлешне карыйк.

Беренче юнәлеш – югары мәктәптә татар телендә укыту. «Мәгариф турында» законның 6нчы маддәсендә Россия гражданнары мәгариф системасы биргән мөмкинлекләр кысасында уку телен сайлап алырга хокуклы дип язылган. Моны тәэмин итү өчен кирәкле дәрәҗәдә махсус уку йортлары яки группалар оештырылырга, һәм алар өчен аерым шартлар тудырылырга тиеш дип тә өстәлгән (сүз уңаеннан, юридик яктан мәсьәлә бик гади хәл ителә: укыту-тәрбия теле уку йортының уставына язылырга тиеш).

Кызганычка каршы, бүген татарстанлыларның – Россия Федерациясе гражданнарының – бу хокуклары тормышка ашу өчен шартлар тудырылмаган, һәм шушы көнгә кадәр республиканың рәсми органнарында бу өлкәдә салкын битарафлык күзәтелә.

Законның шул ук 6 маддәсе нигезендә Россия Федерациясе халыклары телләрендә укыту өчен белгечләр әзерләүне федераль

үзәк үз өстенә тик бер очракта ала – бу халыкның дәүләтчелеге булмаса гына. Татарстан дәүләте бар икән, димәк, татар телендә укыту – аның үз бурычы.

Икенче юнәлеш – югары мәктәптә татар телен һәм мәдәниятен өйрәнү. Россия Федерациясенең «Мәгариф турында», «Югары һәм вуздан соң профессиональ белем турында» законнары нигезендә Дәүләт белем стандартлары ике өлештән тора: федераль һәм милли-региональ компонентлардан. Бу – балалар бакчасыннан башлап, аспирантура-докторантурага да кагыла.

Милли-региональ компонентны эшләү һәм кертүне Закон федерация субъектларына тапшыра, һәм болай дип өстәп куя: югары белем өлкәсендә субъектның милли-региональ компонентны билгеләүдәге суверенлыгы – Россия дәүләт политикасында төп принципларның берсе. Ә инде «Мәгариф турында» законның 6нчы маддәсе нигезендә РФ составындагы республикаларның дәүләт телләрен өйрәнү бу республиканың законнары аша башкарылырга тиеш.

Законга комментарий ясап, Россия Мәгариф министрлыгының Белгечләр әзерләү буенча проблемалар үзәге милли-региональ компонент күпмилләтле дәүләт шартларында милли мәдәниятне саклау һәм үстерүне тәэмин итә дип белдерә.

Югары мәктәп коллективының компетенциясен һәм гражданлык позициясен исәпкә алып, бу компонентның эчтәлеген билгеләү аның үзенә тапшырылган. «Мәгариф турында» закон үз көченә кергәч, Россия Мәгариф министрлыгы Дәүләт стандартын куллану буенча югары уку йортларына берничә тапкыр инструктив хат җибәрде, һәм, төп белем программасын, укыту планнарын, фән программаларын төзегәндә, милли үзенчәлекләрне исәпкә алуга аерым игътибар бирүне шарт итеп куйды.

Беренче Дәүләт белем стандартларында минималь эчтәлек (федераль компонент) кенә күрсәтелгән иде. Аларда милли-региональ компонент ачык формада билгеләнмәгән иде, һәм вузлар аның булмавын “күрми” калдылар. Шуңа Россия Мәгариф министрлыгы аерым хат белән милли-региональ компонентка 20% кадәр вакытны биреп булганлыгын вузларның исенә төшерде. Бүген Югары белем стандартларында милли-региональ компонентның күләме төгәл билгеләнгән. Мисал өчен, гуманитар һәм социаль-экономик фәннәр циклында аңа 270 сәгать (бу якынча

15%), ә математика, табигать һәм гомумпрофессиональ фәннәр циклларында 10%ка кадәр вакыт бирелгән.

Татарстан югары уку йортларында милли-региональ компонентның күләмен тулысынча татар телен, тарихын һәм мәдәниятен (әз дигәндә, Туган якны яки Татарстан экономикасын) өйрәнүгә бирергә кирәк. Әмма, вузларның укыту планнарыннан күренгәнчә, милли-региональ компонент, башлыча, исәпкә алынмый, һәм аның сәгатьләре республиканың үзенчәлекләрен чагылдырмаган фәннәргә бирелә. Димәк, мәгариф турында төп законнар тупас рәвештә бозыла.

Искә алыйк, теләк булганда, милли-региональ үзенчәлекләрне өйрәнү өчен укыту планнарына сайлап алына торган фәннәрне дә кертергә була. Бу тагы 10-15 % вакыт дигән сүз.

Әлбәттә, әгәр финансласа, федерация субъекты милли-региональ компонентның эчтәлеген үзе билгели ала. Бу законда шулай дип язылган. Ләкин, бүгенге салым шартларында, югары белем стандартларын тормышка ашыруны үзәк тулысынча үзе финанслый. Димәк, милли-региональ компонентның чын-чынлап законга туры килүе өчен вуз җитәкчелегенең теләге генә кирәк.

Шулай итеп, Татарстанда федераль законнар игълан иткән дәүләти принцип (милли мәдәниятне һәм үзенчәлекләрне мәгариф системасы ярдәмендә яклау һәм үстерү) һәм тәкъдим иткән механизм (милли-региональ компонент) мәгарифнең иң әһәмиятле буынында – югары мәктәптә тормышка ашмый. Моның төп сәбәбе – Татарстанның бу өлкәгә кагылышлы үз законнарының һәм норматив документларының нигездә эшләнмәгән булуы.

Эшне һөнәри белем стандартларының татар милли компонентын эшләүдән, аны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан раслап, закон көченә кертүдән башларга кирәктер. Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгында татар телендә югары белем бирүне оештыручы һәм моның үтәлешен тикшерүче вәкаләтле югары белем идарәсе төзүнең дә әһәмияте зур булыр иде.

Шулай итеп, югары мәктәптә татар телендә белем бирергә, татар цивилизациясен өйрәнергә бүген хокукый һәм юридик нигезләр бар. Россия Федерациясе законнары (Конституциядән башлап) тәрбия һәм белем бирү өлкәсендә үзенең субъекты белән вәкаләтләрне бүлешүне, ә хөкүмәтара килешү Татарстанда урнашкан югары уку йортларында татар телендә укытуны таный.

ЯҢА МӘГЪЛҮМАТИ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР ҺӘМ ТАТАР ТЕЛЕН НОРМАЛАШТЫРУ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Т.И. Ибраһимов

(Казан дәүләт университеты)

Казан дәүләт университеты һәм Татарстан фәннәр академиясе каршындагы «Шәкли фәһем» лабораториясендә текстларны сөйләмгә күчерүче система – татарча сөйләм синтезлагычы төзелеп килә. Бүгенге көндә аның сөйләме бик үк табигый яңгырамаса да, җитәрлек дәрәҗәдә аңлаешлы. Якын киләчәктә синтезлагычның сукырларны, чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезне татар телендә нәшер ителгән язмалар белән таныштыра алауына ышаныч зур. Шулай ук без аның сөйләм әгъзалары имгәнгән шәхесләргә, татар телен икенче тел буларак үзләштерүчеләргә дә ярдәме тияр дип өметләнәбез.

Әйтергә кирәк, татар телен яңа мәгълүмати технологияләргә иңдерү синтезлагычлар төзү белән генә чикләнмәячәк. Алдагы көннәрдә ул татарча сөйләмне ишетеп тану, шул ук вакытта аны тәрҗемә итеп бару мәсьәләләрен чишүдә дә урын табачак. Шушы хәлне исәпкә алганда, синтезлагыч төзүдә ирешелгән тәҗрибәләрне уртаклашу, һичшиксез, файдалы булыр иде.

Татарча сөйләм синтезлагычы, башка телләр өчен төзелгән синтезлагычлар кебек үзлегеннән сөйләм тудырмый. Ул бары тик язма текстларны сөйләмгә күчерә. Мондый система, беренче чиратта, язу берәмлекләре белән сөйләм берәмлекләре арасында тәңгәллек мөнәсәбәтләре урнаштыруны таләп итә. Ягъни ул автоматик рәвештә язмаларны фонематик һәм фонетик транскрипцияләү алгоритмнары белән тәэмин ителергә тиеш була. Телгә алынган алгоритмнар бары тик тәртипкә салынган графикаларга карата гына төзелергә мөмкин. Кызганычка каршы, татар язуы менә шушы сыйфатка ия түгел. Әйтик, инглиз язмаларындагы «c» хәрефенең, я булмаса немес телендәге «s» тамгасының укылышы алар кулланылган урыннан һәм контексттан чыгып ачыкланырга мөмкин. Ә менә татарча текстлардагы сүзләрнең чыгышы кайсы телгә каравын белми торып, сузык һәм тартыкларның укылышын билгеләп булмый. Күп кенә очракларда сүзнең тамыр өлеше чит телгә, аффикслары татар теленә караган була. Бу сүзләрне транскрипцияләү морфологик

анализ ясау зарурыйлыгын тудыра. Ул анализның кайсы тел морфологиясе нигезендә ясалырга тиеш булуын әйтү кыен. Без хәтәр боҗрага юлыгабыз: транскрипция ясау өчен сүзнең чыгышын белергә, чыгышын белү өчен өлешчә транскрипция ясарга, ягъни тамырны аффикслардан аера белергә кирәк була.

Нәтиҗә бер – телне уңышлы рәвештә яңа мәгълүмати технологияләргә иңдерү һәм бер үк вакытта гомерен дә озынайту өчен аның фәнни орфографик һәм орфоэпик нормаларын төзү таләп ителә. Танылган Аргенетина галиме Э.Косериу фикеренчә, телне нормалаштыру «ничек әйтелергә мөмкин» принцибына түгел, ә ул авазларның (сүзләрнең) моңа чаклы ничек әйтелүеннән чыгып, ягъни традиция принцибына нигезләнергә тиеш. Татар телендә алынмаларның әйтелеш үзенчәлекләре күренекле якташыбыз В.А.Богродицкий хезмәтләрендә тәфсилләп бәян ителгән. Шушы галим күрсәтмәләре нигезендә төзелгән орфография һәм орфоэпия ярдәмендә генә татар язуы тәртипкә салынырга, синтезлагычлар уңышлы рәвештә татарча сөйләм тудырырга, ишетеп танучы системалар татар сөйләмен башка телләргә тәрҗемә итеп барырга мөмкин.

ИСЕМЕ ҖИСЕМЕНӘ ТУРЫ КИЛСЕН

Р.Х. Мөхиярова

(Чаллы дәүләт педагогика институты)

XX гасырның 90нчы елларында башланган милли хәрәкәт татар халкының үзаңы үсүгә китерде. Шуның нәтиҗәсендә байтак кына татар мәктәпләре, татар гимназияләре ачылды. Бу эшкә күпме милләтпәрвәрләрнең вакыты, энергиясе һәм сәламәтлеге сарыф ителде! Шәһәрләрдә ачылган татар мәктәпләре ничә еллар буена югары уку йортларының татар бүлекләре өчен абитуриентлар әзерләде. Гимназияләрдә укырга керергә әзерләү өчен аерым фәннәр буенча курслар да эшләп килде. Гадәттә, ул курсларда эшләү өчен югары уку йортлары укытучыларын чакыралар иде. Шул рәвешле, югары һәм урта мәктәпләрнең үзара бәйләнеше ныгыды. Бу – мәктәпләр өчен дә, институтлар өчен дә, бигрәк тә укучылар өчен бик файдалы эш формасы иде.

Кызганычка каршы, соңгы елларда бик күп предметлар яңадан рус телендә укытуга юнәлеш тота. Моның төп сәбәбе итеп югары

уку йортларында укытуның рус телендә алып барылуын күрсәтәләр, ә институтларда, үз чиратында, татар төркеменә укырга кергән студентларның татарча терминнар белмәвен сәбәп итеп, русча укытуга күчәләр. Исемнәре татар дип аталса да, татар мәктәпләрендә төп фәннәрне рус телендә укытуга күчүгә кем гаепле? Төп предметлар рус телендә укытылгач, ул уку йортлары ни өчен татар мәктәпләре дип атала?! Үзебез дә сизмичә, яңадан узган гасырның 80нче елларына әйләнеп кайтабыз, яулаган үрләребездән кире чигенәбез түгелме? Ни өчен Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы мондый күз буяуга тыныч кына карый, әллә үзе үк шундый сәясәт алып барамы? Чаң сугарга кирәк, татар мәктәпләребез әкренләп руслашып бара. Күз йомып торсак, соңга калуыбыз бар. Татар мәктәпләренең исеме жисеменә туры килергә тиеш.

ГОМУМИ УРТА ҺӘМ ЮГАРЫ БЕЛЕМ БИРҮЧЕ УКУ ЙОРТЛАРЫНДА ТАТАР ТЕЛЕНДӘ УКЫТУДА ДӘВАМЧАНЛЫК

М.Г. Мозафарова
(ТРның мәгарифне үстерү институты)

Татар теле дәүләт теле итеп игълан ителгәннән соң республикабызда гаять зур эшләр башкарылды; сәясәтчеләребез, галимнәребез, югары уку йорты һәм мәктәп укытучыларыбыз фидакарь эшчәнлек алып барды һәм бара. Ләкин зур эшләр күләгәсендә бүгенгәчә көнүзәк булып кала биргән мөһим мәсьәлә бар: ул – татар теленең дәүләт теле буларак та, туган тел буларак та өйрәнелүе, аны куллану даирәсенең киңлеге, камиллеге, табигый ихтыяҗ дәрәҗәсенә күтәрелүе өчен гомуми урта белем бирү учреждениеләре белән югары уку йортлары арасындагы дәвамчанлык зарурлыгы; ягъни, мәсьәләне дикъкать белән күздән кичерү, ачыклау, конкретлаштыру һәм чишү юлларының иң нәтиҗәлеләрен билгеләп эшчәнлек оештыру.

Уку йортларында татар теленә карата мөнәсәбәт татар мәктәпләренең сан ягыннан үсү-үсмәвенә турыдан-туры йогынты ясаучы факторларның берсе. Чөнки укыту-тәрбия процессы саф татар телендә алып барылган мәктәпләргә балаларын бирүгә ата-ана каршы. Алар фикеренчә, татарча гына укыган бала югары уку

йортында укый алмаячак. Үз балаң киләчәге хакында сүз барганда «милли үзаң», «тел» һәм «милләт язмышы» кебек олы кыйммәтләр арткы планга күчә. Һәр ата-ананың үз баласы Казанның, Мәскәүнең, Санкт-Петербургның, алай гына да түгел, дөньяның мәшһүр уку йортларында укырга лаек дип исәпләве табигый һәм законлы. Гаилә ул безнең төп заказчыбыз: укучы балалардан башка мәктәп тә, югары уку йорты да юк. Икенче яктан, зур заказчыбыз – милләтебез. Өченче яктан, дәүләт заказы бар – икетеллелек. Димәк, һәр заказчының ихтыяҗын төгәл канәгатьләндерү чарасы табылу зарур.

Россия Федерациясенең «Мәгариф турында»гы Законы нигезендә (29 маддә, 8 пункт) мәгариф өлкәсендә дәүләти белем стандартларының милли-региональ компонентын билгеләү Россия Федерациясе субъектлары карамагына керә. Бу исә, дәүләтнең (Россия Федерациясе), регионның, этносның һәм аерым шәхеснең мәнфәгатьләрен аерым-аерым һәм барысын берьюлы канәгатьләндерүче укыту-тәрбия процессы эчтәлеген булдыруның универсаль принцибын табу максаты белән эшләнгән.

Ә Татарстан Республикасында иң төп милли-региональ компонент – икетеллелек, ягъни, (идеал вариантта) бала, нинди милләт вәкиле булуына карамастан, татарча да, русча да сөйли һәм яза белергә тиеш. Бу инде татар теле һәм рус теле укытучысының гына түгел, ә укыту-тәрбия процессында катнашучы һәр субъектның гражданлык бурычы да.

Бу бурычның хәл ителү юлы гади була ала.

Мисал өчен, татар мәктәбендә башлангыч сыйныфта барлык предметлар да татар телендә бара; музыка, рәсем, хезмәт, табигать белеме дәреслекләренең эчтәлеге «этник кыйммәтләрдән – гомумкешелек кыйммәтләренә» принцибына корыла; махсус белем һәм күнекмәләр этник кыйммәтләрне чагылдырган материал аша формалаштырыла, аннан соң ут күршеләр кыйммәтен үзләштерү аша гомумкешелек кыйммәтләренә күчү гамәлгә ашырыла.

Һәр предмет буенча махсус белем һәм күнекмәләр рус телендә дә тапшырыла, үзләштерелә.

V-IX сыйныфларда да эшчәнлек шул ук принципта дәвам итә. Кайбер предметлар, мәсәлән, VI сыйныфта география, VII сыйныфта алгебра, геометрия һәм физика, VIII сыйныфта химия рус телендәге дәреслекләр белән укытыла ала һәм төп төшенчәләр, төп күнекмәләр татар телендә дә үзләштерелә; тик математиканы V-VI сыйныфларда

татарча укыту зарур. Чөнки V-VI сыйныф укучының барлык гомум уку күнекмәләре дә тәмам ныгып, киңрәк һәм тирәнрәк эшчәнлеккә әзерлек чоры. Әгәр математика рус телендә укытылса, балалар татар әдәби мирасын бар нечкәлеге белән кабул итәргә, сүзне, аның аһәңен тоярга өйрәнә алмаячак. Татар башлангыч сыйныфлары өчен яңа төр – диалектик танып белү кануннарына нигезләнгән математика дәреслеге авторы Фәүзия Казыйханова «Татар теле – математика теле. Чөнки татар җөмләсе төзелешенә баштан анализ, аннан соң гамәл салынган», – ди. Дәлил итеп вакланмалы саннарны уку буенча мисал китерә: җидедән ике – «җидегә бүл, икесен ал» дигәнне аңлата; ә «две седьмых» нәрсәне аңлата?.. Әдәбият ул адәм баласы өчен иң әһәмиятле кыйммәт. Чөнки әдәби сүз, әдәби әсәр геройларының әйткән сүзе, кылган гамәленә бәя биреп, укучыда эчке культура, аралашу тәҗрибәсе туплана. Милли яшәү рәвешен фәкать милли әсәрләр аша гына формалаштыру мөмкин.

Шул рәвешле, татар мәктәбенең IXнчы сыйныфын тәмамлаган укучы өчен тел барьеры гомумән калмый – укучы ике дәүләт телендә дә иркен аралашучы, татар әдәби мирасын, татар тарихын үзләштергән, милли аңы формалашкан шәхес булып җитлегә. Үзе теләгән теләсә кайсы профильле белем бирү учреждениесенең X-XI сыйныфында уку, киләчәктә югары уку йортына керү өчен реаль җирлек хасил була.

Әмма бу – «югары уку йортларында татар телендә укыту кирәкми» дигән сүз түгел. Киресенчә, Татарстан җирлегендәге югары уку йортлары Россия Федерациясе законнары кысаларында кабул ителгән җирле законнарны 100 % гамәлгә ашырырга бурычлылар: ягъни, абитуриент керү имтиханнарында аралашу чарасы буларак «тел»не сайлап алу хокукына ия (мисал өчен, математиканы татар телендә дә бирә ала) булып чыга. Димәк, кабул итү комиссиясендә ике дәүләт телен дә камил белүче галимнәр утыру зарурлыгы туа.

Тагын бер мөһим момент: мәктәп жанры – сочинение язу. Сочинение – укучының теге яки бу темага фикер йөртү дәрәҗәсен һәм шушы фикерен язма сөйләм аша җиткерү сәләтен күрсәтүче контроль төре. Шунлыктан, техник югары уку йортларында абитуриент сочинениене ике дәүләт теленең берсендә яза ала, бу логик яктан да, гуманлы булу ягыннан да табигый һәм максатка ярашкан принцип булып чыга. Бу бик мөһим, чөнки:

1) барлык кеше дә ике телдә уйларга сәләтле түгел; бер телдә булса да фикереңне эзлекле һәм тулы итеп җиткерә алу – үзе үк үсеш күрсәткече.

2) бу адым татар мәктәбен тәмамлаучы өчен аның өстенлеген (ташлама түгел) күрсәтүче факт та булыр иде.

Әгәр мондый эшчәнлекне оештыруга бүгенге федераль кануннар киртә куя икән, бу мәсьәләне тиешле югарылыкта күтәрү һәм чишү юлын тәкъдим итү бүгенге конференция вәкаләтенә керә ала кебек...

ЯЗЫК, ИСТОРИЯ, КУЛЬТУРА

О.Х. Кадыров

(Казанский государственный университет культуры и искусств)

И «Русский язык» Тургенева (1873), и написанный четыре десятилетия спустя «Туган тел» Тукая (1910) – произведения, которые всегда и у всех на виду. Извлечения и цитаты из них давно приобрели статус крылатых выражений, повторяемых изустно и письменно: «Великий и могучий», «И туган тел, и матур тел». Достойна удивления колоссальная внутренняя мощь, которая аккумулирована в этих чрезвычайно лаконичных по форме творениях Тургенева и Тукая и которая вот уже столько лет исправно выполняет свою функцию – неустанно подпитывает национальное самосознание наших народов. Ход исторической жизни лишь умножает число примеров, воочию подтверждающих, какое неизменно возвышающее воздействие продолжают они оказывать на все новые поколения своих читателей.

Национально-патриотические чувства, получившие свое столь совершенное выражение в стихах Тургенева и Тукая, получили продолжение в творчестве самых различных поэтов – от Анны Ахматовой и до Ярослава Смелякова, Аделя Ахмета, Назара Наджми и Энвера Давыдова. И все они одушевлены объединяющей их глубоко патриотической идеей, приверженностью своему языку как высшей духовно-нравственной ценности, которую народ вынашивал в себе в течение многих веков.

Глубоко показателен в этом плане поэтический отклик Энвера Давыдова на стихотворение Смелякова. Как поэт и гражданин, близко воспринимающий события отечественной истории, он

опирается в своем отклике на весь мощный духовный пласт, накопленный культурой его страны в прошлом. Его национально-патриотический пафос одинаково подпитывают собой и Тукай, и Пушкин, и Лермонтов, слагавшие свои гимны, в том числе и во славу общего для них отечества – России. Вот об этой-то единой общероссийской корневой системе, к которой восходят отдельные национальные ветви культур, возросших в пространствах полиэтнической многонациональной России, и напоминает Смелякову его оппонент. А «чарующий всякий взор иноплеменный» всепобедительный пушкинский «пиршественный стол» («уртак табын»), составленный из одних только «жемчугов его поэтического гения», к которому благоговейно тянутся все языци и народы – «и фин, и калмык, и тунгус», раскинут вовсе не за счет филиппик в адрес иного наречия.

Разве на ваш манер месил он
Свой язык, великий русский народ?
Один язык смалывал в меру муки,
Из другого выдавливал каплю дрожжей?

Так заявляет о себе характерное для татарского поэта ясное осознание себя внутри, в составе этого огромного свода общероссийской культуры, выстроенного его великими соотечественниками, говорящими на разных языках. Своим поэтическим пафосом Давыдов воочию демонстрирует действенность нового типа патриотического сознания, исторически складывавшегося в условиях полиэтнического государства России. Он для татарского поэта одновременно национально-этнический и общероссийско-гражданский, возросший на уровне единой для народов России культурной, социально-исторической почвы.

РОССИЯДӘ ТАТАРЧА УКЫТУ ТАРИХЫННАН

Ш.Н. Асылгәрәев
(Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты)

Россия дәүләтендә татарча укыту эше белән өч төрле уку йортлары шөгыльләнгән. Беренчесе – мәктәп һәм мәдрәсәләр. Бу уку йортлары 922 елдан, ягъни безнең бабаларыбыз рәсми рәвештә ислам динен кабул иткәннән соң һәр авылда, болгар-татар халкы

яшәгән һәр шәһәрдә булганнар. Мәктәп-мәдрәсәләрдә төп дәреслек, укырга-язарга өйрәтү китабы булып «Әлифба Иман шартлары берлән» исемле китап саналган.

Ул 1802 елда Казанда «Азия басмаханәсе»ндә нәшер ителә. Күләме ярты басма табак, 11 мең данә басыла. Тора-бара аның «Әлифба» сүзен төшереп «Шәраятел иман», аннан «Иман шартлары» дип үзгәртәләр. Халык телендә ул «Әлебби» (әлифба) аталып йөртелә. 1802 елга кадәр ул кулъязма рәвешендә йөргән, язылган елы билгеле түгел. Төзүчесе – бер чыганакта Мортаза Котлыгыш, икенчесендә – Ишнияз Ширнияз дип күрсәтелә. «Әлебби»дә иң элек 29 хәрефтән торган гарәп алфавиты, аннары шул ук алфавитның ас, өс, өтер куйган өч варианты китерелә. Алфавиттан соң хәрефләрнең өч шәкелдә (сүз башында, сүз уртасында, сүз ахырында) язылышы күрсәтелә. Болардан соң «Әбҗәд», ягъни арифметика гамәлләренә өйрәтү күнекмәләре урнаштырылган. Шуның белән «Әлебби» тәмамлана. XIX йөзнең туксанынчы елларына кадәр «Иман шартлары»н алыштырырлык икенче бер дөньяви «Әлифба» китабы күренми. Сәбәбе – фанатик муллалар, суфыйлар «Иман шартлары»на гына ябышып ятканнар, аны изге китап дәрәҗәсенә күтәргәннәр. XIX йөз ахыры – XX йөз башында бу хәл алдынгы татар җәмәгатьчелеген канәгатьләндерми. Бу чорда татар алфавитының һәм имлясының үзгәрешсез кала алмавын аңлаган галимнәр, журналистлар, мөгаллимнәр, әлифба һәм дәреслек авторлары (Г.Ибраһимов, Г.Алпаров, Ш.Таһири, Һ.Максуди, Г.Нугайбәк, Ә.Мостафа) көрәш мәйданына киләләр.

Татарча укырга-язарга өйрәткән икенче төр уку йортлары – махсус урта һәм югары белем бирүче рус уку йортлары. Тарихтан билгеле, XVII йөз – XIX йөзнең беренче яртысында татар теле Россиядә рәсми тел дәрәҗәсенә күтәрелә. Чөнки көнчыгыш дәүләтләре (Төркия, Иран, Монголия, Кытай) белән сәүдә һәм дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштыру татар теле аша барган. Бу хәл татар телен белүче дәүләт чиновникларын әзерләү бурычын көн тәртибенә куя. Инде XVIII йөзнең урталарыннан башлап гимназия-мәктәпләрдә, соңрак Россиянең югары уку йортларында башка фәннәр белән беррәттән татар теле дә укытыла башлый. Бу исә, үз чиратында, татар теленең төзелешен өйрәнгән грамматика китаплары булдыруны таләп итә. Бу уку йортларында татар телен өйрәтүче укытучылар, дәрес бирүдән тыш, дәреслекләр, тәрҗемә

сүзлекләр төзеп бастырганнар. Шундый авторлардан С.Хәлфин, И.Гиганов, И.Хәлфин, М.Иванов, Мирза Казимбәк, А.Троянский кебек галимнәрне күрсәтергә кирәк.

Татарча өйрәтүче өченче төр уку йортлары – керәшен татарлары өчен махсус ачылган мәктәпләр. Башында Н.Ильминский торган миссионерлар бу мәктәпләрдә укучы керәшен татарлары өчен рус графикасы нигезендә алфавит төзегәннәр, аның имлясын язганнар, татарның җанлы сөйләменә нигезләп дәреслекләр төзеп чыгарганнар. Менә аларның кайберләре: Н.Ильминский. О применении русского алфавита к инородческим языкам. – Казань, 1862; А.Воскресенский. Русско-татарский словарь. – Казань, 1894; Н.Остроумов Первый опыт словаря народно-татарского языка по выговору крещенных татар Казанской губернии. – Казань, 1876.

ТАТАР ТЕЛЕН ӨЙРӘНҮГӘ ИХТЫЯҖ БУЛДЫРУ ЧАРАЛАРЫ

Д.Г. Галимов, Г.Ю. Даутов, Б.А. Тимеркәев
(Казан дәүләт техника университеты)

Татар телен саклап калу һәм үстерүгә, телне өйрәнүдән тыш, аның кирәклеген тою зур этәреш ясый. Тел белән бәйләнгән моңа кадәрге реформаларның тулысынча эшләп китмәве өлешчә татар теленә зур ихтыяҗ булмау белән аңлатылса, өлешчә телне өйрәтүгә берьяклырак караш булу белән аңлатыла. Тел тулысынча эшләсен өчен, татар телен өйрәнү белән беррәттән, фәннәрне дә татар телендә өйрәнергә кирәк. Бу укучыларның фикерләү сәләтен үстерүгә зур йогынты ясый. Бүгенге көндә югары уку йортында укучы татар студентларының күбесе татар телен тел буларак белсәләр дә, аларның фикерләүләре нигездә рус теленә корылган. Чын татарча фикерләүче студентлар авыл мәктәбен тәмамлаган яшьләр арасында гына күзәтелә.

Югары уку йортларында да татар телен өйрәнү алга таба үсеш алсын өчен һәм шул ук вакытта студентлар киләчәктә яхшы белгеч булсын өчен татар теле дәреслекләрендә дә фәннәрне татар телендә өйрәнүнең үзенчәлекләренә игътибар итәргә кирәк. Теге яисә бу фәннең дәрәҗәсен күтәрү өчен без дәресләрдә бу тема киләчәктә

өйрәнеләчәк махсус фәннәр өчен нигез булып тора, дибез. Бу очракта студентлар фәннәр арасындагы бәйләнешне күрәләр, аларның фәннәргә игътибары көчәя. Шушы ук алымнарны татар теле дәресләрендә куллану татар теленең белгечлек белән бәйләнгән фәннәр дәрәҗәсенә күтәрелүенә китерер иде.

Бу юнәлештә инде беркадәр тәҗрибә дә кулланылган. Казан дәүләт техника университетының физика белгечлеге студентларының татар теле дәресләре нәкъ менә шушы технологиягә корып уздырыла, һәм бу дәресләр студентлар арасында зур кызыксыну тудыра.

ЮГАРЫ БЕЛЕМНЕ ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ТОРМЫШКА АШЫРУ ШАРТЛАРЫ

Р.Ә. Вәлиев, Л.Ә. Вәлиева

(Кама дәүләт инженер-икътисад академиясе)

Кама дәүләт инженер-икътисад академиясе (элек Кама дәүләт политехника институты – КамПИ) инженерларны татар телендә 1992 елдан бирле хәзерли. Бүген КамПИда ике факультетта ике белгечлек буенча 200дән артык студент татар телендә югары белем ала.

Татар телендә укырга теләүче һәм югары белем алырга сәләтле укучыларны җыю өчен җәмгыятьтә абруйлы һәм ил хуҗалыгына кирәкле белгечлек сайлап алырга кирәк. Без укыткан “Автомобильләр һәм автомобиль хуҗалыгы”, “Җитештерүне һәм технологик процессларны автоматлаштыру” белгечлекләре әнә шундыйлардан. Нәтиҗә буларак, татар бүлегендә конкурс та, өлгереш тә уртача күрсәткечтән югарырак, студентларның 15%ы кызыл дипломга лаек була, шактые укуын аспирантурада дәвам итә. Студентларның 20%ы түләүле нигездә татарча укуы да игътибарга лаеклы факт.

Татар бүлеген тәмамлаган сәләтле студентларны академиядә эшкә калдыру һәм аспирантурада укыту – татар телендә укыта алырлык югары квалификацияле укытучылар туплау өчен иң нәтиҗәле юл. Бу максатта без ел саен берничә белгечне КамПИның үзендә эшкә алып калабыз. Бүген аларның дүртесе аспирантурада укый, икесе быел диссертация яклаячак, ә алтысы гыйльми дәрәҗәгә лаек булды һәм хәзер инде үзләре доцентлар. Бу –

татарча укытуның сыйфатлы булуына саллы дәлил. Тулаем алганда, бүген бездә 60тан артык укытучы татар телендә укыта, аларның өчтән икесе доцент-профессорлар.

Татар телендә әсбаплар булдыру өчен иң тиз һәм нәтиҗәле юл – штатында тел белгечләре һәм үз китапханәсе булган, заманча җиһазландырылган методик кабинет төзү. Мондый кабинет ярдәмендә КамПИда татар телендә 155тән артык әсбап язылды һәм 17 мең данә күләмендә бастырылды. Хәзерге вакытта татар телендә язылган әсбаплардан бездә электрон китапханә төзелә: теләгән кеше бу әсбаплар белән интернет аша таныша алачак.

Безнең тәҗрибәнең төп нәтиҗәсе – техник югары уку йортларында татар телендә укытып була һәм бу нәтиҗәле эш. Менә шуңа күрә дә без 4 ел элек “законнарны тәңгәлләштерү һәм вертикальләштерү” чорында тулы ышаныч белән КамПИда тагын бер техник белгечлек буенча татар бүлеген ачтык.

Унбиш ел элек КамПИ сайлап алынган белгечлек буенча инженерлар хәзерләүне тулысынча татар телендә башкаруны максат итеп куйган иде, һәм нигездә без моңа ирештек тә: барлык фәннәр дә диярлек татар телендә укытылды, дәүләт имтиханнары һәм диплом эшен яклау татар телендә башкарылды. Әлбәттә, бу юнәлеш зур көч һәм мөмкинлекләр таләп итә. Мондый максат кую яңа белгечлекләр буенча татар бүлеген ачуны тоткарларга мөмкин. Югары уку йортларының мөмкинлекләрен исәпкә алсак һәм республикада игълан ителгән икетеллелекне күздә тотсак, барлык фәннәрне дә татар телендә укытуны якындагы максат итеп кую кирәк тә түгелдер. Шундый карашка нигезләнү безгә КамПИда тагы бер белгечлек буенча татар бүлеге ачарга мөмкинлек бирде: «Җитештерүне һәм технологик процессларны автоматлаштыру» белгечлегендә студентлар кече курсларда гына татар телендә белем ала. Гомумән, мондый шартларда бүген КамПИ башка белгечлекләр буенча да татар бүлеге ачарга әзер.

Югары мәктәптә шәхес тәрбияләүне фәннәрне татар телендә укытуга гына кайтарып калдырырга ярамый. Бик әһәмиятле тагы өч юнәлеш бар: татар телен укыту, татар тарихын өйрәнү һәм милли мәдәният рухын булдыру. Гомумән алганда, уку йортында татар мохитен тудырырга кирәк. Милли-региональ компонентны эшләү һәм тормышка ашыру – татар телендә укытуның ышанычлы киләчәге өчен кирәкле шарт, бигрәк тә техник вузларда. Шуңа

күрә соңгы елларда без моңа аерым игътибар бирә башладык.

КамПИның барлык уку планнарына да «Татар теле» һәм «Татарстан тарихы» фәннәре кертелгән. Татар теле бер курс дәвамында укытыла. Студентлар җитәрлек күләмдә дәреслекләр, сүзлекләр һәм кулланмалар белән тәэмин ителгән. Татар теле кабинеты видео-аудиосистема белән җиһазланган, һәм аның кечкенә китапханәсе дә бар. Укытучыларның өчесе – татар теле буенча фән кандидаты, тагы биш хезмәткәр татар теле буенча кандидатлык диссертациясе яза (берсе техник атамалар буенча). Бер тарих укытучысының гыйльми эше Кама төбәгендә милли югары мәктәп үсешенә багышланган. Узган ел шәһәр идарәсе белән берлектә КамПИда татар һәм рус телләрендә нәшер ителүче «Кама аръягы мәгарифе һәм фәне» электрон журналы оештырылды һәм рәсми теркәлде.

КамПИ даими рәвештә «Татар җыры», «Татар егете» һәм «Сабантуй гүзәле» конкурсларында, «Шаяннар һәм тапкырлар клубы»ның татарча уеннарында катнаша һәм призлы урыннар яулый. Ел дәвамында академия исәбеннән татар театр-концертларына коллектив мәдәни сәяхәт ясала. КамПИ даими рәвештә татар периодик басмаларына языла, «Мәйдан» журналы һәм «Шәһри Чаллы» газеталары 100 данә күләмендә академиянең барлык бүлекләренә таратыла.

Соңгы елларда шәһәр татар мәктәпләренең күбесендә төгәл фәннәр рус телендә укытыла башлады. Нәтиҗәдә бу мәктәпләрдән килгән абитуриентлар КамПИның татар бүлегенә керергә «куркалар», ә укырга кергәннәрен еш кына татар теленә «өйрәтергә» туры килә. Академия татар мәктәпләре һәм шәһәр мәгариф идарәсе белән даими аралашып тора. Бүген Чаллының 3 татар гимназиясендә һәм 1 татар мәктәбендә КамПИ класслары эшләп килә.

Бүген югары уку йортларында татар телендә укытуны милли мәктәп тәмамлаган балаларның ихтыяҗы дип кенә түгел, татар телен саклап калу һәм үстерүнең төп шарты дип кабул итәргә кирәк. Татар телендә техник югары белем бирүнең төп әһәмияте дә шунда, ул телгә фәнни төгәллек һәм логика биреп, аның камилләшүенә китерә. Икенче яктан, гуманитар белем белән генә чикләнгән тел, җәмгыятьнең техник үсешен билгеләүче төп хуҗалык тармакларына керә алмыйча, югалуга дучар ителә.

ЮГАРЫ УКУ ЙОРТЛАРЫНДА МИЛЛИ-ТӨБӘК КОМПОНЕНТЫ

Р.А. Закиров
(Чаллы дәүләт педагогика институты)

Югары уку йортларының укыту планнарына милли-төбәк компоненты (МТК) Югары һәм вуздан соң һөнәри белем турындагы Россия Законына ярашлы рәвештә 2000 елда гамәлгә куелган Югары белемнең дәүләти стандарты буенча кертелде. МТКның эчтәлеген билгеләүне Закон федерация субъектларына тапшыра. Әмма шул ук Законда «МТКның эчтәлеген билгеләүдә вузлар федерация субъекты белән ул аны финанслаган очракта килешеп эшләргә тиеш» дигән 5.5 маддәсе булгангамы, Татарстан Республикасы мәгариф органнарының бу өлкәгә әлегә кадәр катнашы булмады.

Чаллы дәүләт педагогика институтында МТКның конкрет эчтәлеге түбәндәгечә билгеләнә (тәҗрибә уртаклашу тәртибендә):

I. Гуманитар һәм иҗтимагый-икътисадый фәннәр блогы: барлык факультетларда да – татар теле (88-105 сәг.), Татарстан һәм татар халкы тарихы (68-76 сәг.), аерым факультетларда – татар әдәбияты һәм мәдәнияте, татар музыкасы, татар мәгърифәтчелек фикере тарихы.

II. Гомум математика һәм табигать белеме фәннәре блогы: Татарстан экологиясе (80 сәг.).

III. Гомум һөнәри фәннәр блогы: барлык факультетларда да – Татарстан педагогикасы тарихы (76 сәг.), аерым факультетларда – татар халык педагогикасы, Идел буе халыклары педагогикасы.

IV. Белгечлек фәннәре блогында МТК предметлары һәр факультетның үзенчәлеген чагылдыра. Мәсәлән, филология факультетында – Идел буе халыклары, татар әдәбияты, Татарстан топонимиясе һ.б.; география факультетында – Татарстанның физик (икътисадый һәм иҗтимагый) географиясе; сынлы сәнгать факультетында – татар милли костюмы, шамаил сәнгате, келәм туку һ.б.

Дөрес, аерым факультетларда (башка вузлардагы кебек үк) Республика һәм төбәкнең мәдәни, этник, географик, икътисадый һ.б. үзенчәлекләре белән бәйле булмаган, аерым укытучыларның тар тикшеренү юнәлешен генә чагылдырган курслар укытуга да юл куела. Гәрчә аларда сайлап алу өчен махсус курслар, факультативлар өчен бүленгән сәгатьләр дә җитәрлек.

МТКның бердәм фәннәр мәсьәләсен Республика күләмендә хәл итү, укытучыларның белемен камилләштерү, сыйфатлы дәреслекләр әзерләү, бастыру һ.б. эшләрне оештыру өчен ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы яисә Татарстан вузлары ректорлары советы янында координацион үзәк булдыру зарур. Төрле фәннәр буенча татарча чыккан китаплар белән танышканда аның кирәклеге бигрәк тә сизелә. Ул дәреслекләрнең кайберләрен гарәп-фарсы сүзлекләреннән башка аңлау авыр. Гомумаңлаешлы интернациональ терминнарны тел белгечләре һәм авторлардан башка кеше аңламаган атамалар белән алыштыру үзен акламый. Каш төзәтәм дип, күз чыгарып куймыйк. Вузлар өчен уку кулланмалары белгечләр һәм телчеләр тарафыннан җитди редакцияләнергә тиеш. Бу эшне оештыру өчен республикакүләм үзәк кирәк.

КАЗАН ДӘҮЛӘТ МЕДИЦИНА УНИВЕРСИТЕТЫНДА ТАТАРСТАН ТАРИХЫ КУРСЫН УКЫТУНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

М.С. Әхмәтов
(Казан дәүләт медицина университеты)

Казан дәүләт медицина университетында «Татарстан тарихы»н укыту Россия Федерациясендә гуманитар белем бирүне яңарту программасына, 1992 елда кабул ителгән «Татарстан халыклары телләре турында»гы Законга, шушы законны гамәлгә ашыру буенча Дәүләт Советы актларына таянып һәм Татарстанда барган үзгәрешләрне, шул исәптән республика яшәешенең төрле өлкәләре демократиягә йөз тотуын исәпкә алып барыла.

Татарстан тарихы 18дән алып 30 сәгатькә кадәр күләмдә, көндезге һәм читтән торып уку бүлекләрен дә кертеп, университетның барлык 9 факультетында да ике телдә укытыла. Лекцияләр рус телендә укыла, ә семинарларда укучылар ике телле төркемнәргә бүленә, дәресләр рус һәм татар телләрендә алып барыла. Татарстан тарихыннан тыш, семинарларда «Ватан тарихы» курсы да (күләме 85-90 сәг.) татарча укытыла. Университетта тарих фәнен татар телендә укучы төркемнәр саны 3кә җитә. Алар, нигездә, автор инициативасы белән оештырыла, укыту да аның тарафыннан башкарыла. Бу эшнең чишелмәгән

якларыннан укыту йөкләменең исәпкә алынмавын, аның даими финансланмавын, кадрлар мәсьәләсенең чишелмәвен, югары уку йортында үзәктән аудиторияләр белән тәэмин ителмәвен әйтеп узарга кирәк.

Татарстан тарихы курсы «Идел Болгарстаны», «Алтын Урда һәм татарлар», «Казан ханлыгы», «Татар халкы үзәкләштерелгән Рус дәүләтендә һәм Россия империясендә», «Татарстан-ТАССР төзелү», «Татарстан XX гасыр азагы – XXI гасыр башында» дигән этапларны үз эченә ала. 1992 елдан алып шушы курс буенча билгеле бер укыту тәҗрибәсе тупланды, укыту-методик база оештырылды дип әйтергә мөмкин. Аның буенча рус һәм татар телләрендә укыту программасы эшләнде, методик уку кулланмалары, семинар дәресләр планнары төзелеп бастырылды, карталар, таблицалар, структур-логик схемалар төзелде, Л.Н.Гумилев һ.б.ның чыгышлары буенча фонотека тупланды.

Бу юнәлештә кафедра чыганаклар базасын һаман яңарта тора. Бүгенге көндә безнең кафедраның Татарстан тарихы буенча тупланган чыганаклар базасы югары уку йортлары арасында иң алдынгысы дип санала. Укыту курсы Казан дәүләт медицина университетының фәнни-техник советы каршында рационализаторлык тәкъдиме итеп теркәлгән.

Татарстан тарихын өйрәнү теоретик һәм практик курсларны үз эченә ала. Семинарларда интернет аша халыкара мәгълүмат кулланыла, рефератлар әзерләнә, стендлар, структур-логик схемалар буенча чыгышлар ясала, тест үткәрелә. Дәресләр тематика буенча оештырылган аудиторияләрдә уза.

Татарстан тарихы Россия тарихына, гарәп дөньясына, төрки халыкларга һәм дөнья цивилизациясенә бәйләп бирелә. Төбәкнең мәдәни факторларына, мәсәлән, татар теле белән дөнья телләре, ислам дине һәм башка диннәр тарихына күбрәк игътибар ителә.

Татарстан тарихы курсын кулаерак (оптимальрәк) итү максатында чыганаклар базасын һәрдаим баетып торырга, республика югары уку йортлары буенча бердәй методологик юнәлеш булдырырга кирәк. Мондый эшләрне башкару, эш хакын даими түләү өчен югары уку йортлары Республика тарафыннан күпмедер күләмдә һәм законлы рәвештә матди (финанс) яктан һәрдаим тәэмин ителеп торырга тиеш.

ТАТАР ТЕЛЕНДӘГЕ МАТЕМАТИК ИСӘПЛӘҮ КАГЫЙДӘЛӘРЕ ҺӘМ СӨЙЛӘМ ТЕРМИННАРЫНЫҢ ЛОГИК ФОРМАЛАРЫ

Г.М. Мөбәракҗанов
(Казан дәүләт техника университеты)

Дәреслекләр, фәнни эшләр нинди телдә булуга карамастан, математика формулалары бертөрле языла, ә аларның укылу тәртибе (терминнар аша) һәр телдә үзенчә формалашкан. Әлбәттә, ничек укылса шулай язу уңайлы. Формулаларның мәгънәләре дә һәр фәндә үзенчә аңлашыла. Мәсәлән, вакланмаларны гына алыйк: русча әйткәндә без (мәсәлән, 3/7 – три седьмых) башта санаучыны, аннан ваклаучыны әйтәбез. Татарча исә (җидедән өч), киресенчә, башта ваклаучыны, соңыннан санаучыны әйтәбез һәм язабыз. Һичшиксез, ул шулай кирәк тә, чөнки вакланмаларны кушканда да, алганда да без башта уртак ваклаучыны табабыз һәм шунда ук аны җавап итеп ваклаучыга язабыз. Рациональ вакланманы гади вакланмаларга таркатканда да без һәрвакыт вакланманың ваклаучысында торган күпбуынның нинди тамырлары булуыннан чыгып эш итәбез. Тагын берничә мисал: югары уку йортларында кире функцияләрне дифференциаллаганда җавапта иң элек ваклаучыны язарга кирәк. Мәсәлән, вакланмалы функциянең хасиләсен (чыгарылмасын) табу кагыйдәсе болай укыла: «Производная дроби есть дробь, знаменатель которой равен квадрату знаменателя, а в числителе – производная числителя, умноженная на знаменатель минус производная знаменателя, умноженная на числитель». «Производная логарифмической функции есть дробь, в знаменателе пишем то, что стояло под логарифмом, а в числителе – его производную». «Производная квадратного корня есть дробь, в знаменателе которой два таких же корня, а в числителе – производная из подкоренного выражения» һ.б.ш. бик күп мисаллар. Мәктәп һәм югары математика дәреслекләрендә бу гамәлләрнең формулалары гына бар, ә без китергән кагыйдәләре юк.

Формулаларны күзе белән күреп, кагыйдәләрне колагы белән ишетеп бала үзенең күңеленә сеңдерә, колак белән ишетеп үзләштергән кагыйдәләр исә күз белән укып үзләштергән белемгә караганда төплерәк санала. Ләкин югарыда китерелгән кагыйдәләр шулай дип әйтелсә һәм язылса да, рус мәктәбендә урта бе-

лем алган студент, вакланманың санаучысын язмыйча торып, ваклаучысын яза башламый. Моңа ул үзе дә, рус мәктәбендә белем алган күп кенә укытучылар да игътибар итми.

А.Эйнштейн әйтүе буенча, бер математик та формулалар белән уйламый. Ә К.Э. Циолковский: «Математика тулысынча төгәл фикерләү фәне, ләкин хак фикерне математик формуласыз да аңлатырга була. Талантлы кеше математиканы белмәсә дә, ул асылда чын математик», – ди.

Фикер сөрешендә атама, исем һәм терминнарны урынлы һәм дөрес куллану гаять зур роль уйный. Төгәл фәннәрдә дөрес терминнар бигрәк тә әһәмиятле, чөнки терминнар фәннең нигезен, фундаментын тәшкил итә. Терминнарның үсеше фән һәм техника үсеше белән параллель бара. Тел фәнгә терминнар аша керә. Терминнарны уйлап тапканда галимнән бу фәнне тирән аңлап, берничә телне белү таләп ителә. Моның өчен күпьеллык тәҗрибә кирәк. Фәннең үсеш тарихын белү дә гаять зур роль уйный. Берничә мисал китерик.

Линеаль алгебра. lines – «линия», латин сүзе. Бу сүз математикада беренче дәрәҗәгә кагыла. Беренче дәрәҗә тигезләмәләр системасы, ягъни линеаль тигезләмәләр системасы, $f(x)=ax+b$ рәвешендәге линеаль функция һ.б.

Анализ бесконечно малых – *җетек зурлыклар анализы*. Урта мәктәп дәреслегендә түбәндәге җөмләләр бар. «...Гомумән, $\lim\limits_{x\to x_0}\alpha(x)=0$ булса, $\alpha(x)$ – чиксез кечкенә диләр. Чиксез кечкенәләр математик анализда зур роль уйныйлар. Шуңа күрә аны еш кына чиксез кечкенәләр анализы дип тә атыйлар». Уйлап карасаң, биредә $\lim\limits_{x\to x_0}\alpha(x)=0$ аңлатмасы үтәлү чикнең барлыгын күрсәтә. Чиге булгач, ни өчен «чиксез кечкенә» дип атала? дигән сорау туа. Димәк, термин татар теленә дөрес тәрҗемә ителмәгән. «Җетек зурлык» дип әйтү, безнеңчә, дөресрәк була.

Гарәп цифрлары 0,1,2,...,9 Европага Италия һәм Испания аша гарәпләрдән кергән һәм таралган. Элекке заманда белем һәм гыйлемнең халыклар арасында дин белән бергә таралуы һәркемгә билгеле. Бәлки нәкъ әнә шуның нәтиҗәсендәдер, ислам дине белән сугарылган татар теле, гарәп теле (коръән теле) кебек, ал-

горитмлы телгә әверелгәндер. Ул үзенең логикасы буенча да бик күп телләрдән өстен тора. Матур әдәбият теле булгангамы, рус телен алгоритмлы тел дип әйтеп булмый. Бер телле бер коммунистик милләт төзү сәясәте хөкем сөргән елларда рус теле безнең өчен бердәнбер фән теле булып никадәр шомарса да, алгоритмик тел булудан ул ерак тора. Моны тормышта да бик еш очратабыз. Татар теленең исә математика укыту өчен искиткеч күп байлыгы, башка уңай яклары бар.

ТАТАР ТЕЛЕНДӘГЕ МАТЕМАТИКА ТЕРМИННАРЫ ТУРЫНДА

Л.И. Галиева, И.Г. Галәветдинов, М.З. Хөснетдинов

(Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты)

Математика факультетының кайбер группаларында алгебра, геометрия, математик анализ, саннар теориясе фәннәре унбиш елдан артык татар телендә укытыла. Шуңа күрә, бер яктан караганда, шактый зур тәҗрибә тупланды, ә икенче яктан – кайбер авырлыклар ачыклана төште. Без шундый авырлыкларның кайберләренә тукталып китәрбез.

1. Математика терминнарының эчтәлегенә кереп җитмичә, сүзгә-сүз тәрҗемә итү уңышсыз терминнар килеп чыгуына китерә. Бу тезисны дәлилләүче берничә мисал китерик. «Касательная плоскость» һәм «соприкасающаяся плоскость» дигән терминнар хәзерге сүзлекләрдә татарчага «орынма яссылык» һәм «орынучы яссылык» дип тәрҗемә ителгәннәр. Татар телендә «орынма» һәм «орынучы» дигән сүзләр бер үк мәгънәдә кулланыла. Ләкин «касание» һәм «соприкасание» дигән русча терминнарның математик эчтәлекләре төрлечә. «Соприкасание» дигән термин югарырак дәрәҗәдә орынуны аңлата. Шул сәбәпле аңа татар телендә яңа термин кирәк. Мисал өчен, «тиеп орынучы» яисә «ябышып орынучы» терминнарын тәкъдим итәргә булыр иде.

Тагын «цепная дробь» – «чылбыр вакланма», «подходящая дробь» – «яраклы вакланма» дигән тәрҗемәләр дә бу терминнарның математик мәгънәләрен аңлатмыйлар. Беренче очракта аерым рәвештәге вакланмалар турында сүз бара, «чылбыр» сүзе аның мәгънәсен ачыкламый. Шуңа күрә бу урында «тезмә вакланма» яки «өзлексез вакланма» терминнары

уңышлырак булыр иде. Икенче очракта – бирелгән санга тиешле дәрәҗәдә якын булган вакланмалар карала. Шунлыктан «якынаючы вакланма» төшенчәсе дөресрәк була.

Шул ук вакытта, математик эчтәлеккә игътибар ителгән уңышлы тәрҗемә мисаллары да бар. Мәсәлән, «правильное решение», «правильная дробь», «правильный многоугольник» дигән терминнар «дөрес чишелеш», «ялгыз вакланма», «төзек күппочмак» дип тәрҗемә ителгәннәр. Шулай ук «одинаковые доли», «одинаковые знаки» – «бердәй өлешләр», «бертөрле тамгалар»; «однозначное соответствие», «однозначное число» – «беркыйммәтле тиңдәшлек», «берурынлы сан» терминнары да шул ук исемлеккә керәләр.

2. Татар теле кагыйдәләрен бозып төзелгән яңа терминнар да очрый. Мисал итеп «подмножество» терминының «асткүплек» дигән тәрҗемәсен китерәсе килә. Татар телендә мондый сүз дә һәм бу рәвешле яңа сүз төзү кагыйдәсе дә юк. Профессор Ф.Ганиев редакциясендә төзелгән сүзлектә «под» дигән алкушымча ярдәмендә исемнәр хасил итүнең барлык очраклары да санап кителгән. Алар арасында безгә ярардай ике очрак китерелә: «подкласс» – «кече класс», «подотдел» – «бүлекчә». Шуңа күрә «подмножество» – «кече күплек» яисә «күплекчә», «подгруппа» – «кече группа», «подкольцо» – «кече боҗра» дигән терминнар уңышлы булыр иде.

Китерелгән мисаллар математика терминнарына тәрҗемә ясауның шактый җаваплы эш икәнен күрсәтәләр. Шуңа күрә аны төрле югары уку йортлары укытучылары берләшеп эшләсә генә уңай нәтиҗә көтәргә була. Көчләрне берләштерүдә мондый конференция ярдәм итәр дигән өметтә калабыз.

ТЕОРЕТИК МЕХАНИКАНЫ ТАТАРЧА УКЫТУНЫҢ КАЙБЕР ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ ҺӘМ ЙОМГАКЛАРЫ

А.З. Камалов

(Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты)

Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетында аерым белгечләрне татар телендә хәзерләү эше 15 ел дәверендә даими рәвештә алып барыла. Бу мөһим эшне беренче булып күтәреп чыгучы, аны оештыручы һәм Татарстанда популярлаштыручы, җаны-тәне белән бу эшкә бирелгән һәм аңа нәтиҗәле хезмәт иткән

шәхес В.Ш. Фәтхуллин булды. Нәкъ менә 1990-91нче елларда Вагыйз Фәтхуллин җитәкчелегендә аның университеттагы бер төркем фикердәшләре тарафыннан татарча югары белем бирү программасы төзелде, кайбер фәннәр буенча, шул исәптән теоретик механика буенча да, эш программасы, лекцияләр конспекты һәм методик күрсәтмәләр хәзерләнде.

Теоретик механика фәнен татарча уку-укытуны җитәрлек дәрәҗәдә дәреслекләр белән тәэмин итү максатыннан, кыска вакыт эчендә (1992-93 еллар) механиканың барлык бүлекләре буенча диярлек шактый зур күләмле 4 уку кулланмасы язылды һәм басылып чыкты.

Һичшиксез, нинди генә укыту фәне булмасын, укучыга юнәлтелгән китаплар югары фәнни дәрәҗәдә булулары, теленең аңлаешлы һәм кызыклы булуы белән билгеләнергә тиеш. Фәнни дәреслекне, китапны иҗат иткәндә сүзне тою, телнең гармониясен нечкә сизү галимгә яңа фәнни терминнар табарга, уйлап чыгарырга ярдәм итә. Аңлатыла торган күренешләрне бу терминнар төгәл чагылдырырга һәм сөйләмгә туры килергә тиеш. Өйрәнелә торган табигать объектларына һәм күренешләренә тәңгәл исем бирә белү – бик сирәк очрый торган сәләт. Һәрбер фән буенча, шул исәптән теоретик механика буенча да, сыйфатлы терминнар уйлап табу гадәттән тыш кыен нәрсә. Моны алдан күргән һәм бик яхшы аңлаган В.Ш. Фәтхуллин, 1991 елны ук югары белемле тел белгечләрен җәлеп итеп, терминология комиссиясе һәм семинар оештырып җибәрде. Бу комиссия 15 ел дәверендә даими рәвештә бик нәтиҗәле эшләп килде. Терминология буенча шәһәркүләм семинарларда авторлар белән семинарларда катнашучылар тарафыннан тәкъдим ителгән терминнар тирәнтен анализланды һәм кабул ителде. Нәтиҗәдә, фәнгә ныклап кереп урнашкан терминнар аз түгел.

Терминология комиссиясе тарафыннан расланган терминнарны кулланып һәм теоретик механиканы татарча укыту барышында тупланган тәҗрибәгә таянып иҗат ителгән татарча «Теоретик механика» дәреслеге 1996 елны «Мәгариф» нәшриятында дөнья күрде. Әйтергә кирәк, җәмәгатьчелек тарафыннан дәреслеккә зур бәя бирелде һәм ул югары белем бирү мәктәбендә теоретик механиканы татарча укыту методологиясенең нигезен тәшкил итә.

Башка техник фәннәрне өйрәнгәндә теоретик механиканың төп кануннарын киң һәм урынлы куллану өчен катлаулы корылмаларга, җайланмаларга якынлаштырылган гамәли

мәсьәләләрне зур осталык белән чишә белергә кирәк. Шуны күздә тотып, кафедра тарафыннан мондый катлаулы мәсьәләләр чишүнең кайбер яңа методик алымнары да татар телендә тәкъдим ителде һәм методик күрсәтмәләр рәвешендә бастырып чыгарылды.

1992-93 елларда теоретик механика буенча нәшер ителгән уку кулланмалары уку-укыту барышында таушалу, китапханәләргә кире кайтарылмау сәбәпле аз калганлыктан, университетның татарча укыту буенча методик комиссиясе, тупланган тәҗрибәгә таянып, расланган фәнни терминнарны кулланып бай эчтәлекле һәм сыйфатлы яңа кулланмалар төзергә һәм нәшер итәргә дигән карар кабул итте. Шуны тормышка ашыру ниятеннән, 1998-2004 елларда теоретик механиканың статика, кинематика һәм динамика бүлекләре буенча мәсьәләләр җыентыклары (авторлары А.З. Камалов, Ф.Г. Шиһабетдинов, Р.Н. Ильязов) хәзерләнде һәм нәшер ителде. Бу дәреслекләр 1996 елда басылып чыккан китап һәм 1992-93 елларда нәшер ителгән мәсьәләләр җыентыклары нигезендә эшләнде. Дөресен әйткәндә, болар яңа җыентыклар. Аларда Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетының теоретик механика кафедрасында татарча укыту барышында соңгы елларда тупланган тәҗрибә чагылыш тапты.

Йомгаклап әйткәндә, теоретик механика буенча бер китаптан, 8 уку кулланмасыннан һәм методик күрсәтмәләрдән торган 1500 бит күләмле уку-укыту методик комплексы төзелде. Әлеге комплекс Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетында 15 ел дәверендә сынау үтте һәм үзен яхшы яктан күрсәтте. Ул теоретик механиканы татарча укытуга куелган таләпләрне тулысынча канәгатьләндерә дияргә була.

ТЕОРЕТИК МЕХАНИКАДА АТАМАЛАР ДӨНЬЯСЫНА КҮЗӘТҮ

М.Х. Мәрсәлимов, Р.Г. Хәкимов
(Кама дәүләт инженер-икътисад академиясе)

1990 елда Татарстан үзенең мөстәкыйльлеге турында Декларация кабул итү республикада татар телен үстерүгә зур этәргеч булды. Казан төзелеш институтыннан соң 1992 елда Яр Чаллыда Кама дәүләт политехника институтында “Автомобильләр

һәм автомобильләр хуҗалыгы” белгечлегендә беренче тапкыр бар фәннәр татарча укытыла башлады. Хәзер академиядә шәкертләр ана телендә ике белгечлек буенча белем алалар. Теоретик механика фәне буенча да эш зур дәрәҗәдә алып барыла. Барлык кирәкле кулланмалар, уку әсбаплары язылды һәм институт нәшриятында дөнья күрде. Дистә ярым ел чорында бу кулланмаларны язган галимнәр яңадан халыкның хәтерендә калган һәм башка фәннәрдә (күбесенчә урта мәктәптәге физика басмаларында) кулланган атамаларга таянды. Методик кулланмалар, әсбаплар язганда Рәшит Шакир төзегән “Русча-татарча төзелеш атамалары” сүзлеге кулланылды. Бүгенге көндә кирәкле кулланмалар язылса да, таләпләр елдан-ел артып тора.

Әгәр инде теоретик (ягъни назари) механикада кулланган атамаларга кагылсак, татар телендәге мирасны яңадан югалтканыбызны яхшырак аңлыйбыз. Мондый караш тик механика фәненә генә кагылмый. Күрәсең, бу гомуми хәл: рус теленә дә хәзерге заманда урынлы-урынсыз чит тел сүзләре керә бара. Бигрәк тә бу хәл милли телебезгә кагылышлы. Күпчелек галимнәр арасында атамаларга караш бертөрле түгел: күп вакытта рус сүзләре кулланыла. Бездәге тәҗрибә теоретик механикада татар яки халыкара таралган атамаларны гына куллану мөмкинлеген күрсәтә. Татар теле шактый бай, ул юкка гына дөньяда иң таралган 14 телгә кермәгән. Телебезнең мирасын күтәрү юлында без беренче адымнар гына ясыйбыз. Елдан-ел сүзлекләрдә, халык хәтерендә калган сүзләр табылып тора. Бу бик сокландыргыч хәл. Телебезнең байлыгына горурлану сәбәпләре чиксез. Хәзерге чорда Татарстан фәннәр академиясенең ярдәме дә урынлы булыр иде. Үткән елларда тупланган тәҗрибә нигезендә техника фәннәреннән, шул исәптән механикада кулланган атамалардан татарча-русча сүзлек чыгару бик зарур.

«КОРЫЛМА МЕХАНИКАСЫ» ДӘРЕСЛЕГЕНЕҢ КОНЦЕПЦИЯСЕН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ

Р.Ә. Шакирҗанов

(Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты)

Корылма механикасы (русча: строительная механика) фәне каты җисем механикасының мөһим өлешен тәшкил итә. Аның

ысуллары корылмалар һәм биналарны проектлау, хисаплау һәм тикшерү эшләрендә киң кулланыла. Югары белемле инженерлар әзерләү стандартларында һәм программаларында да бу фәнне өйрәнүгә зур әһәмият бирелә. Шуңа күрә корылма механикасы буенча күп дәреслекләр язылган. Алар бу фәннең төрле өлкәләренә төрлечә игътибар биреп, төрле аудиториягә исәпләнгәннәр, төрле күләмдә һәм тирәнлектә язылганнар.

Фән үсә барган саен корылма механикасы да үсә, аның яңа өлкәләре, ул чишә торган мәсьәләләр саны арта бара. Хисаплау техникасының куәте һәм мөмкинлекләре үскән саен яңа хисаплау ысуллары һәм алгоритмнары эшләнә. Шуңа күрә язылган дәреслекләр бүгенге таләпләргә җавап бирми, тиз арада искерә баралар. Шул ук вакытта, илебезнең техник һәм фәнни потенциалы киму, техник белемне кысрыклау һәм гуманитар белемгә күбрәк әһәмият биру шаукымы нәтиҗәсендә, укыту программаларында корылма механикасы (һ.б. бик күп техник фәннәр) өчен билгеләнгән дәресләр саны кимеде. Шунлыктан, булачак белгечне корылма механикасының теоретик нигезләре, ысуллары, төрле корылмаларны хисаплау алымнары белән таныштыру кыенлашты. Бүген фәннең яңа казанышларын исәпкә алган, шул ук вакытта тулы эчтәлекле, кыска һәм аңлаешлы телдә язылган дәреслекләргә ихтыяҗ бар.

Өченче меңьеллык бусагасында татар теле яңа үсеш алып, фән һәм югары техник белем биру өлкәсенә дә үтеп керә башлады. Бу хәл милләтебезнең рухи һәм мәдәни үсеше белән дә, аның формасы буенча милли, ә эчтәлеге буенча дөньякүләм мәгариф системасына интеграцияләнгән мәгариф системасын төзергә омтылышы белән дә аңлатыла. Без, Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетының бер төркем татар галимнәре, әлеге тенденцияне тоеп, татар телендә югары техник белем бирүгә нигез салырлык дәреслекләр һәм уку кулланмалары язуга, сүзлекләр төзүгә зур әһәмият бирәбез.

Корылма механикасы фәне татар телендә беркайчан да укытылмаган. Шуңа күрә аны 1993 елны укыта башлаганда ук татарча лекцияләр курсын язарга, гамәли дәресләр үткәрү һәм курс эшләрен башкару өчен кулланмалар эшләргә кирәк

булды. Эшне фәнни югарылыкта оештыру өчен КДАТУда «Корылма механикасын татар телендә укытуның фәнни-методик һәм гамәли нигезләре» дигән яңа фәнни тикшеренү темасы ачылды, булачак дәреслекнең концепциясе төзелде.

Тикшеренүләр ике төп юнәлештә алып барылды. Аның беренчесе – татарча фәнни-техник терминология һәм фәнни стиль. Бу юнәлештә эшләү татарча техник терминнарны барларга, тупларга һәм тәртипкә салырга мөмкинлек бирде. Нәтиҗәдә, автор тарафыннан һәм аның катнашында берничә сүзлек эшләнеп, бастырып чыгарылды. Алар арасында «Русча-татарча төзелеш атамалары сүзлеге», «Төзүчеләр өчен русча-татарча сүзлекчә», «Русча-татарча нефть сәнәгате сүзлеге» һ.б. бар. Шулай ук, бу юнәлештәге эшчәнлек нәтиҗәсендә «Фән һәм тел» дип аталган фәнни-хәбәри журналга нигез салынды, аның фәнни стиле һәм терминнар системасы булдырылды. Журнал бүген дә яши, татар халкына һәм татар теленә хезмәт итә. Инде аның 28 саны дөнья күрде.

Икенче юнәлеш – корылма механикасы фәненең теоретик һәм гамәли нигезләрен студентларга татар телендә ирештерү һәм алар мөстәкыйль өйрәнә алырлык уку кулланмалары әзерләү. Бу юнәлештә дә күләмле эш башкарылды: татарча лекцияләр курсы язылды, 4 уку кулланмасы һәм 2 методик кулланма басылып чыкты. Инде татар телендә «Корылма механикасы» дәреслеге әзерләнеп, бастыру өчен «Мәгариф» нәшриятына тапшырылды.

Дәреслек корылма механикасы фәнендә булган яңа казанышларны исәпкә алып һәм авторның күпьеллык укыту тәҗрибәсенә нигезләнеп язылды. Ул 3 кисәктән һәм русча-татарча терминнар сүзлекчәсеннән тора. Андагы 15 бүлекнең һәрберсендә, теоретик материалдан тыш, бик күп рәсемнәр, мәсьәлә чишү үрнәкләре, мөстәкыйль чишү өчен мәсьәләләр, белемне тикшерү өчен сораулар бирелә.

Киләчәктә шушы дәреслек нигезендә студентлар өчен яңа лекцияләр курсы, гамәли дәресләр үткәрү өчен кулланма-дәреслек, компьютер ярдәмендә белемне тикшерү комплексы эшләү күздә тотыла.

ТЕХНИК ЮГАРЫ УКУ ЙОРТЛАРЫНДА ФИЗИКА УКЫТУНЫҢ КАЙБЕР ПРОБЛЕМАЛАРЫ

Ф.Ф. Рамазанов, Ф.С. Сәрвәров, Х.К. Таҗмиев
(Кама дәүләт инженер-икътисад академиясе)

Физика – техник фәннәрнең нигезен тәшкил итүче фәннәрнең берсе. Бары тик физика кануннарын тирәнтен аңлаганда гына техник белгечлекләр укыту программасына кертелгән гамәли механика, термодинамика, газлар динамикасы кебек фәннәрне җиңел үзләштерергә мөмкин. Татар балаларына физиканы ана телендә укытуның файдасы күзгә күренеп тормаса да, мондый эшнең зарури булуын "киредән исбатлау" мисаллары раслый. Мәсәлән, кайбер урта уку йортларында аерым фәннәрне чит телдә укыталар. Күп еллар дәвамында күзәтүләр физиканы болай укытуның нәтиҗәсе аяныч булуын аермачык күрсәтәләр.

Соңгы елларда техник югары уку йортларында физиканы татарча укытуны югары дәрәҗәгә күтәрү мөмкинлекләре күпкә артты. 1999-2004 елларда Казан дәүләт техника университеты профессорлары Галимов Д.Г., Даутов Г.Ю. һәм Тимеркәев Б.А. язган өч томлы дәреслек нәшер ителде. 2004 елда шул ук авторларның физикадан мәсьәләләр җыентыгы "Мәгариф" нәшриятында дөнья күрде һәм Татарстан хөкүмәтенең телләрне саклау һәм үстерү эшчәнлегендә каралган күрсәтмә нигезендә югары уку йортларына түләүсез таратылды. Биредә шуны әйтеп үтәргә кирәк, әлеге дәреслекләр, бигрәк тә иң беренче нәшер ителгән беренче һәм икенче томнар, барлык уку йортларында да җитәрлек күләмдә түгел.

Билгеле булганча, физика – ул тәҗрибәләргә нигезләнүче фән. Ә тәҗрибәләрне дәреслекләрдән укып кына аңлау кыен, аларны үз күзләрең белән күзәтергә кирәк. Шулай булганда гына алар яхшы һәм озаграк хәтердә торалар. Әмма барлык тәҗрибәләрне дә лаборатор дәресләрдә һәм лекцияләрдә күрсәтеп булмый. Мондый очракларда видеофильмнар куллану уңайлы. Хәзерге көндә физика өчен андый кулланмалар аз, ә татарчалары бөтенләй юк.

Иң зур һәм иң авыр хәл ителүче проблемаларның берсе – физиканы татарча укыту буенча кадрлар җитешмәү. Бу проблема зур, күләмле һәм ул татарча укытуга гына кагылмый. Хәзерге вакытта мәктәпләрдә физика укытучылары җитәрлек түгел, ә

татарча укытучылар бигрәк тә аз. Шул сәбәпле югары уку йортларында физикадан хәзерлекләре түбән булган студентлар белән эш итәргә туры килә. Физика укытуның сыйфаты кими. Билгеле, мондый шартларда югары уку йортлары кул кушырып утыра алмыйлар. Соңгы вакытта Кама дәүләт инженер-икътисад академиясендә техник белгечлекләргә укучы студентлар өчен мәсьәләләр чишү буенча өстәмә дәресләр уздырыла. Алар уку расписаниесенә кертелгәннәр, студентларның бу дәресләргә йөрүе мәҗбүри.

ГОМУМИ ФИЗИКАДАН ЛАБОРАТОР ЭШЛӘР БУЕНЧА КЕРЕШ ДӘРЕС

Н.К. Гайсин
(Казан дәүләт технология университеты)

Гомуми физика буенча лекцияләрдә лекторның аерым студентлар белән турыдан-туры контакты аз. Лектор лекцияне бер студент өчен генә түгел, аудиториядәге барлык студентлар өчен укый һәм лекцияне ничек кабул итүләрен күзәтә. Лаборатор дәресләрдә эш башкача тора. Анда укытучы студентлар белән аерым-аерым эш итә. Бу эш татар телендә укытыла торган группалардагы студентлар өчен әһәмиятле, чөнки монда укытучы белән студент туган телендә турыдан-туры әңгәмә алып баралар.

Лаборатор эшләр лекциядә өйрәнелгән материалларны тәҗрибәдә тикшерергә һәм аларны истә калдырырга, ныгытырга, бу материалларны тикшерү буенча практик күнегүләр алырга, төрле приборлар белән эш итәргә өйрәтә һәм мөмкинлек бирә. Шул сәбәпле, студент тикшеренү эшенә иҗади карарга, күзәтелә торган күренешләрне аңларга, аларның нигезендә ятучы теорияне дөрес куллана белергә тиеш. Экспериментны аңлы рәвештә уздыру, игътибарлык һәм төгәл үлчәү, эшкә җитди караш, приборларга сакчыл мөнәсәбәт – лаборатор эшләрне уңышлы башкаруның мөһим шарты. Кереш дәреснең татар телендә уздырылуы мондый шартларны тудыруда зур роль уйный. Группадагы студентларның байтагы мәктәптә физиканы рус телендә укыган булып чыга. Беренче дәрестә үк аларга вузда физиканы татар телендә өйрәнергә туры киләчәген аңларга туры килә.

Бу дәресне ике төп өлештән тора дип күз алдына китерергә була.

Беренче өлештә түбәндәге мәсьәләләр карала:

– физикадан лаборатор эшләрне башкарганда студентларның максаты һәм бурычлары;

– физика лабораториясе һәм анда куелган лаборатор эшләр белән таныштыру;

– лаборатор эшләрне башкару өчен студент ничек әзерләнергә тиеш;

– лабораториягә килгәч, студентлар ни эшләргә тиеш, лабораториядә тәртип саклау кагыйдәләре белән танышу;

– лаборатор эшләрне ничек башкарырга;

– лаборатор приборлар төзек булмаса, яки эшләрне башкарганда аңлашылмаган сораулар туса, ни эшләргә;

– лаборатор эшләрне башкарганнан соң, үлчәнгән тәҗрибә нәтиҗәләре белән ни эшләргә;

– лаборатор эшләрнең нәтиҗәләрен дәфтәргә ничек теркәргә;

– башкарылган лаборатор эш буенча отчетны укытучыга ничек тапшырырга, отчет тапшырганда нинди сорауларга күбрәк әһәмият бирергә;

– лаборатор эшләрне башкарганда саклык кагыйдәләрен ничек үтәргә.

Икенче өлештә физик үлчәүләрне башкару һәм аларның нәтиҗәләрен эшкәртү методлары карала.

Теләсә нинди физик зурлыкны үлчәү гадәттә өч төрле операцияне бер-бер артлы үтәүгә кайтып кала:

– приборларны урнаштыру һәм тикшерү;

– күзәтү һәм прибор күрсәткән зурлыкны теркәү;

– үлчәү нәтиҗәләре буенча исәпләү һәм үлчәнгән яки исәпләнгән зурлыкларның хаталарын бәяләү.

Соңгысында түбәндәгеләр күздә тотыла:

– хаталарны төркемләү;

– ихтималлык теориясенең нигезләре белән кыскача танышу (очраклы зурлыклар, аларның бүленеше һәм бүленеш параметрлары, очраклы зурлыкларның һәм аларның хаталарының нормаль бүленеше);

– аз тапкыр үлчәү төгәллеген санау өчен сайланма метод белән танышу;

– турыдан-туры һәм читләтеп үлчәүләрнең хаталарын бәяләү методлары белән танышу;

– үлчәү нәтиҗәләрен графикта күрсәтү методлары белән танышу.

Боларны өйрәнгәндә студентлар ихтималлык теориясенә караган яңа терминнар белән танышалар, чөнки алар киләчәк лаборатор эшләрне башкарганда күп мәртәбә кулланыла.

СЫЗМА ГЕОМЕТРИЯ, ИНЖЕНЕР ҺӘМ КОМПЬЮТЕР ГРАФИКАСЫ ФӘННӘРЕН ТАТАРЧА УКУТУНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

Р.Г. Газизуллин

(Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты)

Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетында «Сызма геометрия» фәнен татарча укыту 1993 елдан бирле алып барыла. Бу, беренчедән, татар телен рус теле кебек дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү, икенчедән, авыл балаларының түбән хәзерлекле булулары, өченчедән, курсны үзләштергәндә тел барьеры булу, дүртенчедән, күп кенә авыл мәктәпләрендә сызым дәресләре үткәрелмәү белән бәйләнгән.

Авыл мәктәбен бетергән укучыларының ике үзенчәлеге бар: беренчедән, алар тырыш, белем алырга теләклеләре зур, икенчедән, табигатьнең перспективасын шәһәр балаларына караганда киңрәк күзаллыйлар.

«Сызма геометрия» авыр фәннәрдән санала, ә русча яхшы белмәү аркасында аны үзләштерү тагын да катлаулана. Бу предметны татар телендә укыту өчен профессор С.М. Миңнуллин тарафыннан 1995 елда «Сызма геометрия» дәреслеге язылды һәм басылып чыкты. Бу дәреслек, фәнни хезмәткә якын буларак, катлаулы. Ул фән эшлеклеләре һәм укытучылар өчен язылган дияргә була. Анда, чалыштырма турылар методларына таянып, ярдәмче моделләү ысуллары күп кулланылган. 2002 елны профессор Р.Г. Газизуллин «Сызма геометрия»нең кыскача курсын гадиерәк телдә язып чыгарды. Шулай ук, бездә татар телендә «Инженер графикасы» курсы алып барыла, аны укыту өчен дә барлык методик кулланмалар бар диярлек.

Тел – информация алу инструменты. Белемне төрле телләрдә – рус, инглиз, француз, немец һәм башка телләрдә дә алып була. Әмма катлаулы фәннәрне ана телендә (әгәр дә укучы ул телдә

укыган һәм белем алган булса) алу-үзләштерү нәтиҗәлерәк була.

Авыл балалары түбәнрәк белемле булу сәбәпле, лекцияләр укыганда һәм практик дәресләр алып барганда Г.Монж эпюрлары аңлашылсын өчен ноктаның, сызыкның, яссылыкларның, өслекләрнең моделләре киң кулланыла. Шулай ук, эш дәфтәрләрендә төп теорияләр һәм мәсьәләләрне чишү алгоритмнары бирелә. Бу методик кулланмалар дәресләрне нәтиҗәле үткәрергә мөмкинлек тудыра. Беренче семестрда студентлар 90 мәсьәлә чишәләр, аларның 50-60%ы аудиториядә, ә калганнары өйдә. Аннан тыш 4 график эш башкаралар. Түбәндә студентларның имтихан бирү нәтиҗәләре китерелә.

1 таблица

Сыйфат күрсәткече	Татар телендә укучылар		Рус телендә укучылар	
	Сессиядә	Сессиядән соң	Сессиядә	Сессиядән соң
Бик яхшы, %	6,1	6,1	18,1	19,1
Яхшы, %	24,2	24,2	25,1	33,4
Уртача, %	48,5	69,7	24,7	46,6
Түбән, %	21,2	–	32,1	0,9
Өлгереш, %	78,8	100	67,9	99,1

Бу таблицадан күренгәнчә, татар группаларында укучы студентларның белем сыйфаты рус телендә укучы студентлар белән чагыштырганда түбәнрәк, әмма гомуми өлгереш буенча сессиядә дә, сессиядән соң да югарырак.

Икенче семестрда студентлар «Инженер графикасын» өйрәнәләр һәм аның буенча дүрт график эш башкаралар. Шунысын әйтеп китәргә кирәк, татар телендә укучы студентлар бирелгән эшләрне укытучыга төгәл график буенча тапшыралар һәм вакытында зачет алалар.

2 таблица

Уку теле	График эшләрне үтәү сыйфаты				Өлгереш, %
	Бик яхшы, %	Яхшы, %	Уртача, %	Үтәлмә-гән, %	
Татарча	8,9	36,1	52,2	2,8	97,2
Русча	15,1	36,8	43,2	4,9	95,1

2нче таблицадан күренгәнчә, «Инженер графикасы» буенча татар һәм рус телендә укучы студентларның өлгерешләре (бик яхшы билгеләреннән башка) бер-берсеннән аз аерылалар дияргә була.

Икенче курсның беренче семестрында «Компьютер графикасы»

рус телендә алып барыла. Татар телендә укучы студентлар «Сызма геометрия»нең һәм «Инженер графикасы»ның нигезләрен белгәч, «Компьютер графикасын» үзләштерүне авырсынмыйлар, вакытында контроль эшләрен тапшыралар һәм зачет алалар.

Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, ана телендә белем алган студентлар югары курсларда белемнәре буенча рус телендә укыган студентларны куып җитәләр һәм алгарак та китәләр.

МЕТРОЛОГИЯ, СТАНДАРТЛАШТЫРУ, СЕРТИФИКАЦИЯЛӘҮ ФӘНЕН ТАТАРЧА УКЫТУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Г.Р. Мортазин

(Казан дәүләт авыл хуҗалыгы академиясе)

Метрология, стандартлаштыру һәм сертификацияләү (МСС) гомуми һөнәри фән буларак югары һөнәри инженерлар әзерләүдә гаять мөһим урын алып тора. Шуңа да карамастан, соңгы елларда уку планнарында һәм дәүләти үрнәк эш кәгазьләрендә бу фәнне өйрәнүгә бирелгән вакытның өзлексез кимүе күренә.

МССның төп кануннарын башка һөнәри фәннәрне өйрәнгәндә дөрес куллану мөһим, шул максаттан чыгып студентлар, теорияне тирән үзләштерү белән бергә, җитештерүдә киң очрый торган конкрет мәсьәләләрне зур осталык белән чишәргә тиешләр. Болар белән бергә, МСС өлкәсендәге төп атамаларның махсус һәм әдәби чыганакларда булмавы бу фәнне татар телендә укытуны гаять катлауландыра. Югарыда әйткәннәрне исәпкә алып, КДАХАда МССны укыту эше берничә этапта алып барылды.

Беренче этапта атамалар сүзлеге төзелеп, эш программалары булдырылды, лекция конспектлары язылып, тәҗрибә йөзеннән гамәли дәресләр үткәрелде, лекцияләр татар телендә укыла башланды. Икенче этапта (1998-2000 еллар), югарыда әйтелгәннәрдән тыш, татар телендәге лекция конспектлары яңадан эшкәртелде, методик кулланмалар, күргәзмә әсбаплар булдырылды һәм алар дәресләрдә сыналды. Өченче этапта (2001 елдан) методик кулланмалар, уку дәреслеге матбугатта бастыруга әзерләнде.

Студентларның фәннәрне татарча укытуга карашын билгеләү өчен анкета үткәрелде. Аларга МССка кагылган түбәндәге

сораулар бирелде:

1) Татар телендә белем алырга телисезме?

2) Татар телендә укыту сыйфаты сезне канәгатьләндерәме?

3) Рус телендә укытылган фәннәр белән чагыштырганда белемегезне ничек бәялисез?

4) Татарча уку-укытуга барлык шартлар тудырыламы?

1996-2001 елларда анкеталарга барысы 164 студент яшерен рәвештә җавап бирде. Югарыда китерелгән сорауларга җавапларны анализлап, кыскача түбәндәге нәтиҗәләрне ясарга мөмкин. МСС фәнен КДАХАда татарча укытуга карата студентларның мөнәсәбәте яхшы якка үзгәрә. Мәсәлән, 1996 елда 25, ә 2001 елда 38 студент татарча укырга теләкләрен белдерде. Икенче сорауга җавапларда 1996 елда 25 студентның 13е генә канәгатьләнү белдерсә, 2001 елда 41 студентның 36сы канәгать булуын күрсәтте. Өченче сорауга – 1996 елда 15, ә 2001 елда 37 студент үзләренең МСС фәне буенча татарча алган белемнәрен рус телендә алган белемнәрдән яхшырак дип бәяләде. Моны студентларның төрле фәннәрдән имтиханда алган билгеләре дә дәлилли. Ә менә соңгы (дүртенче) сорауга җавапта 2001 елда 28, ә 1996 елда 20 студент укыту шартларыннан канәгать булмауларын белдерде.

Югарыда әйткәннәргә нигезләнеп шундый нәтиҗә ясарга мөмкин. Татарстанның дәүләт телләре турындагы канунын гамәлгә ашырып, Казан дәүләт авыл хуҗалыгы академиясендә МСС фәне буенча ике телдә укыту алып барыла. Тәҗрибә күрсәткәнчә, татарча укыган студентлар да, русча укыган студентлар да белемне бер үк дәрәҗәдә үзләштерә. Шулай итеп, әлеге фәнне ике дәүләт телендә дә укытырга мөмкин һәм аны дәвам итү өчен тигез мөмкинлекләр тудырырга кирәк.

ТАТАР ХАЛКЫНА АНА ТЕЛЕНДӘ ТАБИГЫЙ-ФӘННИ БЕЛЕМ БИРҮ ТАРИХЫНА ЗАМАНЧА КАРАШ

Н.Ш. Мифтахова, И.Я. Курамшин, А.М. Кузнецов

(Казан дәүләт технология университеты)

Татарстан Республикасында югары белемне ике телдә бирүгә нигез моннан ун-унбиш ел чамасы элегрәк салына. Республиканың иң яңа тарихында үз урынын алу өчен бу аз вакыт түгел, әлбәттә. Әлеге

вакыйганы тормышка ашыручылар – үзебез. Ләкин без татар халкына белемне ана телендә бирү турында сүз алып барабыз икән, безне киләчәккә рухландыручы табигать фәннәре өлкәсендәге күпгасырлык мәгариф тарихын һич тә онытырга хакыбыз юк. Әлегә иң өйрәнелгән өлкәләрдән татар халкының математикадан үз телендә белем алу тарихы санала. Математика фәненнән татарча терминологиянең барлыкка килүе һәм үсеше, математиканы ана телендә укыту тарихларын тикшерү – моның ачык дәлиле. Шулай ук, Татарстан Республикасындагы ике теллелек шартларын күздә тотып, татар милләтеннән булган укучыларны математика фәнен ана телендә укытуга күчерүнең никадәр мөһим булуы һәм мөмкин эш икәнлеге анализланган. Моннан тыш, Урта Идел, Урал буе өлкәләрендә яшәүче татар һәм рус халыкларының X гасырдан алып XX гасыр башына кадәрге чордагы астрономия, физика, география, биология буенча белем алу нәтиҗәләре билгеле. Татар телендә медицина терминологиясенең формалашу һәм үсеш тарихы өйрәнелгән.

Соңгы ике унъеллыктагы тикшеренү нәтиҗәләрен санап чыгуның максаты нәрсәдә соң? Бу – татар халкының табигый-фәнни белем алудагы меңьеллык педагогик тарихына анализ ясау һәм әлеге тикшеренү нәтиҗәләрен менә бүген – милли белем бирүне активлаштыру чорында – файдалану мөмкинлеге иде.

Милли белем бирүне активлаштыруның конкрет адымнары түбәндәгеләр:

а) белем бирү өчен бөтен шартлары булган уку йортлары булдыру. Бу бурыч хөкүмәт компетенциясенә керә;

б) укыту-методик әсбаплар белән тәэмин итү. Монысы инде турыдан-туры әлеге уку йортларында эшләүче укытучыларга карый. Татарстанның техник һәм технология югары уку йортларында химия фәне ике телдә укытыла башлану белән, университет укытучылары җиң сызганып дәреслекләр һәм лингвистик әдәбият төзеп бастыру эшенә керештеләр. Мондый басмаларның бер өлеше безнең университетның неорганик химия кафедрасында әзерләнде. Алар буенча ике телдә укучы студентлар белем алалар. Без, беренче чиратта, кирәклек ихтыяҗыннан чыгып, русча-татарча терминнар сүзлекләре төзедек. Эш барышында элекке елларда татар телендә дөнья күргән терминологик сүзлекләргә һәм уку әсбапларына мөрәҗәгать итәргә туры килде. Алар белән танышкач, химия фәне буенча мондый төр басмаларның бары тик гарәп яисә латин

графикасы нигезендә генә нәшер ителүе ачыкланды. Лингвистик һәм укыту-методик әсбаплар төзүче хәзерге заман педагогларының күпчелегенә әлеге милли байлыгыбыздан файдалану гаять дәрәҗәдә авыр. Без, менә шуларны күздә тотып, химия фәне буенча гарәп шрифтында дөнья күргән лингводидактик басмаларны өйрәндек. Бу басмалар татар мәгарифенең яңарыш чорына (XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы) карый. Тикшеренү нәтиҗәләре «Фән һәм тел» журналының 2005 елгы саннарында басылып чыкты.

ОРГАНИК ХИМИЯНЕ ТАТАР ТЕЛЕНДӘ УКЫТАБЫЗ

М.Б. Газизов, Р.Ф. Кәримова

(Казан дәүләт технология университеты)

1997 елда Казан дәүләт технология университетында ике телдә – татар һәм рус телләрендә – укыту үзәге оештырылды. Соңга табарак үзәк Ике телдә укыту кафедрасы итеп үзгәртелде. Шул ук елны органик химия кафедрасында да ике телдә укытуны оештырдык. Төп укыту теле итеп, әлбәттә, татар телен сайладык, барлык дәресләрне – лекцияләрне, семинар һәм лаборатория дәресләрен татар телендә алып бара башладык.

Билгеле инде, һәр фәндә аңа гына хас булган терминнар бар. Химия терминнарын без рус телендә дә, татар телендә дә бирәбез. Мәсәлән:

химическое соединение – химик кушылма,
промежуточная частица – арадаш кисәкчек,
переходное состояние – күчеш халәте,
родоначальная структура – башлангыч структура (төзелеш),
взаимодействие – тәэсир итешү,
реакционная способность – реакциягә керү сәләте,
вещество – матдә һ.б.

Ә халыкара терминнарны, аларның татар телендә эквивалентлары булуына да карамастан, өч телдә кулланабыз. Мәсәлән:

acid and base <u>theory</u> – <u>теория</u> кислот и оснований – кислоталар һәм нигезләр <u>теориясе</u> (тәгълиматы);

parent <u>structure</u> – родоначальная <u>структура</u> – башлангыч <u>структура</u> (төзелеш);

amine <u>group</u> – амино<u>группа</u> – амин <u>группасы</u> (төркеме);

locant – локант – локант (урын саны) һ.б.

Татар телендә уку һәм укыту әсбаплары әзерләү өстендә дә эшлибез. 2001 елда «Мәгариф» нәшрияты безнең «Химик кушылмалар номенклатурасы» дигән дәреслекне бастырды. 2006 елда бастыру өчен шул ук нәшриятка «Инглизчә-русча-татарча химик сүзлек»не тапшырдык.

ЮГАРЫ УКУ ЙОРТЛАРЫ ӨЧЕН ХИМИЯДӘН ТАТАРЧА ДИДАКТИК МАТЕРИАЛЛАР ТӨЗҮ

Г.Г. Хисамиев

(Казан дәүләт медицина университеты)

Татар милли мәгариф системасы турында сүз алып барганда тарихи чыганакларга мөрәҗәгать итәргә кирәк. Билгеле булганча, ислам дине белән Болгарга фән һәм фән белән кызыксыну да үтеп керә. Моңа, мәсәлән, X гасырда Биләр казые Әбү Галә бине Идрис әл-Болгариның медицина, шәех Хаҗи Әхмәд әл-Болгариның фармакология буенча хезмәтләр («Әл-җәмигъ», «Файдалы асыллар») иҗат итүләре, XIII гасырда табиб һәм фармаколог Таҗетдин бине Юныс әл-Болгари хезмәтләре («Дару үләннәренең мөмкинлекләре», «Агулануга каршы иң яхшы дәвалар») һәм аларның берничә кат язылып, гарәп илләрендә таралуы ишарәли. Монгол яуларыннан соң, Алтын Урда, Казан ханлыклары чорында фәннең үсеше, шушы илләрнең төрле өлкәләрдә чәчәк атуы күзәтелә. Явыз Иваннан соңгы ике йөз еллык «томаналык»тан соң татарларның Рәсәй империясе яшәешенең барча өлкәләренә дә үтеп керә башлавы нәтиҗәсендә татар мәгарифе кабат уяна, аякка баса башлый. Әмма бу процесс нигездә гуманитар юнәлештә (дин, сәүдә һәм тәрбия өлкәсендә) генә алып барыла. Беренче фәнни реформа XIX гасыр ахырында К.Насыйридан башлана, XX гасыр башында Г.С.Ибраһимов (Шнаси) тарафыннан мәдрәсәләр өчен химиядән гарәп графикасында дәреслек тә чыгарыла.

Әмма татар терминологик лексикографиясе, татар мәгарифе Октябрь инкыйлабыннан соң гына, татар теле дәүләт статусы алгач кына үсеш ала. 1921 елда Татарстан Республикасы терминология комиссиясе оештырыла, аның тарафыннан тармак терминнары төзү буенча күрсәтмәләр эшләнә. Шуңа таянып, 1935 елда Г.Камай җитәкчелегендә латин графикасы белән русча-

татарча сүзлек (төзүчеләре – Г.Дистанов, Г.Вәлитов), Г.Камайның «Химиядән лекцияләр курсы» басылып чыга. Соңрак, Советлар Союзында урнашкан режим бу эшләргә киртә куя. Мәсәлән, Г.Дистанов тарафыннан химия буенча әзерләнгән 10 мең терминлы сүзлек 1978 елда гына, үз эченә нибары 1500 терминны алган хезмәт рәвешендә дөнья күрә.

Татарстан Республикасының суверенлыгын игълан итү, «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы Законны кабул итү терминологик сүзлекләр төзүнең яңа (өченче) этабына этәргеч ясады. Аңа таянып, химиядән шактый күләмле русча-татарча сүзлекләр (Мифтахова Н.Ш., М.Б.Газизов һ.б.), аңлатмалы сүзлекләр (Р.С.Сәйфуллин, Г.Г.Хисамиев, А.И.Нарбеков һ.б.), югары уку йортлары өчен химиядән беренче дәреслек һәм уку кулланмасы (Г.Г.Хисамиев) нәшер ителде. Химия өлкәсендә югары уку йортлары өчен гомуми химиядән татарча уку-укыту комплекты булдырылды.

XX гасырның 90нчы елларында башланган милли яңарыш мәктәпкәчә оешмаларда татар төркемнәре булдыру, башлангыч һәм урта белем бирү мәктәпләрендә татар телендә укытуны арттырудан тыш, югары уку йортларында татар телен укыту һәм татарча югары белем бирү мәсьәләләрен дә күтәрүгә этәргеч ясады. Милли телдә һөнәри белем бирү өчен шушы телнең язма һәм әдәби нормалары, белем бирү системасы, фәнни терминнары булу мөһим. Тиешле статусы булмау, һәм шул сәбәпле кайбер сыйфатлары буенча үсеш алмаса да, татар теле белем алу-бирүдә кулланырлык иде.

Шуларны исәпкә алып, 90нчы елларда, беренче чиратта Татарстандагы техник югары уку йортларында, татарча укыту төркемнәре булдырылды. Бу эш В.Ш.Фәтхуллин (КТИИ), А.К.Юлдашев (КАХИ), Ф.Ә.Гарифуллин (КХТИ), А.Х.Хәйруллин (КамПИ) җитәкчелегендәге бер төркем татар техник интеллигенциясе вәкилләре активлыгы, инициативасы, басымы астында башланып китте. Мәсәлән, КТИИда химия фәне татарча 1991 елдан бирле өзлексез укытылып килә. Ул 10 ел буена доцент Г.Г.Хисамиев, ә соңгы елларда доцент Р.Т.Порфирьева тарафыннан үткәрелә. В.Ш.Фәтхуллин тарафыннан булдырылган шартлар, аның ярдәме иң нәтиҗәле булды. Чөнки химиядән чыгарылган ике сүзлек («Физика, химия һәм химия технологиясе буенча русча-татарча-инглизчә аңлатмалы сүзлек-белешмә»,

«Химиядән русча-татарча аңлатмалы сүзлек»), «Гомуми химия» дәреслеге, «Гомуми химия: Мәсьәләләр һәм күнегүләр» шушы институт тәҗрибәсе һәм В.Ш.Фәтхуллин күзәтчелегендә эшләнде. Бу хезмәтләр Татарстан фәннәр академиясе тарафыннан югары уку йортлары өчен татар телендә дәреслекләр төзү буенча 1996-2004 елларга исәпләнгән Координацион план-программага таянып, Татарстан хөкүмәте каршында оештырылган «Татарстан халыклары телләре турында»гы Законны гамәлгә кертү бүлеге (К.М.Миңнуллин) матди ярдәме, «Мәгариф» милли нәшрияты (М.Х.Вәлиев) хезмәткәрләре тырышлыгы белән дөнья күрде. Һәрбер югары уку йорты өчен аерым укыту чаралары төзү яки аларны русчадан татарчага тәрҗемә итеп бастыру икътисади яктан нигезсез булганга, региональ дидактик материаллар булдыру эше әһәмиятле иде. Мондый чаралар федераль дәүләт стандартларына һәм регион таләпләренә, югары уку йортларының укыту программаларына туры китереп, фәннең эчтәлеге, аның төзелеше, үзләштерелергә тиешле белемнең күләме буенча кимендә рус телендәге мәгълүматларны үз эченә алып, этник-мәдәни мохиттә дә, гомумкешелек сферасында да эшли алырлык белгечләр хәзерләү мөмкинлеген тудыру тиешлеген исәпкә алып төзелде. Рус телендәге аналоглары кебек, аларга фәнни һәм гамәли әһәмият, күргәзмәлелек, киң мәгълүмат хас. Моннан тыш, алар гомуми химия фәнен читтән торып укыганда да үзләштерергә, татар телендә иҗади фикерләү сәләтен үстерергә, белешмәлекләр белән эшләү осталыгына өйрәнергә, материалның мәгънәсен тормышчан кабул итергә, Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә аңлы рәвештә җиңелрәк эш алып барырга мөмкинлек тудырырлар дигән өмет уяталар.

Фәннәрне үзләштерүдә терминнарның әһәмиятен, фәннең үсешендә яңа терминнар төзү яки чит телдәге терминнарга тиң татарча терминнар куллану таләбен исәпкә алып, химиядән бердәй терминнар куллануны максат итеп, элегрәк вузара терминология комиссиясе химия буенча еш кулланыла торган һәм бәхәсле дип саналган атама-терминнарны тикшерде. Комиссия кабул иткән терминнар бастырылып, югары уку йортларына, нәшриятларга, Дәүләт Советына, мәктәп-гимназияләргә таратыла иде. Шулай итеп, без химиядән татарча бердәй терминнар системасын булдырдык. Шушы эшләрне башкаручыларның берсе буларак, алар халкыбызга киләчәктә дә хезмәт итәр дигән өметтә каламын.

ТӨЗҮ МАТЕРИАЛЛАРЫ ФӘНЕНДӘ ТЕХНИК ТЕРМИННАР КУЛЛАНУ

З.А. Камалова, А.М. Сөләйманов
(Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты)

1991 елны Татарстан суверенитеты турында декларация кабул итү татар телен тергезүгә һәм ана телендә укытуга бик зур этәргеч булды. Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетында 1990-91 елларда В.Ш.Фәтхуллин җитәкчелегендә аерым белгечләрне татар телендә хәзерләү эше башланды. Татар авылларында һәм шәһәрләрдә татар мәктәпләрен тәмамлаган балаларга югары уку йортларына ана телендә укуларын дәвам итәргә мөмкинлек ачылды.

Техник фәннәрне татар телендә укыта башлау бик мөһим һәм катлаулы адым иде. Чөнки төрле очрашуларда, театрда, өйдә татар телендә бик матур итеп сөйләшкән татар зыялылары, хәтта техник интеллигенция дә, техник терминнарга кагылышлы яки аларны кертеп сорау биргәндә яисә рус теленә күчә, яисә чит телдәге терминнарны кушып сөйли, яисә татар телен ямьсез итеп боза башлый. Ни өчен шулай килеп чыга соң? Татар телендә техник белемне ничек бирергә, нинди терминнар кулланырга?

Төзү материаллары фәнен татарча укыта башлаганда шундый сораулар күп иде. Аларга җавап табу өчен башка телләргә мөрәҗәгать иттек. Мисал өчен, рус телендә чит ил терминнары бик уңай кереп урнашкан. Техник текстларда алар аеруча күп. Гомумән, телләрнең үсеш тарихы башка телләрдән сүзләр алу кебек объектив күренеш белән бәйләнгән. Бу күренеш төзелеш материаллары фәненең тарихына да карый. Мәсәлән, рус теленә башка телләрдән кергән күпсанлы терминнар арасында гарәп теленнән (фарфор, мрамор), грек теленнән (керамика, полимер, асфальт, гипс, металлургия, асбест), латин теленнән (битум, материал), немец теленнән (клинкер, цемент, гнейс), татар теленнән (кирпич, чугун, смола, деготь, тартание, руда) кергән сүзләр дә, европалашкан терминнар да (бетон, фибробетон, ситалл) бик күп.

Без, төзелеш материаллары фәнен татарча укытканда, шушы объектив күренешне исәпкә алып, рус телендәге атап киткән терминнарны кулландык. Әмма, терминнар итеп гарәп һәм фарсы телләреннән яки татар теленнән кергән сүзләр кулланылса, аларның татарча вариантларын алырга тырыштык (мәрмәр, чуен,

сумала, дегет, чәртәп һ.б.). Шулай да, безнең уебызча, төп акцент европалашкан терминнарга бирелергә тиеш. Чөнки бүген интернет һәм информацион технологияләр заманы.

Шушыларны истә тотып, төзелеш материаллары фәнен татарча укыту өчен методик әдәбият әзерләнде, 2 уку кулланмасы һәм 7 методик күрсәтмә басылып чыкты.

БОТАНИКА ФӘНЕН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ УКЫТУ ТӘҖРИБӘСЕ

Л.Г. Мәүлүдова
(Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты)

Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетының ботаника кафедрасында татар төркемнәрендә укучы студентларга ботаника фәнен ана телендә укыту 1992 елда башланды. Шул вакыттан алып доцент Р.Х. Фәйзерахманова һәм автор татар телендә уку-укыту әсбаплары хәзерләүдә зур эш башкардылар. Хәзерге вакытта барлык уку-укыту материаллары (программалар, имтихан сораулары, тестлар) татар теленә тәрҗемә ителгән. Укыту процессының барлык төрләре дә – лекция, лаборатор дәрес, кыр практикасы, имтихан алу һ.б. татар телендә алып барыла.

«Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законының гамәлгә керүе бу эшкә керешергә төп этәргеч булды. 2002-06 елларда әлеге Законны гамәлгә ашыру комитеты ярдәмендә «Мәгариф» нәшриятында «Ботаника: Югары төзелешле үсемлекләр систематикасы», «Ботаника: Суүсемнәр, гөмбәләр, лишайниклар систематикасы» дигән дәреслекләр нәшер ителде. Дәреслекләрдә Татарстан флорасына зур урын бирелде. Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән, саклауга мохтаҗ булган, сирәгәеп бара торган үсемлекләргә аеруча игътибар ителде.

Беренче дәреслек нигезендә «Лаборатор дәресләр үткәрү методикасы» һәм «Эш дәфтәре» дә басылып чыкты. Без хәзер һәр курс буенча уку-укыту басмаларының тулы комплектын булдыру һәм укыту методикасын камилләштерү өстендә эшлибез.

Таксоннар атамаларын, фәнни терминнарны төзүдә билгеле бер авырлыклар туды. Терминнарның бер өлеше рус теленнән

тәрҗемә ителде (орлыкбөре – семяпочка), икенче өлеше – татар теленнән табылды (җимешлек – җимеш өлгерүче орган, русча: пестик). Термин чит телләрдән алынган булганда (мәсәлән, гинофор), аның килеп чыгышын аңлатабыз (гр. gyne – хатын-кыз, phoros – күтәреп тору, гинофор – чәчәктә җимешлек утыручы күтәренке урын). Үсемлек төрләренең татарча атамалары Ф.Г. Ситдыйков һәм Р.К. Зәкиев редакциясендә басылып чыккан «Биологиядән русча-татарча аңлатмалы сүзлек»кә (Мәгариф, 1998) нигезләнеп алынды, шулай ук латин теленнән кергәннәре дә байтак (мәсәлән, кладофора – Cladophora).

Терминнарны, үсемлек атамаларын дәресләрдә элек бары тик татарча гына бирергә тырыша идек. Хәзер мондый караш бик дөрес түгел дип уйлый башладык. Һәр терминның һәм үсемлек исеменең рус телендә дә тәрҗемәсен бирәбез, студентларыбыздан аларны белүен таләп итәбез. Моннан тыш, ботаника систематикасының фәнни теле латин теле булганга, төп таксоннарның исемен латинча да белү мәҗбүри. Шулай итеп, без укыту процессына полилингва караштa торабыз.

Югары уку йортларының татар төркемнәрендә укучы студентларга төрле фәннәрне ана телендә уку мөмкинлеген тудыру югары дәрәҗәдә кирәкле дип саныйбыз. Бу педагогика университетында аеруча кирәк, чөнки без татар мәктәпләре өчен укытучылар хәзерлибез. Шуңа өстәп, фәннәрне татар телендә укыту студентларга (аеруча 1-2нче курс студентларына) вуз системасына тизрәк җайлашырга, фәннәрне тирәнрәк үзләштерергә, дәресләрдә үз белемнәрен тулырак күрсәтергә, имтиханнарны яхшырак тапшырырга мөмкинлек бирә.

ГЕОГРАФИЯ ФӘНЕН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ УКЫТКАНДА РУСЧА-ТАТАРЧА АҢЛАТМАЛЫ-БЕЛЕШМӘ СҮЗЛЕКНЕҢ КИРӘКЛЕГЕ ҺӘМ АНЫҢ БҮГЕНГЕ КӨН ӨЧЕН ӘҺӘМИЯТЕ

Җ.А. Хөсәенов

(Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты)

XXI гасырның башында дөнья картасында зур үзгәрешләр барлыкка килде. Элеккеге эре колонияләр калмады, дәүләтләр

саны бермә-бер артты. Аерым дәүләт, шәһәр, регионнарның атамалары алмашынды. Соңгы дәвердә илебездә зур үзгәрешләр булды: СССР дәүләте таркалды, социализм илләре системасы юкка чыкты, нәтиҗәдә дөнья картасында мөстәкыйль дәүләтләр барлыкка килде. Территориаль бүленеш ягыннан Россиянең үзендә дә үзгәрешләр бик күп. Өр-яңа физик-географик, сәяси-хакимият бүленешләре барлыкка килде, элеккеге атамалар телдән төште. Шулай итеп, география фәне зур үзгәрешләр кичерде.

Шуларны истә тотып, географиядән русча-татарча сүзлек төзү мәсьәләсе килеп басты. Әлбәттә, элекке елларда басылган сүзлекләр бүгенге көн таләпләренә һич кенә дә җавап бирми башладылар.

Шуннан чыгып, шәхсән үзем географик сүзлек төзү эшенә керештем. Сүзлек яхшы белешмәлек булсын һәм әһәмиятле термин-атамаларны үз эченә алсын өчен зур көч түгәргә туры килде. Дөньякүләм, илкүләм әһәмияте аз булган географик объект, төшенчә, аңлатмаларны сүзлеккә кертмәскә тырыштым. Аның эчтәлеген билгеләгәндә югары уку йортларының укыту-белем бирү программаларын истә тоттым. География фәне белән нык бәйләнештә булган геология, топография, геодезия, метеорология, экология һ.б. фәннәргә караган термин һәм аңлатмаларга киң урын бирдем. «Туган ягыбыз – Татарстан» географик программа материаллары искә алынды. Татар әдәбиятында, матбугатында, татарча алып барылган радио-телевидение тапшыруларында еш кулланыла торган географик атамаларның, терминнарның язылышы, яңгырашына да әһәмият бирелде. Топонимик мәгълүматлар да урын алды, ләкин күпчелек географик атамаларның килеп чыгышы бәхәсле һәм фикер төрлелеге күп. Сүзлеккә дөньядагы барлык дәүләтләргә һәм аерым дәүләтләргә караган кече биләмәләр (колонияләр) турында да мәгълүматлар керде. Биредә аерым илләрдә яшәүчеләрнең саны, илнең мәйданы, дәүләт төзелеше, икътисады, экспорт һәм импорт структурасы, сәүдә итүче илләре, тимер юллар озынлыгы һәм кораллы көчләре хакында да белешмәләр табарга мөмкин. Халыкның тормыш дәрәҗәсен билгеләгәндә, бер елда җан башына күпме тулай милли продукция җитештерелүе АКШ долларында күрсәтелде. Сүзлектә Россия Федерациясенең унбер икътисади районы, җиде федераль округы, барлык субъектлары турында мәгълүмат урын алды, эре физик-географик, икътисади объектлар искә алынды. Аларның

физик-географик халәте, халык саны, экология шартлары һ.б. ягыннан кыскача характеристика бирелде.

Сүзлекне төзү барышында география һәм аңа янәшә торучы геология, топография, геодезия, экология, экономика һ.б. фәннәргә караган өр-яңа терминология мәсьәләләрен дә хәл итәргә туры килде. Дөньядагы барлык дәүләтләргә, регионнарга, өлкәләргә, районнарга караган микъдари мәгълүматларның иң соңгыларын кулланырга тырыштык, ләкин икътисадка караган мәгълүматлар тиз арада искерә баралар. Төрле чыганакларда мәгълүматларның төрлечә бирелүе дә эшне катлауландырды.

Шулай итеп, 4000 чамасы географик термин һәм атаманы үз эченә алган бу сүзлек «Географический русско-татарский толково-справочный словарь = Географиядән русча-татарча аңлатмалы-белешмә сүзлек» исеме белән басылып чыкты. Хәзерге заман фәннәре белән тыгыз бәйләнгән сүзлек үз укучыларын тапты, югары уку йорты студентлары, татар мәктәбе, көллият, гимназия һәм лицей укытучылары һәм укучылары география фәне буенча даими файдалана торган китапка әйләнде.

ХЕЗМӘТТӘГЕ ИМИНЛЕК ФӘНЕ ТАТАР ТЕЛЕНДӘ: ТЕЛ ҺӘМ ИМИНЛЕК БӘЙЛӘНЕШЛӘРЕ

Ә.Х. Җомагылов

(Казан дәүләт авыл хуҗалыгы академиясе)

Академиянең агрономия һәм механикалаштыру бүлекләрендә «Хезмәттәге иминлек» фәне татар телендә 1992 елдан укытыла башлады. Аннан соңгы елларда бу фән буенча татар телендә методик кулланмалар, 86 авыл хуҗалыгы һөнәренә караган куркынычсызлык күрсәтмәләре, төрле элмә такталар һәм плакатлар әзерләнде, практикум чыгарылды.

1998-2002 елларда Ә.Х.Җомагылов һәм Р.Г.Нуруллин җитәкчелегендә алты укучыбыз чыгарылыш проектларын татар телендә язып якладылар. Академия тарихында беренче булып «Татарстан Республикасының Арча районы Яңа Кенәр күмәк хуҗалыгында механизаторларның эш шартларын яхшырту һәм җирне чәчүгә әзерләү агрегатын төзелмәләү» дигән темага татар телендә диплом эше башкарылды һәм аны

Фәрит Нигъмәтҗанов уңышлы яклады.

Авыл хуҗалыгындагы технологик процесс һәм гамәлләрне (операцияләрне) ышанычлы башкаруда кешенең роле зур. Кеше алга куелган эшне кирәклек ягыннан кабул итеп, уңышлы башкарырга тиеш. Ләкин ул, дөрес булмаган максат куеп, процесста хата җибәрергә мөмкин. «Хезмәттәге иминлек» фәне «Тормыш иминлеге» фәненең төп өлеше булганлыктан, кешенең мөмкинлекләрен һәм хәлен бу фәндәге логик һәм шартлы билгеләр белән күрсәтеп тикшереп була.

«Кеше-машина-мохит» челтәрендә кеше ясаган хаталар төркемләнә. Монда ике төркем хаталар булырга мөмкин: кешене эшкә әзерләгәндәге хаталар һәм эш вакытындагы хаталар.

Беренчесенә керәләр: һөнәри фән туган телдә укытылмау; эштә чит телдә аралашу; процесс төзелеше һәм эшләү тәртибе турындагы мәгълүматлар чит телдә язылу; оештыру боерыкларының һәм күрсәтмәләрнең чит телдә башкарылуы; телне белмәү аркасында эшне куркынычсыз башкара алмау, шул сәбәпле эшкә алынмау һәм кертелмәү; Россия Федерациясендә өстенлекле эш теле урнаштырылу.

Икенчесенә керәләр: процесс төзелмәсе дөрес ясалмау; эшче хаталары; төзү һәм җыю хаталары; хезмәт күрсәтү хаталары; билгесез хаталар; тикшерү хаталары; боерыкның дөрес булмавы; оештыру хаталары; идарә хаталары.

Тел кешенең психофизиологик үзлекләренә бәйле. Тел кешенең саклану челтәрендә төп урынны алып тора. Чит телнең кешегә һәм тән тоемлагычларына тәэсире иминлек ягыннан әле тикшерелмәгән. Шулай ук, тел аша алынган хәбәрләр ир-атларның һәм хатын-кызларның нерв челтәрләренә, аларның эшчәнлекләренә, канның биохимик күрсәткечләренә, йөрәк-кан юллары челтәренә һәм башка челтәрләргә тәэсире турында мәгълүматлар матбугатта күренми. Галимнәр чит телдә гамәл кылуның стресска китерү мөмкинлекләрен, милли азчылык дип саналган халыкларга тәэсирен ачыкларга тиеш, дип саныйм.

Тел иң кирәкле һәм мөһим эш коралы. Ул яшәешнең иминлек нигезен тәшкил итә. Россия Федерациясендә «Тормыш иминлеге» фәне буенча чыгарылган дәреслекләрдә һәм уку әсбапларында бу мәсьәләләр төшереп калдырыла. Бу фәндә технологик процесста катнашкан кешенең куркынычсызлыгы эшнең оештырылуына, эчтәлегенә, хезмәт

шартларына һәм тирә-юнь мохиткә генә бәйләп өйрәнелә.

Бүгенге көндә академиядә укучыларны эшкә әзерләгәндә һәм алар эш башкарганда иминлек ягыннан хаталар булмасын өчен «Тормыш иминлеге» фәне буенча ике телдә башкарылган эш урыннары булдырылды. Хәзерге вакытта фән буенча дәреслек әзерләнгән. Дәүләт кануннары да татар телендә нәшер ителсәләр, бу фәнне укыту җайга салыныр дип өметләнәбез.

ГАМӘЛИ ДӘРЕСЛӘРДӘ ИКЕТЕЛЛЕЛЕК – ЮГАРЫ БЕЛЕМ БИРҮНЕ КАМИЛЛӘШТЕРҮ ЫСУЛЫ

С.Г. Мортазина, М.Г. Мортазин
(Казан дәүләт авыл хуҗалыгы академиясе)

Туфрак, табигать җисеме буларак, биосфераның бик мөһим чылбырын тәшкил итә. Бу җәһәттән туфрак белеме, биосфера турындагы фундаменталь фәннәрнең берсе буларак, бик зур тәрбияви һәм гамәли байлык чыганагы булып тора, экологик тәрбия эшендә һәм белем бирүдә аның урыны аерым әһәмияткә ия. Шунлыктан, бу фән авыл хуҗалыгы академиясендә хәзерләнә торган барлык белгечлекләрнең дә уку планнарына кертелгән.

Авыл хуҗалыгында туфракның сәнәгать чарасы буларак роленә аерым игътибар ителә, аның башка сәнәгать чараларыннан аермасы ассызыклана һәм туфракның бөтен яшәеш, кешелек һәм хайваннар дөньясының яшәү нигезен тәшкил итүе күрсәтелә.

Фактик материалларга таянып, гамәли дәресләрдә туфракның биосфера өчен әһәмиятле үзенчәлекләре, шул исәптән – санитар, энергетик, газ һәм су халәтен көйләү аспектлары күрсәтелә. Шулардан чыгып, авыл хуҗалыгы сәнәгатен әйләнә-тирә мохиткә якынлаштыру һәм экологик таләпләргә җавап бирә торган итеп оештыру зарурлыгы нигезләнә. Авыл хуҗалыгы культураларын игүнең хәзерге заман технологияләре һәм тирә-юньне оештыру, эшкәртү чаралары һ.б. барысы да экологик яктан нигезләнгән булырга тиеш. Алар гамәли дәресләрдә өйрәнелә, татарча үткәрелгән дәреслар студентларга бигрәк тә зур тәэсир ясый.

Теоретик дәресләр (лекцияләр) гамәли дәресләр белән бәйләп алып барыла. Туфрак белеменең гамәли дәресләре 5 бүлектән тора: геология, туфрак төзелеше (морфология), лаборатор эшләр, гамәли

хисап (туфракны яхшыртуның гамәли алымнары һәм аларны фактик нигезләү), җәдвәлләр буенча, агрохимик тасвирламаларга таянып һәм монолитлар буенча туфрак төрләрен танып белү. Һәрбер бүлек биремнәре өчен билге куела, уртача билге имтихан билгесе өчен нигез булып тора. Билгеләре югары булган студентлар имтиханнан азат ителергә, яки, теләкләре буенча, билгене тагын да яхшырту максатында имтихан бирергә мөмкин. Түбәндә китерелгән җәдвәлдән күренгәнчә, гамәли дәресләрне татарча укыту өлгерешкә уңай тәэсир итә (җәдвәлдә: * – рус телендә белем алучы группа, ** – ике телдә белем алучы группа).

Группа	Имтихан билгеләре (балларда)					
	Барлы -гы	Бик яхшы	Яхшы	Уртача	Түбән	Гомуми урта билге
2000-2001 уку елы						
194*	22	5	7	10	–	4,0
196**	17	7	8	3	–	4,3
2001-2002 уку елы						
103*	20	2	7	11	–	3,5
107**	17	3	11	3	–	4,0
2002-2003 уку елы						
112*	22	3	9	10	–	3,6
115**	25	2	17	6	–	3,9
2003-2004 уку елы						
122*	24	4	12	8	–	3,8
123**	19	5	8	7	–	4,0
2004-2005 уку елы						
135*	10	2	4	2	–	4,0
136**	18	2	8	2	–	4,0

АГРОНОМИЯ ФАКУЛЬТЕТЫНДА ТУФРАК БЕЛЕМЕ ФӘНЕН ИКЕ ТЕЛДӘ УКЫТУ ТӘҖРИБӘСЕ

С.Г. Мортазина

(Казан дәүләт авыл хуҗалыгы академиясе)

Югары уку йортларында тар белгечлекләрне ике телдә укыту мөмкинлеге ачылу белән, туфрак белеме фәнен ике телдә укыту методикасын төзү һәм аны камилләштерү эшен башладык. Рус телендә бу фәнне укыту программасы бар һәм зур тәҗрибә туплаган. Безнең методика шушы программадан чыгып үзебезнең шартларга

яраклаштырып төзелде. Әмма татарча укыта башлау бу методиканы үзгәртүне һәм камилләштерүне көн тәртибенә куйды.

Иң әүвәл максатны билгеләдек – ике телдә белем бирү белемне үзләштерүне яхшыртырга, татар телле студентларның рус мохитенә яраклашуын тизләтергә һәм, иң мөһиме, белем бирүнең һәм алуның, уку-укытуның сыйфатын яхшыртырга тиеш.

Туфрак белеме фәнен ике телдә укыту-уку мөмкинлеген җентекләп өйрәнеп, анализ ясау нәтиҗәсендә эчке мөмкинлекләрдән чыгып махсус методика төзелде. Татарча укытуга күчү процессы берничә этапка бүленде, чөнки, югарыда әйтеп үтелгәнчә, татарча дәреслекләр, ярдәмлекләр, уку әсбаплары, методик кулланмалар һәм, ниһаять, русча-татарча терминологик сүзлекләр булмау татарча укытуга кискен генә күчергә мөмкинлекләр бирми генә түгел, белем алу сыйфатына начар йогынты ясарга да мөмкин. Шуңа күрә ике телдә дә параллель яки аралаштырып укыту ысулын кулай таптык. Бөтен курс берничә блокка бүленә, шуларның кайсы татарча, кайсы русча укытыла.

Лекцияләрне татарча укуга күчү шулай ук эзлеклекне таләп итә. Шунлыктан без лекцияләрнең бер өлешен (туфрак белеменең махсус өлеше – туфрак төрләренең ясалышы, үзенчәлекләре, географиясе, кулланылышы) татарча укысак, гомуми туфрак белеме русча укытыла. Шушындый эзлеклекне без тар белгечлекләр буенча татарча укытуга күчүдә мөһим адым дип саныйбыз, чөнки ул студентларның да, укытучыларның да психологик һәм матди әзерлеген арттыра. Студентларның курс эшен татарча мөстәкыйль башкара алуы һәм башкаруы – бу инде татарча уку-укыту процессының сыйфаты яхшы булуын дәлилли, укытуны тагын да югарырак баскычка күтәрә. Ул студентның татарча мәгълүмат үзләштерә алу мөмкинлеген генә түгел, шушы мәгълүматны иҗади кулланып, татарча фикерләү сәләте ачылуын һәм аның фәнни-практик һәм иҗади мөмкинлекләренең үсешен дә күрсәтә.

Туфрак белемен өйрәнү имтихан тапшыру белән тәмамлана һәм, кагыйдә буларак, курс эшен яхшы башкарган студентлар имтиханда да төпле белемнәре булуын раслыйлар. Имтиханда сорауларга җавап бирү, студентларның теләге һәм тел хәзерлегенә карап, ике телдә (русча яки татарча гына), яки русча-татарча булырга мөмкин. Әгәр студент татарча укып та сөйләргә кыенсына икән, русча гына сөйли ала. Биш еллык тәҗрибә шуны күрсәтә:

татарча уку студентларга белемнәрне яхшырак үзләштерергә, фикерләү сәләтен үстерергә ярдәм итә һәм, гомумән, белем алуның сыйфатын яхшырта.

Җыеп кына әйткәндә, тар белгечлекләр әзерләүдә ике теллелекнең аерым методик кыенлыклары, үзенчәлекләре бар, бу өлкәдә алгарыш ясау өчен укыту методикасын һәрдаим камилләштерү зарур һәм эзләнүләр туктаусыз дәвам ителергә тиеш.

КЕШЕНЕҢ ПСИХОЛОГИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕН ИСӘПКӘ АЛЫП ХАЛЫК ПЕДАГОГИКАСЫН ЗАМАНЧА КУЛЛАНУ

Р.Г. Нуруллин, Р.Р. Нуруллин
(Казан дәүләт авыл хуҗалыгы академиясе)

Кеше алдында торган теләсә нинди мәсьәләне уңышлы чишү фикер эзлеклеген төзи белүгә кайтып кала. Фикер чылбырын дөрес итеп төзи белү логика һәм психология фәннәренә таяна. Логика һәм психология кагыйдәләрен белмәгән һәм аларны белеп тә дөрес кулланмаган кеше ялгыш нәтиҗәләр ясый. Соңгы чиктә бу хәл аерым бер кешенең язмышына да тәэсир итәргә мөмкин.

Логикага нигезләнеп фикер йөртә белү сәләтен кешедә кече яшьтән үк тәрбияләргә кирәк. Моның өчен балаларны логик һәм психологик мәсьәләләр чишәргә өйрәтү файдалы булыр иде. Логик мәсьәлә буларак, балаларга төрле башваткычлар тәкъдим итәргә була. Башваткычлар чишү балаларның кече яшьтән үк фикерләү сәләтен үстерә, тормышлары табигать белән, алар янында яшәүче башка затлар белән бербөтен булуын аңларга өйрәтә. Ә инде мәсьәләнең чишелешен табу балага рухи ләззәт китерә, үз көченә ышану тойгысын арттыра һәм кыенлыкларны җиңәргә күнектерә.

Ләкин татар мохитенә туры китереп төзелгән логик мәсьәләләр бик аз, психологик мәсьәләләр юк диярлек. Халык педагогикасына таянып, татар халкы мәдәниятенең үзенчәлекләрен исәпкә алып, мәсьәләләрне метафоралар, мәзәкләр һәм әкиятләр рәвешендә бирү, бигрәк тә андый мәсьәләләрне шигъри калыпларга салу – баланың һәрьяклы үсешенә китерә. Аның тел байлыгы, акыл зирәклеге, эстетик һәм психологик зәвыгы, үткенлеге арта. Баланың, аң үсеше белән

берроттэн, туган теленә, туган ягына, якыннарына һәм туганнарына мәхәббәте дә ныгый. Ул башка шәхесләрне дә ихтирам итәргә күнегә.

Яшь чагында алган күнекмәләр татар егетләренең һәм кызларының югары уку йортларына керү, аларны уңышлы тәмамлау һәм тормышта зур нәтиҗәләргә ирешү мөмкинлеген арттыра.

ТАТАР ТЕЛЕН ДӘҮЛӘТ ТЕЛЕ БУЛАРАК УКЫТУНЫҢ КАЙБЕР НИГЕЗЛӘРЕ

Л.М. Сәмигуллина
(Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте институты)

XX гасырның 90нчы елларында сәяси өлкәдә барган яңарышлар эчендә Татарстан Республикасында телләр турында закон кабул ителә. Бу закон нигезендә татар һәм рус телләре дәүләт телләре дип игълан ителә. Тик, шулай да, татар телен куллану даирәсе әле сизелерлек чикләнгән. Бүген ике дәүләт теле дә тигез дәрәҗәдә кулланылсын өчен, беренчедән, республикада барлык дәүләт оешмаларындагы хезмәткәрләргә ике телне белү зарури булуын, икенчедән, эш кәгазьләренең ике телдә алып барылуын таләп итү кирәк. Бу таләпләр үтәлгәндә татар теленең дәрәҗәсе тагын да күтәреләчәк.

Татарстан Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте институтында татар теле дәүләт теле буларак укытыла. Институтта «Татарстан Республикасы телләре турында»гы Закон нигезендә төзелгән һәм расланган укыту программасы булдырылды. Бу программа татар һәм рус төркемнәре өчен махсус эшләнде.

Татар телен үзләштерүче рус телле студентлар татар теленнән мәктәптә алган белемнәрен бер семестр дәвамында гамәли рәвештә активлаштыралар, дәүләт хезмәтендә татар телен куллану процессында очрый торган актив нигез әйләнмәләрне, терминнарны үзләштерү юнәлешендә күнекмәләр алалар.

Икенче семестрда студентлар эшлекле татар теле курсын өйрәнәләр. Нигездә, бу курста төрле эшлекле очрашуларны чагылдырган текстлар, танылган дәүләт хезмәткәрләренең эшчәнлеген тасвирлаган өзекләр бирелә. Мәсәлән, киңәшмә

үткәрү турында текст, яки М.Ш. Шәймиевнең эшчәнлеге турында язмалар алына, аның хезмәт портретын чагылдырырлык материаллар сайлана.

Беренче гамәли дәресләрдә үк студентлар Татарстан Республикасының Телләр турындагы законын өйрәнә. Маддәләрнең төзелешен, гомуми эчтәлеген татар әдәби телендә аңлата. Законның теленә, текстта кулланылган терминнарга анализ ясый. Татарстан Республикасында телләрнең үзара мөнәсәбәтен билгели. Татар һәм рус телләрен куллану сферасын күзәтә.

Махсус кертелгән эшлекле татар теле курсы дәүләт структураларында татар телен куллану мөмкинлекләрен төшендерә. Бу курста эшлекле әңгәмә кору, киңәшмә үткәрү төрләренә басым ясала, татар телендә чыгыш ясау, аның текстын төзү формалары аңлатыла, рәсми эш кәгазьләренең төзелеше, тел үзенчәлекләре өйрәтелә.

Гомумән, эшлекле татар теле курсын үзләштерүче рус телле студентларга татар телен тирәнтен өйрәнү, бу телдә иркен аралашу, эшлекле аңлашу өчен кирәкле тел берәмлекләрен үзләштерү бурычлары куела.

Шунысы әһәмиятле: бүгенге көндә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте институтында рус телле студентларның күбесе татар телендә аңлап сөйләшә, аралаша, эшлекле әңгәмәләр кора, фәнни чыгышлар ясый. Бу күренеш студентларның үзләрендә теләк туудан һәм укыту программалары камиллегеннән барлыкка килә дип бәяләнә.

БУЛАЧАК ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ СӨЙЛӘМ КУЛЬТУРАСЫН ҮСТЕРҮ – ТАТАР ТЕЛЕН ӨЙРӘНГӘНДӘ КОММУНИКАТИВ КОМПОНЕНТ

С.В. Вьюгина

(Казан дәүләт технология университеты)

Казан дәүләт технология университеты Россия һәм Татарстанда гына түгел, бәлки бөтен дөньяга билгеле абруйлы уку йортларының берсе. Бу профессиональ уку йортының тарихы йөз елдан артык булган уку-укыту эшчәнлеге бар. Заман үзгәргән саен, югары белем бирү өлкәсендә дә студентларны укытуга булган

таләпләр дә үзгәрә. Казан дәүләт технология университетында, хәзерге заман таләпләренә туры китереп, техник белгечлекләр белән беррәттән «Дәүләт һәм муниципаль идарә итү» һәм «Социаль хезмәткәр» белгечлекләре буенча дәүләт хезмәткәрләре дә әзерләнә. Белем алырга теләүчеләр арасында бу белгечлекләр буенча конкурс иң югары.

Беренче курстан ук безнең студентлар үзләренең уку сәләтләрен төрле формадагы уку программалары аша тикшерә алалар. Булачак дәүләт хезмәткәрләре икенче дәүләт теле булган татар телен бик теләп өйрәнәләр. Сөйләм культурасын үстерү безнең фәнни-методик эшебездә зур урын алып тора. Мәгълүм ки, студентлар традицион дәресләрне, тәрҗемә эшләрен бик яратып бетермиләр. Шуңа күрә без, еш кына, татар теле дәресләрендә яңа проектларны тормышка ашырабыз. Алар төрле: сөйләм миниатюраларын төзү, телевидение дикторына конкурс, булачак депутатның сайлау алды программасын тикшерү һ.б. Төрле бәйгеләр оештыру, булачак һөнәрләрен үзләштерү буенча проблемалы дәресләр уздыру, студентларга белем бирүдән тыш, аларның сөйләм культурасын яхшырта, аудиториядә үзләрен тотарга өйрәтә. Сөйләм культурасына өйрәткәндә профессиональ культураны үстерүгә дә зур урын бирелә.

Яшьләр татар телен мәктәптә ун ел дәвамында өйрәнсәләр дә, кызганычка каршы, белемнәре бик сай, сөйләм культурасы юк дәрәҗәсендә. Ә сөйләм культурасы, педагогик күренеш буларак, сүз запасын файдаланудан тыш, язма һәм әдәби телне куллануны да үз эченә ала. Шуңа күрә студентларның сөйләм культурасын үстерү безнең кафедрада иң алдынгы юнәлешләрнең берсе булып тора. Бу коммуникатив компонент булачак дәүләт хезмәткәренең профессиональ культурасын да күрсәтә бит. Профессиональ культура сөйләм культурасы белән янәшә үстерелә һәм ул дискуссиядә катнашканда, эшлекле сөйләшүләр вакытында үзеңне тоту, төрле контрактлар, шартнамәләр, килешүләр төзегәндә файдаланырга тиеш.

Булачак дәүләт хезмәткәрләренә татар телен өйрәткәндә татар халык педагогикасы традицияләренә дә таянып эш итәбез. Халык авыз иҗатын өйрәнүдән тыш без классик һәм хәзерге буын татар әдипләренең әсәрләренә дә мөрәҗәгать итәбез. Чөнки, безнең уйлавыбызча, мәктәп программаларында татар әдәбиятенә

бик аз урын бирелгән. Студентлар татар язучыларының әсәрләрен генә түгел, аларның исемнәрен дә белмиләр. Бу бушлыкны бетерү өчен без, икенче семестрдан соң, студентларга татар язучыларының әсәрләрен тәкъдим итәбез. Алар, теләгәнен сайлап алып, үзлекләреннән авторның биографиясен, әсәрнең язылу тарихын өйрәнәләр, төркем алдында әсәрнең эчтәлеге буенча чыгыш ясыйлар. Исемлеккә татар халкының язмышын чагылдырган әсәрләр кертелде. Бирелгән әдәбият белән студентлар бик теләп танышалар. Безнең уйлавыбызча, булачак дәүләт хезмәткәрләре татар халкының мәдәниятен, тарихын, әдәбиятын белергә тиешләр.

ЮГАРЫ УКУ ЙОРТЫНДАГЫ КҮПТЕЛЛЕЛЕК ШАРТЛАРЫНДА ТАТАР ТЕЛЕН ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫН УКЫТУ ТОРЫШЫ

Р.Ш. Хөрмәтуллина
(Кама дәүләт инженер-икътисад академиясе)

«Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законы кабул ителгәннән соң, югары уку йортларында укучыларны татар теленә өйрәтү һәм фәннәрне татарча укыту эше берникадәр җайга салынды.

Кама дәүләт политехника институты укытучылары бу эшкә республикада беренчеләрдән булып алынды. Институтта фәннәрне татар телендә укыту буенча методик кабинет ачылды, ә чит телләр кафедрасы укытучылары 1993/94 уку елыннан башлап икътисад факультеты студентларына 1998/99 уку елыннан барлык факультет студентларына да татар телен һәм әдәбиятын укыта башладылар. Бүгенге көндә кафедраның татар теле һәм әдәбияты секциясе иң дәрәҗәлеләрдән санала.

Хәзерге техник казанышлар чорында яшьләргә тел өйрәтү шактый четерекле мәсьәлә булып тора һәм укытучы-тәрбиячедән үзенең бөтен булган осталыгына таянып эшләүне сорый. Техник югары уку йортында укучылар белән эш итүнең барлык үзенчәлекләрен дә исәпкә алсак, укытучы алдына куелган таләпләр тагын да катлаулана төшә. Төгәл фәннәрнең «коры» теленә күнеккән аз сүзле студентларны ничек итеп аралашырга, үз фикерләрен тулы, матур итеп ике телдә дә җиткерергә өйрәтергә?

Укытуга бирелгән сәгатьләрне арттыру хисабынамы?

Мәсәлән, безнең Кама дәүләт инженер-икътисад академиясендә 1993 елдан алып 1998 елга кадәр тел өйрәнү өчен бирелгән сәгатьләр саны 102гә җитеп, студентлар татар теленнән имтихан тапшырып чыгалар иде. 1998/99 уку елыннан башлап барлык факультет студентларына татар телен сайлап алып уку мөмкинлеге бирелде, ләкин сәгатьләр саны күпкә кимеде һәм курслар зачет тапшыру белән тәгәлләнә башлады. Соңгы өч уку елында исә, милли төбәк компоненты буларак, татар телен өйрәнү икътисад һәм автоматлаштыру факультетларында гына мәҗбүри программага кертелеп, бу эшкә 68 сәгать бирелә башлады. Төзелеш факультетында укучы студентлар сайлап алу мөмкинлегеннән дә мәхрүм. Билгеле, тел өйрәнү өчен 68 сәгать бик аз. Чөнки күп еллар дәвамында мәктәпләрдә татар теле барлык укучыларга да укытылган булуга карамастан, студентлар арасында татар телен бөтенләй белмәүчеләр яки бик начар белүчеләр күп. Шул ук вакытта, татар телен ана теле итеп санаучыларның да телне белү дәрәҗәләре төрлечә. Шунлыктан, бер төркем эчендә дә татар телен берничә программа буенча укытырга туры килә. Мәсәлән, телне өйрәнә генә башлаучылар өчен программа көндәлек тормышта кирәкле 10-12 сөйләшү темасын эченә алып, монологик һәм диалогик сөйләм күнекмәләре булдыруны максат итеп куя. Татар теле дәресләре лекцияләр һәм гамәли семинарлар рәвешендә үткәрелә. Дәрестә грамматик категорияләр, лексик берәмлекләр сөйләм ситуациясенә кертеп карала, дөрес сөйләм төзү һәр эш төренең төп максаты булып тора. Студентлар алдына үтелгән сөйләм темаларын һәм грамматик материалны дөрес итеп куллана белү бурычы куела.

Югарыда билгеләп үтелгәнчә, техник югары уку йортында татар теленә өйрәтүнең төп максаты – студентларны фикерләрен дәүләтнең ике телендә дә оста итеп җиткерергә өйрәтү. Мондый шартларда игътибар үзәгендә, һичшиксез, үзенең сәләте, белеме, карашлары һәм фикерләре белән укучы шәхесе тора. Укытучы өстенә шул шәхестә төрле алымнар белән телне өйрәнүгә кызыксыну уяту йөкләнә. Бу очракта төрле инновацион методлар кулланып эш итәргә туры килә. Тәҗрибәләр күрсәткәнчә, өйрәнелә торган темаларны эшлекле уеннар, бәйрәмнәр формасында бирү яхшырак нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек тудыра.

Чит телләрне өйрәнүдә уен формасын куллану, гомумән, актив метод булып санала һәм көннән-көн киңрәк тарала. Методик кулланмаларда уеннар эшлекле уеннарга (идарә итү, оештыру, хөкем итү һ.б.) һәм рольләргә бүлеп уйнауга (сәхнәләштерү) бүлеп карала. Уен – ифрат дәрәҗәдә җитди һәм иҗади эш. Бу очракта укучыга, тел күнекмәләре алу белән беррәттән, көндәлек кулланылышта булган әдәп кагыйдәләрен дә, алдагы тормышына кагылышлы һөнәри күнекмәләрне дә алу мөмкинлеге туа. Шунлыктан, мондый уеннарны тирәнтен уйлап планлаштыру һәм оештыру зарур.

Әдәби китаплар, татарча газета-журналларны бик сирәк укучы татар яшьләрен ничек итеп саф татарча сөйләштерергә, аларда туган якка, туган телгә, татар халкына карата мәхәббәт һәм горурлык хисләре тәрбияләргә соң? Шәхсән үзебез соңгы ике елда татар телле студентларыбыз белән татар халкының изге урыннары, татарлар һәм татар мәгърифәте, Татарстан республикасы, туган як шәһәрләренә һәм районнарына багышланган текстлар укып (бүгенге көндә аларны дәреслек итеп туплау бара), текстларның эчтәлеген сөйләтү өстендә эшлибез. Студентларыбыз өстәмә материаллар табарга да ярдәм итәләр.

Бу юнәлешкә кереп китәргә безне нәрсә этәрде соң? 10-15 еллар элек татар телле укучылар татар теле һәм әдәбияты дәресенә, ә рус телле укучылар туган якны өйрәнү дәресенә керәләр иде. Шулай итеп, татар телле студентларыбызның бүгенге көндә туган як тарихын азрак белүләре сизелә башлады. Хәтта «Татарстанда ничә шәһәр бар?» дигән сорауга да дөрес җавап алуы бик авыр. «Башта Болгар дәүләте булганмы, Алтын Урдамы?» кебек сораулар да җавапсыз кала.

Шул рәвешле, туган якка, татар халкына, аның тарихына багышланган текстларны укытып, сөйләтеп, тәрҗемә иттереп, сорауларга җаваплар бирдертеп, ике куянны берьюлы атарга омтылыш бар-барын, ләкин болар барысы да тәҗрибәләр генә. Эшнең нәтиҗәсен вакыт күрсәтер.

Татарстан Республикасында татар телен үстерү буенча эшне җәелдергән чорда академиягә укырга керергә теләүчеләрнең татар телендә имтихан тапшыра алмавы күңелне борчый. Әле берничә ел элек кенә без кабул итү имтиханнарын ике телдә дә үткәрүебез белән горурлана идек. Югыйсә, имтиханнарны ана телендә

тапшырырга телəгəн татар балалары кимемəде. Тестлар төзү, компьютерга кертүгə килгəндə, бу һич тə кулдан килмəстəй эш түгел. Аңа безнең мөмкинлеклəребез җитəрлек. Яулаган казанышлардан чигенмəскə иде бит.

ТАТАР ТЕЛЕН УКЫТУНЫҢ ҺƏМ ИКЕ ДƏҮЛƏТ ТЕЛЕНДƏ БЕЛГЕЧЛƏР ƏЗЕРЛƏҮНЕҢ ТОРЫШЫ ТУРЫНДА

Ф.Г. Галлəмов

(Алабуга дəүлəт педагогия университеты)

Алабуга дəүлəт педагогия университетының филология факультетында белгечлəр əзерлəү Татарстан Республикасының ике дəүлəт телендə алып барыла. Бүгенге көндə татар филологиясе факультетында дүрт бүлек (рус-татар, татар-рус, татар-чит теллəр, татар бүлеклəре) уңышлы гына эшлəп килə. Факультетның барлык бүлеклəрендə дə татар теле һəм əдəбиятына караган фəннəр, педагогиканың кайбер бүлеклəре татарча укытыла, ə рус филологиясенə караган һəм башка фəннəр рус телендə алып барыла. Соңгы елларда филология факультетының укыту планына бүгенге көндə актуаль булган махсус курслар кертелде. Мəсəлəн, «Рус телле балаларны татар теленə өйрəтү методикасы», «Татар телен укыту теориясе һəм методикасы», «Рус телле мохиттə татар теле» һ.б. Рус-татар һəм татар-рус бүлеклəрендə тəрҗемəчелəр əзерлəү башланды.

Татар теле кафедрасы эшчəнлегенең төп юнəлеше – Татарстан мəктəплəре һəм татарлар күплəп яши торган башка төбəклəр өчен төпле белемле татар теле һəм əдəбияты укытучылары əзерлəү. 2003-04 уку елыннан башлап, Россия Федерациясенең татарлар күплəп яши торган төбəклəре өчен, татар теле һəм əдəбияты укытучыларын əзерлəү максатыннан, махсус төркем булдырылды.

Татар теле кафедрасы мөгаллимнəре барлык факультетларда да татар теленə өйрəтү дəреслəре алып баралар. Нинди миллəт вəкиле булуга карамастан, барлык студентлар да татар телен өйрəнəлəр. Факультетларның укыту планына яраклы рəвештə кафедра мөгаллимнəре тарафыннан укыту программалары төзелде, аларда белгечлек үзенчəлеклəре

дә истә тотылды. Милли төбәк компоненты буларак, барлык факультет студентлары да «Татарстан Республикасының тарихы һәм мәдәнияте» курсын өйрәнәләр. Татар телендә укыту тарих-филология, биология, физика-математика, техника-экономика факультетларында берәр академик төркемдә алып барыла. Абитуриентлар үзләренең теләкләре буенча кабул итү имтиханнарын татар телендә дә тапшыра алалар.

Татар теле кафедрасы соравы буенча, Алабуга дәүләт педагогия университеты китапханәсе даими рәвештә татар телен интенсив өйрәнү буенча китаплар һәм кулланмалар белән тәэмин ителеп тора. Кафедра мөгаллимнәре тарафыннан татар телен интенсив өйрәнү буенча укыту-методик кулланмалар чыгарыла. Рус телле аудиториядә эшләү өчен кирәкле әдәбият белән кафедра тулысынча тәэмин ителгән. АДПУ китапханәсе Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты бушлай бүлеп бирә торган китаплар белән дә тулылана. Китапханә фонды рус телле төркемнәрдә татар телен өйрәтү методикасы һәм кайбер фәннәрне татарча укыту буенча да кирәкле китаплар белән даими рәвештә тулыландырылып тора.

Шулай итеп, Алабуга дәүләт педагогия университетында татар телен интенсив өйрәнү һәм Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә белгечләр әзерләү буенча максатчан эш алып барыла.

РЕГИОНАЛЬ ЧЫНБАРЛЫККА НИГЕЗЛӘНЕП ТАТАР ТЕЛЕН УКЫТУ

Н.Х. Шарыпова
(Казан дәүләт авыл хуҗалыгы академиясе)

Җәмгыятьтә булган үзгәрешләргә нигезләнеп, һәр телнең заманча халәте билгеләнә. Яңа чынбарлыктан караганда, соңгы 15 ел телләр үсешенә нык тәэсир ясады.

1989 елдан 2006 елга кадәр Татарстан җирлегендә яшәүче халыкларның телләрен саклау, өйрәнү өчен актив рәвештә уңай шартлар булдырылды, төрле чаралар үткәрелде. Бу чаралар Республиканың иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормышында татар теленең ролен һәм әһәмиятен шактый күтәрде.

Телнең тулы мәгънәдә функциядә булуы бик күп шартларга бәйле. Теманың актуальлеге 2006-13 елларга хәтле кабул ителгән Тел турындагы дәүләт программасын тормышка гамәли яктан ашыру өчен төрле юллар эзләүне таләп итә.

Татар телен дәүләт теле буларак тормышка ашыруда җитди һәм мөһим рольне укыту процессы ала. Югары һөнәри белем бирү системасы шартларында телне өйрәтү алымнары һәм юллары яңартылып тора. Хәзерге чынбарлыкта куелган проблеманың нигезендә «ничек?» һәм «нәрсәгә?» өйрәтү – төп мәсьәләләрнең берсе булып тора. КДАХАда «Татар теле» программасы Татарстандагы телләр ситуациясен истә тотып, Татарстан җәмгыятенең социаль заказы нигезендә эшләнде, һәм ул уку курсы буенча төгәл максат куя. Студентлар белән эшләү дәверендә шушы программа һәрбер студентның белеменә, сәләтенә, яңа материал үзләштергәндә шәхси темпына, кызыксыну дәрәҗәсенә карап берникадәр җайлаштырыла. Шуны истә тотып, студентның шушы курс буенча шәхси уку программасына регуляр рәвештә төзәтмәләр кертелә. Аларның ирешкән нәтиҗәләренә анализ ясала, студент эшләнгән эше буенча укытучыга отчет бирә. Шуннан соң, укытучы белән берлектә үтәлмәгән эшләрне истә тотып, алдагы көннәргә яңа план төзелә.

Студентның укытучы белән хезмәттәшлек чорында (студент иң түбән активлыктан югарырак баскычка күчкәндә) реферат темасы сайлана һәм шул тема буенча ачыкланырга тиешле сораулар куела. Шуннан соң студент мөстәкыйль эшли башлый. Аның активлыгы нык күтәрелә, укытучы белән консультацияләр бары тик студентның инициативасы нигезендә генә үткәрелә башлый. Шулай итеп, студент әкренләп фәнни тикшерү эшенә кереп китә. «Татар теле» предметы аша бу фәнни эш филологик юнәлештә алып барыла, реферат язу, укыту барышында иҗади эш үтәү, студентларның фәнни конференциясендә, олимпиадаларда катнашу юлы белән тормышка ашырыла.

Шулай итеп, телне өйрәтүнең төрле ысулларын файдалану сөйләшеп аңлашуга гына кайтып калмыйча, студентларның фәнни тикшеренү күнекмәләренә, шәхес булып җитлегүләренә, белем дәрәҗәсен, үз-үзләрен үстерү сәләтен формалаштыруга һәм һөнәри осталыкларын үстерүгә шартлар тудыра.

ИКЕТЕЛЛЕЛЕК ГАМӘЛДӘ

Ф.Ф. Харисов
(Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты)

Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетында, Татарстанның дәүләт мөстәкыйльлеге турында Декларация кабул ителгәч тә, республика югары уку йортлары арасында беренчеләрдән булып, 1991-92 уку елыннан башлап ике яклы ике теллелек яки рус теле белән бергә рус һәм башка милләт телләрендә сөйләшүче студентларга татар теле укытыла башлады. Ул барлык факультетларның уку планына кертелде һәм нигездә 64 сәгатькә исәпләнгән программа буенча гамәлгә ашырыла.

Әйтергә кирәк, беренче елларны эш зур кыенлыклар белән барды. Сәбәбе – дәреслек, методик кулланмалар, күргәзмә әсбапларның һәм башка төрле уку-укыту кирәк- яракларының юк дәрәҗәсендә булуы. Өстәвенә, татар телен чит тел буларак башка аудиториядә укыту методикасы да эшләнмәгән һәм ул проблема бүген дә көн үзәгендә тора. Шуңа күрә башлангыч чорда рус телле студентларны беренче чиратта сөйләшергә өйрәтү урынына татар теле грамматикасын укыту кебек ялгышлыклар да булгалады.

Хәзер эш башкачарак тора. Университетның ике укытучысы рус мәктәбендә татар теле укыту методикасы буенча докторлык диссертациясе яклады, татар тел белеме, рус мәктәбендә татар теле укыту кафедралары каршында аспирантура уңышлы эшләп килә: 6 кеше диссертация яклады, 4 кеше эшләрен йомгаклап килә, ике аспирант рус мәктәпләрендә татар теле укыту проблемаларын төрле яклап өйрәнәләр, ягъни бу өлкәдә фәнни эзләнүләр дәвам итә. Икенчедән, бу курсны алып баручы укытучылар үзләре дә фәнни-методик, гамәли тәҗрибә тупладылар һәм аны көндәлек эштә уңышлы файдаланалар. Өченчедән, рус аудиториясендә татарча сөйләшергә өйрәтү өчен шактый күләмдә төрле программалар, ярдәмлекләр, сөйләүлекләр, сүзлекләр дөнья күрде (кайбер авторларны гына санап китәбез: Ф.А. Ганиев, Р.А. Йосыпов, К.Р. Галиуллин, Г.Ш. Әсәдуллин, Н.Х. Салихова, Ф.Ф. Харисов, Ч.М. Харисова, А.Ш. Йосыпова һ.б.). Нәтиҗәдә, укытучыларга фәнни-методик әдәбият сайлап алу мөмкинлеге туды. Дүртенчедән, 1995 елда Г.Ш. Әсәдуллин, Р.А. Йосыпов авторлыгында рус телле аудиторияне татар теленә өйрәтү буенча

программа һәм кулланма нәшер ителде. Авторлар билгеләвенчә, алар югары уку йортларында файдалану өчен төзелгән. Бу дөрестән дә шулай: кульязма хәлендә үк әлеге кулланма күпмедер дәрәҗәдә безнең университетта сынау да узды. Хәзер дә без аны бу мөһим эштә төп ярдәмлекләребезнең берсе итеп карыйбыз. Бишенчедән, әгәр дә укытучы төрле методик алынмалар белән бергә сөйләмгә яңа лексиканы кертә, диалог һәм монологлар төзегәндә күргәзмәлелек дигән төшенчәне онытмыйча, үзенең дәресләрендә аннан даими рәвештә файдалана икән, татар теленә өйрәтү, аеруча башлангыч чорда, күпкә нәтиҗәлерәк була. Андый мөмкинлекләр бүгенге көндә бар.

Рус аудиториясендә татар теленә өйрәтүнең төп бурычы – телне аралашу чарасы буларак программада каралган фонетик-лексик һәм грамматик минимум нигезендә көндәлек тормышта куллана алырдай итеп өйрәнү (коммуникатив принципны тормышка ашыру).

Татар теле дәресләренең төп максаты – студентларны татар сөйләмен дөрес итеп аңларга (тыңлап аңлау), сөйләм процессында катнашырга (кара-каршы сөйләшү), үзең күргән, ишеткән вакыйгалар турында яки укытучы биргән тема буенча сөйләшергә (монолог), дөрес итеп укырга, язарга һәм укыганны аңларга өйрәтү, икенче төрле әйткәндә, һәр дәрестә сөйләм эшчәнлегенең 4 төре буенча да биремнәр нигезендә аларда белем һәм күнекмәләр булдыру.

Дәрес материалын үзләштерүнең сыйфатын күтәрүдә фонетик, лексик, грамматик уеннарның әһәмияте зур. Мәсәлән, татар теленә генә хас сузык авазларны өйрәткәндә, студентларга үзләрен җырчы итеп хис итәргә тәкъдим ителә. Бу очракта укытучы дирижер вазыйфасын башкара. Өйрәнүчеләр берничә төркемгә бүленә һәм һәрберсенә авазлар бирелә. Студентлар, укытучы кушуы буенча, авазларны опера җырчыларына хас тавыш белән сузалар. Уен кызыграк чыксын өчен, әйттерү тәртибен үзгәртергә дә була. Укытучы дөрес әйтелешкә игътибар итәргә тиеш. Без дәресләребездә мондый алымнардан еш файдаланабыз.

Тәҗрибә шуны күрсәтә: рус телле студентларның сөйләм телен тыңлап аңлау, сөйләшү (диалог, монолог), белем һәм күнекмәләрен формалаштыру һәм үстерү – төп бурычларның берсе. Бу исә, үз чиратында, татар теле белән бергә язма сөйләмне дә тирәнтен үзләштерү өчен нигез булып тора.

ТӨРЛЕ СҮЗ ТӨРКЕМНӘРЕНЕҢ КИЛЕШ БЕЛӘН ТӨРЛӘНҮЕ

Ч.М. Харисова
(Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты)

Килеш категориясе телдәге исемнәрне башка сүз төркемнәре белән бәйли, алар арасында төрле грамматик мөнәсәбәтләр урнаштыра һәм аларны җөмлә кисәкләре итеп формалаштыра. Хәзерге вакытта татар әдәби телендә бу категория төгәл бер системаны тәшкил итә, аның алты формасы кулланыла. Һәр килешнең үзенә генә хас грамматик формасы (кушымчасы) һәм грамматик мәгънәләре бар.

Грамматик категория буларак, килеш категориясе, һичшиксез, предмет исемнәренә хас. Әмма татар телендә башка мөстәкыйль мәгънәле сүз төркемнәре дә (аваз ияртемнәреннән башка) килеш белән төрләнеп килә ала. Исемнән башка тагын нинди сүз төркемнәре, кайсы очракларда килеш белән төрләнә ала соң? Аларның килеш белән төрләнү яки килеш кушымчаларын кабул итү очраклары берничә.

1. Татар телендә күп кенә сүз төркемнәре – сыйфатлар, саннар, кайбер рәвешләр сыйфат һәм сан алмашлыклары, сыйфат фигыльләр, үзләре ачыклап килгән исем җөмлә эчендә кулланылмаганда *исемләшә,* ягъни төшеп калган исемнең барлык формаль күрсәткечләрен (күплек сан, тартым, килеш кушымчаларын) кабул итә. Мондый вакытлыча төрләнү – исемләшү, гадәттә, сүз төркемен үзгәртми, мәсәлән, сыйфат – сыйфат булудан, рәвеш – рәвеш булудан, алмашлык – алмашлык булудан туктамый. Бу күренеш сөйләмне стилистик яктан шомарта, җыйнакландыра. Мәсәлән: *Сөйләшкәндә төрле сүзләр очрый: **салкыны** бар, була **җылысы*** (И.Г.). ***Кайсыгызның** кулы җылы? – Бәйлисе бар йөрәкне* (Х.Т.). *Сүзен уйлап **сөйләмәүчеләрне** мин гомумән яратмыйм* (Г.Ә.). *Билгеле, укучыларның **күбесе** аны бик туры мәгънәсендә аңлаганнар* (Ә.Е.). Монда тагын шуны да истә тотыйк: рәвешләрдәге килеш кушымчалары исемләшүгә бәйле булмаска да мөмкин. Юнәлеш, чыгыш һәм урын-вакыт килешләренең кушымчалары конверсия юлы белән төрле сүз төркемнәреннән рәвешләргә күчкән сүзләрдә ешрак очрый. Мәсәлән: *бергә, яттан, башта, анда-монда* һ.б. рәвешләр.

Югарыда аталган сүз төркемнәре ачыклап килгән исем белән урыннарын алышканда да исемләшү күзәтелә, шуңа алар да килеш һәм тартым белән төрләнә: *Малайларның **берничәсе** балыкка китте.*

2. Телебездә лексик-семантик яктан предметлыкны белдермәсә дә, морфологик яктан исемгә охшаш сүз төркемнәре байтак. Исем алмашлыклары, исем фигыльләр, җыю саннары – шундыйлардан. Бу сүз төркемнәре дә килеш белән төрләнәләр һәм төрле җөмлә кисәкләре булып киләләр. Мәсәлән: *Гомерем **минем** моңлы бер җыр иде* (М.Җ.). ***Берәүләргә** тәхет җитмәгән гел, **берәүләргә** бәхет җитмәгән* (Ф.Я.). *Гүзәл үзенең нигә **килүен** дә онытты* (Г.Г.).

3. Үткән һәм киләчәк заман сыйфат фигыльләрдә эш, хәрәкәт мәгънәсе өстенлек иткәндә, еш кына килеш һәм тартым кушымчалары очрый. Бу очракны сыйфат фигыльләрнең исем фигыль мәгънәсендә кулланылуы дип тә билгеләргә мөмкин. Мәсәлән: *Олы юлның тузанын үзем күрдем **тузганын** (Җ.).*

4. Кайбер хәбәрлек сүзләрнең һәм бәйлекләрнең килеш кушымчалары белән кулланылуы да исемләшү күренешен хәтерләтә. Мәсәлән: *Куй, Ильяс, **юкны** сөйләмә* (М.Ә.). Килеш белән төрләнгән бәйлекләр килеп чыгышлары буенча сыйфатларны хәтерләтәләр. Бу турыда *-лы/-ле* кушымчаларының булуы искәртә. Мәсәлән: *Минем аның **хәтлене** күргәнем юк иде әле* (тау турында).

Шулай итеп, татар телендәге шактый сүз төркемнәре килеш белән төрләнә ала. Бу, беренчедән, исемләшүгә, икенчедән, исемне алыштыруга, өченчедән, исем фигыльләрдә исем билгеләре булуга, кайбер сыйфат фигыльләрнең исем фигыль урынында кулланылуына бәйле. Хәбәрлек сүзләр һәм сыйфатлардан килеп чыккан бәйлекләр дә еш кына килеш кушымчалары белән очрый. Бу да исемләшү күренешен хәтерләтә.

“ТАПКЫР” WEB-САЙТЫ

Р.М. Һадиев, Э.Ш. Хамизова, К.Р. Һадиев

(Казан дәүләт университеты)

Укучы, сәләтен танытканчы, үзен бу дөньяда табарга тиеш. Шул эшне башкару өчен районнардагы мәктәпләр белән тыгыз элемтәдә эшли торган, сәләтле укучыларны үстереп торучы оешма

булырга тиеш. Бу оешма ел буе даими эш алып барып, сәләтле укучыларны ачыкларга, аларны укытырга, ярышлар уздырырга тиеш. Бу эшне, нигездә, ИМКЦО РОО (район мәгариф бүлегендәге санаклы мәгълүмат эшкәртү-укыту үзәге) алып бара ала. Эшне тагын да киңәйтү өчен районнан чыккан, хәзер югары уку йортларында укучы студентларны җәлеп итәргә була. Кайсыдыр төбәктә зур кызыксыну туса – укытучыларны да, шул районнан чыккан галимнәрне дә җәлеп итәргә була.

Сәләтле балалар белән санак ярдәмендә читтән торып эшләүне ике өлешкә бүлергә мөмкин. Беренчесе – уй-фикерне ел буе интернет аша үстерү. Икенчесе – алдан алып барылган эшне ныгыту өчен сәләтле балаларны җәен ял итү урынына туплап, анда студентлар белән галимнәрне чакырып дәресләр алып бару.

Мондый эш 2003 елдан бирле Теләче районындагы сәләтле балаларның санаклы «Паскаленок-Тапкыр» җәйләвендә оештырыла. Тупланган тәҗрибә һәм белем белән конференцияләрдә, интернетта уртаклашабыз. Ел буе алып барылган эш Казан мәгариф бүлегенең www.kros.ru серверенда чагылыш таба.

Сайтта төрле фәннәр буенча мәгълүмат һәм түбәндәге электрон дәреслекләр бар:

• информатика буенча информатика нигезләре, мантыйкка һәм программалау теленә өйрәтү дәресләре;

• татар теле буенча сүзлекләр, җырлар, табышмаклар, мәкальләр;

• татар әдәбияты һәм язучылары турында мәгълүмат, татар теле дәреслекләре;

• татар тарихы буенча мәгълүмат;

• дин тарихы, гореф-гадәтләр, йолалар;

• математика, физика, экология, биология буенча мәгълүмат.

Санакка салынган дәресләрдә укучыларга гомуми кагыйдәләр бирелә, миссалар күрсәтелә, күнегүләр аша белем ныгытыла, белем тикшерелә, олимпиадага әзерлек үткәрелә.

Бу эшне Казан дәүләт университетының һәм Татар дәүләт гуманитар-педагогик университетының татар филологиясе, журналистика, ВМК факультетлары студенталары төрле формада алып баралар. ВМК студентлары курс, диплом эшләре итеп төрле программалар төзиләр. Филологлар һәм журналистика

факультеты студентлары информатика дәресләрендә җырлар, рефератлар язалар. Кайбер студентлар үз иҗатларын да шунда урнаштыралар. Шулай ук, бу эштә катнашкан укытучылар да үзләренең фәнни иҗатын шунда урнаштырып, уртаклашу мөмкинлеге алалар.

"Тапкыр" web-сайтына 3000 җыр, 15 укыту программасы, уннан артык диплом эше, тестлар кертелгән. Бөтен мәгълүмат интернетта 300 Мб хәтер алып тора. "Тапкыр" укучыларга татарча белем алырга, студентларга татарча эшләргә өйрәнергә, укытучыларга татарча мәгълүмат алмашырга ярдәм итә.

КҮПКАНАЛЛЫ ТЕЛЕКОММУНИКАЦИЯ СИСТЕМАСЫНА КАРАГАН ТЕРМИНОЛОГИЯ

А.Р. Биктимирова

(Казан дәүләт техника университеты)

А.Н.Туполев исемендәге Казан дәүләт техника университетының Радиоэлектроника һәм телекоммуникацияләр институты 1952 елдан бирле эшләп килә. Берничә төркем студентлар күпканаллы телекоммуникация системасы белгечләре булырга әзерләнә. Телекоммуникация – информация алмашу методларын, алым һәм технологияләр җыелмасын эченә алган фән тармагы.

Күпканаллы телекоммуникация системалары эре техник комплекс булып тора. Төрле электр сигналларын көчәйтү техникасын һәм теориясен, спектрларның киңлеген белү югары квалификацияле күпканаллы телекоммуникация системасы инженерлары өчен мәҗбүри таләп. Ул гына да түгел, бу белгечләр рус теле белән беррәттән татар телен дә үзләштерергә тиеш.

Татар теленә өйрәтү биш семестр буена ике дәрәҗәдә алып барыла: беренче дәрәҗә – рус телле студентларга, икенче дәрәҗә – татар студентларына. Сүзебез – татар студентлары, ягъни икенче дәрәҗәдә белем алучы студентлар белән алып барылган терминология эше турында. Татар әдәби теленең мөһим тармаклары белән бергә студентларга терминология нигезләре дә укытыла. Терминнарның татар телендә яңгырашын, кулланылышын студентларга җиткерү белгечлеккә нигезләнеп телне

өйрәтүдә гаять дәрәҗәдә отышлы алым санала.

Студентлар белән эш барышында безнең тарафтан төзелгән лексик модульләр телекоммуникация дигән яңа һәм әһәмиятле бер юнәлешнең терминологиясен эшләүдә мөһим адым булып тора. Техника терминнары буенча русча-татарча, гарәпчә-русча сүзлекләр бар. Әмма таррак белгечлек өчен әзерләнгән бу модуль (аның күләме сүзлеккә дәгъва итми) татар студентлары белән махсус терминологияне өйрәнүдә зур ярдәм итә.

Без, нигездә, фәнни тикшеренү нәтиҗәсендә туган терминнарны тәрҗемә аша кулланабыз. Әмма, төшенчә таләп иткән дөрес сүзне сайлаганда, кайбер терминнарны татар теленә тәрҗемә итмичә алу кирәк: *абонент, антенна, таймер, факс* һ.б. Бу сүзләргә татар телендә эквивалент сүз табарга омтылыш терминның мәгънәсен ялгыш аңлауга китерә.

Кайвакыт теге яки терминга бәйләнешле булган, ләкин термин булмаган сүзләргә дә юлыгыла. Андый очракта сүзләрне татар теленә тәрҗемә иткәндә кыенлыклар туа. Мәсәлән, *восприимчивость* сүзе. «Русча-татарча сүзлек»тә бу сүз *тиз аңлаучанлык, тиз төшенүчәнлек, зирәклек; тиз бирешүчәнлек* дип тәрҗемә ителгән. Тик *пульт* терминына *восприимчивость* сүзе ялганганда, әлеге татар сүзләре мәгънәләре белән туры килми, алар урынына *сизгерлек* сүзен кулланырга кирәк.

Үзер сүзне табып, ана теле чаралары ярдәмендә терминнар ясау эшебездә ешрак кулланыла. Мисаллар шактый: *двухсторонняя связь – икеяклы элемтә, высокочастотное колебание – югары ешлыклы тирбәнеш* һ.б. Терминнар арасында мәгънәне бозмыйча, гади генә тәрҗемә ителгәннәре дә бар: *волокно – җепсел, узел – төен* һ.б.

Кайбер терминнарны турыдан-туры татар сүзләре белән алыштыру мөмкинлеге булса да, чыганак телдәге вариантны куллану уңышлырак булган очраклар да шактый: *защитный интервал – саклау арасы* дип тәрҗемә ителә ала, ләкин *ара* сүзе урынына *интервал* сүзен калдыру терминның төгәлрәк булуына китерә.

Шулай итеп, термин ясауның барлык нечкәлекләрен тоеп эш итү терминологиянең үсүенә, баюына китерә. Ә күпканаллы телекоммуникация белгечлеге өчен төзелгән модуль татар терминологиясе үсешенә сизелерлек өлеш кертә.

ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ АҢЛАТМАЛЫ ЭЛЕКТРОН СҮЗЛЕГЕ

Р.Р. Имамов, З.М. Мифтахов, Р.Р.Вәлиев
(Казан дәүләт техника университеты)

Һәр милләтнең төрле сүзлекләре арасында аңлатмалы сүзлек мөһим урын алып тора. Мисал өчен – әйтемнәргә кергән «толковый словарь Даля», «толковый словарь Ожегова» кебек гыйбарәләрне китереп була. 1977-81 елларда чыккан 3 томлык «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» татар теле өчен шундый урында. Сүзлеккә барлыгы 32880 баш сүз, 14010 тезмә һәм фразеологик берәмлек теркәлгән. Рус телендәге аңлатмалы сүзлекләренең электрон версияләре инде күптән дөнья күрде. Берничә ел эшләү нәтиҗәсендә Jahat Lab., KAI һәвәскәр төркеме егетләре татар теленең аңлатмалы электрон сүзлеген дә эшләп бетерделәр. Бу программага «Anlatma» исеме бирелде.

Anlatma электрон сүзлеге 3 томлыкның барлык сүз хәзинәсен үз эченә алган. Кирәкле сүзне сул яктагы өске тәрәзәдә курсор белән әлифба буенча эзләп яисә сул яктагы аскы тәрәзәдә кулдан җыеп була. Билгеләнгән яисә җыелган сүзнең аңлатмасы уң яктагы тәрәзәдә килеп чыга. Шулай итеп, кирәкле сүзне өч зур томны актарып түгел, ә берничә секунд эчендә компьютерда табып була. Уңайлык өчен программада төрле функцияләр кертелгән. Мисал өчен, табылган сүзнең аңлатмасын оператив хәтергә кертеп тә, WORD яисә PageMaker программаларына кертеп тә була. Әлбәттә, программа интерфейсында эш тәртибе, чыганак китап, кулланылган кыскартмалар һ.б. мәгълүматлар да бирелгән. Программаның зурлыгы якынча 4 Мбайт тәшкил итә. «Anlatma» программасы Jahat™ программалар пакеты белән бергә эшли.

Мәгълүм булганча, профессор Ф.Ә.Ганиев җитәкчелегендәге редколлегия төзегән яңа «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» күптән түгел матбугатта басылып чыкты. Бу сүзлектә 52 мең мөстәкыйль сүз, 6 меңгә якын фразеологик берәмлеккә аңлатма бирелгән. Бу сүзлекне дә файдаланып, «Anlatma» электрон сүзлегенең яңа версиясе эшләнә башлады.

КОМПЬЮТЕРЛАРНЫ ТАТАРЧА-ЧУАШЧА ЛОКАЛЬЛӘШТЕРҮЧЕ ПРОГРАММАЛАР ПАКЕТЫ JAHAT™

Р.Р. Имамов, З.М. Мифтахов, Р.Ш. Басыйров, Р.Р. Вәлиев, Л.М. Воронина, К.А. Малышев
(Казан дәүләт техника университеты)

Үткән гасырның 90нчы еллар башыннан бирле Jahat Lab., KAI һәвәскәр төркеме тарафыннан үзешчән рәвештә алып барылган эшләр нәтиҗәсендә бүгенге көндә компьютерлар өчен татар һәм чуаш программалары эшләнде.

Татар теленең графикасы 1939 елда кириллицага күчерелгәннән бирле яшәп килгән татар клавиатурасы проблемасы махсус уйлап тапкан технология нигезендә уңышлы чишелде. Ул техник ысул Россия һәм халыкара патентлар алды (РФнең уйлап табуга патенты № 2107628; Бөтендөнья интеллектуаль милек оешмасы тарафыннан чыгарылган халыкара патент публикациясе № WO 97/07981, Женева; Евразия патенты № 000311; КНДР патентын бирүгә әзерлек карары № 33402).

Шушы уйлап табу нигезендә компьютерга татар клавиатура драйверы эшләнде. Башкаларныкын үзгәртеп ясау түгел, ә тулаем үзебез эшләнгән булу сәбәпле, ошбу программага да Россия патент оешмасы тарафыннан лицензия бирелде. Программаның исеме дә товар мөһере булып тора.

Татар текстларын җыйгач, хаталарны тикшерү өчен корректор программасы да эшләнде. Аңа «Идегәй» дастанындагы Субра карт исеме бирелде, әлеге программа да лицензия алды. Күптән түгел өч томлы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» нигезендә эшләнгән аңлатмалы электрон сүзлек «Anlatma» да дөнья күрде.

Болар өстенә төрле шрифтлар, конверторлар, кодлар һәм башка компьютер эшләре өчен кирәк-яраклар эшләнде, хәтта татарча уеннар да бар. Бүгенге көндә JAHAT™ программалар пакеты ерактагы авыллардан башлап хөкүмәт даирәләренә хәтле шактый күп оешмаларда уңышлы эшли. Аларны хәзер санап чыгу да мөмкин түгел. Шуны да ассызыклап әйтергә кирәк, бу оешмалар Jahat-не, бушлай булган башка татар программаларыннан баш тартып, акча түләп куялар. Күп оешмаларны бу программаны куюдан финанс хәле генә тоткарлый.

Татардан тыш, башка халыклар өчен дә программалар ясала. Чуаш клавиатурасы стандарты нигезендә компьютер өчен программалар да эшләнде. Бүгенге көндә Татарстанда чуаш телендә чыгучы биш газетаның дүртесе – «Сувар» (Казан), Буа, Норлат, Чүпрәле район газеталары менә инде берничә ел Jaһat™ программалар пакетында уңышлы эшлиләр.

ЯЗУ ҖАЙЛАНМАЛАРЫ ӨЧЕН ЧУАШ КЛАВИАТУРАСЫ СТАНДАРТЫ ПРОЕКТЫ

Р.Р. Имамов, К.А. Малышев

(Казан дәүләт техника университеты)

Татар клавиатурасы өчен кулланылган патентлы «Jaһat» технологиясе өстәмә хәрефләре булган башка халыклар телләре өчен дә бик уңай. Татарстанда биш газета чуаш телендә чыгуын исәпкә алып, Татарстан халыклары телләре турында Законны тормышка ашыру җәһәтеннән чуаш теле өчен дә компьютер программаларын ясау кирәк булды. Аның өчен иң элек чуаш клавиатурасы стандартын булдыру зарур. Башка чуаш программалары **ӑ , ӗ , ç , ӳ** кебек үзенчәлекле чуаш хәрефләрен клавиатураның 4нче өске рәтенә урнаштырганга, андагы сигез ярдәмче тамга юкка чыга. Шуңа күрә ул программалар ун бармак белән текст җыю методикасын кулланырга мөмкинлек бирми.

Чуаш клавиатурасы стандарты проектын эшләгәндә халыкара ISO/IEC 9995 һәм Россиянең ГОСТ 6431-75 клавиатура стандартлары исәпкә алынды. Рәсемнән күренгәнчә, тулаем алганда чуаш әлифбасының хәрефләре ГОСТ 6431-75 стандарты буенча урнаштырылган, әмма **щ,ъ,ж,ё** хәрефләре урынына чуашның

ç , ÿ , ă , ĕ хәрефләре куелган, **щ,ъ,ж,ё** хәрефләре исә шул клавишларның өстәмә регистрларына урнаштырылган. Аларның берәрсен куллану өчен алдан «Jahat» клавишы (ГОСТ буенча В00) басып алына (тотып торасы түгел!), аннары кирәкле клавиш басыла. Зур хәреф кирәк булса «Jahat» клавишын басып алганнан соң Shift яисә CapsLock басыла, аннары кирәкле хәреф клавишы. Кайсы гына билге клавишы басылса да, клавиатура өстәмә регистрдан төп регистрга үзе кайта. Шулай итеп, 4нче рәттәге барлык тамгалар сакланды һәм барлык төр чуаш текстларын «карамыйча» басып була. Ул гына да түгел, яңа тамгалар дә өстәлде – апостроф, рим саннары, градус, параграф һ.б. (рәсемне кара).

Клавиатураның 4нче өске рәте татар һәм рус клавиатураларына тәңгәл килә. Аерым чуаш хәрефләрен кайсы клавишка конкрет бәйләү өчен чуаш теле графикасына филологик анализ һәм махсус санаулар үткәрелде. Математик санаулар өчен заманында татар клавиатурасын эшләгәндә билгеләнгән оригиналь эргономик модель кулланылды. Бу математик модель нигезендә текстны ун бармак белән җыйганда бармакларның кирәкле хәрефләргә дөрес эләгүе ихтималлыгын санау һәм шуның нигезендә клавиатураны оптимизацияләү ята. Мондый хисаплауларны башкару өчен хәрефләрнең ешлыгын белү кирәк. Аны табар өчен төрле чуаш газеталары редакцияләреннән алынган, гомуми күләме 2 млн. хәрефле текст файллары кулланылды (бу чама белән бер мең стандарт басма текст бите дигән сүз). Шунысы кызык, санап табылган ешлыклар филологик анализ нәтиҗәсе белән тәңгәл килде. Филология күзлегеннән караганда, чуаш телендә «иң кирәксез» булган дүрт хәреф – **щ,ъ,ж,ё.** Текстларда да аларның ешлыгы иң әз булып чыкты. Әйтергә кирәк, үз вакытында татар телендәге хәрефләрнең ешлыгын исәпләү нәтиҗәсе филологик анализ нәтиҗәсе белән бик үк туры килмәгән иде.

ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК В ИНОЯЗЫЧНОЙ АУДИТОРИИ

М.Б. Хайруллин
(Казанский государственный университет культуры и искусств)

Основные аспекты экономической, социально-политической, культурной и духовной жизни общества связаны с развитием общественных, национальных, в том числе и межъязыковых

отношений, а также с развитием и совершенствованием национальных культур и языков, национальной языковой культуры.

Развитие общества и языков, их взаимосвязи, развитие национальных культур и языков всегда осуществлялось как на основе своих языковых, исконно национальных материальных и духовных ресурсов, так и за счет инонационального, на основе связей и контактов с другими народами. При этом необходимо соблюдать реальное соотношение национального и международного, интернационального, способствующего развитию национального самосознания, сохранению и совершенствованию национальной психологии, национальной специфики, национального менталитета. Здесь немыслим процесс ни искусственного ускорения, ни торможения процесса.

Диалектика национального и интернационального должна быть осуществлена на демократической основе, на основе использования закономерностей развития, взаимообогащения языков и при учете соответствующих объективных, общественно-социальных и лингвистических факторов. Процессу развития наций и их языков должно быть свойственно естественное, органическое сочетание функционального и структурного развития языков как философской категории содержания и формы.

В связи с такой постановкой вопроса и с актуальностью данной проблемы на современном этапе реализации демократической государственной языковой политики, мы остановимся на вопросах преподавания татарского языка в иноязычной аудитории.

Татарский язык – первый государственный язык Республики Татарстан. Его можно было бы, на мой взгляд, назвать одним из неофициальных государственных языков в РФ, так как татары по численности занимают второе место после русских в Российской Федерации. Татарский язык является также языком межнационального общения многомиллионной тюркско-татарской зарубежной диаспоры во многих странах мира: в Турции, США, Германии, Финляндии, Швеции, Китае, Австралии и т.д. Можно сказать, что по своей функциональной значимости и структурному богатству татарский язык занимает в сегодняшние дни свое достойное место среди языков РФ.

При прохождении грамматического, лексико-семантического материала, при освещении разговорных тем, при составлении

диалогов и монологов на уроках родного языка в начинающих группах, а также при написании письменных работ в продолжающих группах, мы регулярно обращаемся как к исконно татарскому материалу, татарским источникам, так и к источникам на русском и других языках, сравниваем языковые явления, грамматические категории в татарском, русском, немецком, английском, арабском, турецком, итальянском и других языках, что способствует нахождению сходств и расхождений в языках, помогает избежанию ошибок в речи русскоязычных студентов. В частности, сравнения делаются в области фонетической, морфологической, синтаксической систем татарского, русского, английского, немецкого и других языков. Например, при объяснении гласных и согласных, при их употреблении в речи можно найти сходства и в области гласных и согласных татарского и английского языков. Имеются сходства и в области образования глагольных времен, залогов, наклонений в татарском, немецком и английских языках. Имеются расхождения и сходства в морфологических и синтаксических категориях татарского, русского, английского и других языков. Так, например, в татарском и английском языках нет грамматической категории рода у отдельных частей речи, а в русском языке такие категории имеются. Падежи имеются и в татарском, английском и немецком языках, но их число, их функции в этих языках совершенно разные.

Когда отдельные языковые сходства и расхождения в языках аргументируются на практических примерах по развитию устной речи студентов, они способствуют интенсивному усвоению лексико-грамматического материала.

Словом, использование национальных и интернациональных компонентов, использование сходств и расхождений в языках на уроках родного языка имеет большое значение как для ускоренного обучения родному языку, так и для установления дружбы между народами, для контактирования многих разноструктурных неблизкородственных языков.

В заключение следует подчеркнуть следующие моменты при изучении татарского языка в иноязычной аудитории: 1) при преподнесении языкового материала нужно создавать соответствующую языковую ситуацию, особенно при составлении диалогов и монологов; 2) следует уметь объяснить нужную для урока

лексику и терминологию на конкретных примерах; 3) нужно уметь отличать исконно татарские и иноязычные слова в татарском языке; 4) необходимо добиваться соответствующего функционального и структурного усвоения языкового материала на уроках в условиях реализации демократической государственной языковой политики.

МЕТОДИКА ПРОВЕДЕНИЯ ПРАКТИЧЕСКИХ ЗАНЯТИЙ ПО ТАТАРСКОМУ ЯЗЫКУ

М.М. Мухаметшина

(Казанский государственый университет культуры и искусств)

В современных условиях изучение и знание татарского языка оказывает благотворное влияние на сближение народов разных национальностей, повышает культурный уровень студентов, позволяет приобщиться к духовным ценностям татарского народа.

Курс «Татарский язык» преподается на факультете МиХИ нашего университета в первом семестре. Основная задача курса – сформировать у студентов умение составлять и произносить простые предложения, читать и понимать тексты на татарском языке, приобрести навыки грамотного письма.

На факультете обучаются в основном русскоязычные студенты, поэтому татарский язык изучается как иностранный. Основное время на практических занятиях отводится разговорной практике. Теоретический материал предполагает изучение различных грамматических форм, он дается в конце занятия и занимает небольшое время.

Основываясь на методике Т.И. Ибрагимова, мы рассматриваем язык как средство описания окружающего мира. Мир состоит из предметов, форм движения. Выделяем структурные классы слов: названия предметов и явлений (существительные, личные местоимения); названия действий и составлений (глаголы); признаки существительных, признаки глаголов и служебные слова.

Студенты приобретают знания, раскрывающие суть определенных ситуаций. Ситуацию можно представить как взаимодействие, либо как состояние предметов и явлений физического мира. Мы говорим о предполагающем соединении теории и практики.

Лингвистическое представление мира, описание ситуации удобнее проводить на основе форм и состояний. В качестве названия ситуации используется именная форма глагола. Разрабатываются систематизированные таблицы глаголов с грамматическими формами. Описание ситуации начинается с построения ее актантной структуры, то есть указания функциональных ролей, участвующих в ней предметов и явлений. К каждой ситуации подбираются актанты: инициатор действия – «агент»; точка, от которой агент начинает свое перемещение – «исходная точка»; точка, в которой агент окажется в результате своего перемещения – «сходная точка»; средство, с помощью которого агент перемещается; цель перемещения и само действие.

В предложениях актанты выражаются с помощью грамматических форм, которые изучаем, проговариваем и закрепляем на каждом занятии.

В процессе практических занятий обучающиеся должны адекватно подражать преподавателю. Важным условием общения на том или другом языке является умение задавать вопросы на этом языке. Студенты должны участвовать в диалогической речи, читать тексты и правильно воспроизводить знакомые им слова и выражения.

СОБЛЮДЕНИЕ ЛЕКСИКО-СТИЛИСТИЧЕСКИХ НОРМ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА В РЕЧИ

Э.В. Павлова
(*Татарский государственный гуманитарно-педагогический университет*)

В настоящее время, когда создаются необходимые условия для овладения богатством национальной культуры, в том числе и литературным языком, вопросы культуры речи приобретают первостепенное значение. К сожалению, сейчас не все литературные произведения и не каждую радио- или телепередачу можно взять в качестве образца нормативного употребления языка. А ведь мы должны стремиться к тому, чтобы наша речь была выразительной, правильной, чтобы не искажался тот язык, на котором мы говорим, думаем. Вопросы защиты, охраны и поддержки литературного языка являются общими для всех сфер. В 1992 году, после принятия

Закона «О языках народов Республики Татарстан», татарский и русский языки были объявлены государственными. Татарский язык стал обязательным для изучения во всех учебных заведениях. В этих условиях, с одной стороны, особую значимость приобретает овладение языковыми нормами; с другой – достаточно остро стоит вопрос качества знаний учащихся. Ведь не секрет, что речь некоторых татар является далеко не образцовой. Сейчас уже можно говорить и о снижении общего уровня грамотности населения, что неизбежно приводит к возникновению проблемы соблюдения лексико-стилистических норм в татарском языке.

Норма – это образец единообразного, общепризнанного употребления элементов языка (слов, словосочетаний, предложений). Языковое явление считается нормативным, если оно отвечает следующим требованиям: соответствует структуре языка, массово и регулярно воспроизводится в процессе речевой деятельности большинства говорящих, находит общественное одобрение и признание. Соблюдение языковых норм в семье помогает научиться правильно говорить на своем языке, а школа и высшие учебные заведения способствуют усовершенствованию этих знаний.

Известно, что наиболее сложной в грамматике татарского языка частью речи является глагол. Многообразие форм грамматических категорий глагола и их значений обладает уникальными возможностями употребления в речи. Поэтому нарушение лексико-стилистических норм в речи особенно часто встречается при употреблении глаголов. В последнее время чаще начали допускать ошибку такого рода: *Концерт тамашачыларыбызга ошадыдыр дип ышанып калам.* В данном случае говорящего интересует не выполнение работы, а его результат, поэтому уместнее использовать вместо формы прошедшего определенного времени форму прошедшего неопределенного времени: *Концерт тамашачыларыбызга ошагандыр дип ышанып калам.* Такие недочеты объясняются многообразием форм времени татарского глагола и разнообразием их смысловых оттенков, что недостаточно принимается во внимание при изучении этой части речи. Невнимание к лексико-стилистическим нормам языка в речи – один из недостатков нашего общества, и это требует пристального внимания и скорейшего разрешения.

«Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел» – гласит народная мудрость.

Именно бережное отношение к родному языку воспитывает нас, наше подрастающее поколение. Поэтому нужно стремиться к тому, чтобы татарский язык приобрел и образцовое употребление, чтобы им не только восхищались, но и захотели изучать его.

ИЗ ОПЫТА ПРЕПОДАВАНИЯ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА В ЭНЕРГЕТИЧЕСКОМ УНИВЕРСИТЕТЕ

Я.М. Ахметова

(Казанский государственый энергетический университет)

Начиная с 1992 года, с принятием закона РТ о языках народов РТ и принятием декларации о государственных языках РТ, преподавание татарского языка и предметов на татарском языке в вузах стало актуальной проблемой. В связи с потребностью подготовки специалистов, владеющих и татарским и русским языками в равной степени, в КГЭУ ввели предметы на татарском языке «Татарский язык и культура речи», «Документная лингвистика на татарском языке», «Общий курс татарского языка», «Старотатарский язык (в арабской графике)» для специальностей «Документоведение и документационное обеспечение управления», «Историко-архивоведение».

Исходя из того, что студенты к нам в университет поступают с разным уровнем владения татарским языком (есть приезжие из других регионов России, СНГ), лекции по данным предметам или ведутся на татарском и русском языках, или предоставляются конспекты лекций на двух языках.

При преподавании предметов на татарском языке в специфичной аудитории (в нашем случае спецификой является техническая направленность вуза и различный уровень владения татарским языком) следует опираться на следующие принципы:

1) дифференцированный подход к каждому студенту и к предлагаемому материалу;

2) использование современных технологий и методов обучения;

3) ведение занятий на двух языках, сопоставляя языковые явления, которые отражают отличия от родного языка студента (в реальном процессе эти сходства и различия так или иначе влияют на усвоение материала);

5) при изучении грамматики – использовать сходные моменты

татарского языка с иностранным языком, ранее изученным студентом (чаще всего – это английский язык);

6) обращать внимание на способы восприятия студентами материала, и выбрать из них наиболее подходящие.

Основные задачи предметов «Татарский язык и культура речи», «Документная лингвистика на татарском языке», «Общий курс татарского языка» – это коррекция грамматических и лексических ошибок, а главное – активизация материала. Многое из того, что выучено раньше (а частично и то, что изучается на этом этапе), должно теперь использоваться при разговоре и письме. А коррекционные курсы – это исправление ошибок в речи, приближение к уровню носителя (который говорит без этих ошибок). В новых экономических условиях Татарстана, когда татарский язык является государственным языком, для студентов специальности «Документоведение и документационное обеспечение управления» вопрос владения практическими навыками составления документов принимает более серьезный характер, так как применение того или иного государственного языка начинается с правильного составления и применения гражданско-правовых документов на этом языке.

РУС ТЕЛЕН БАШКА МИЛЛӘТ ВӘКИЛЛӘРЕНӘ ӨЙРӘТҮДӘ ТУГАН ТЕЛ ЧАРАЛАРЫ

З.М. Мәһиярова

(*Казан дәүләт технология университеты*)

Студентларның белем үзләштерү ихтыяҗын канәгатьләндерүдә, шулай ук аралашу мөмкинлекләрен арттыруда үзенең әһәмияте буенча беренче урында төп тел тора. Татар мәктәбен тәмамлап килгән һәм төп теле татар теле булган студентлар һәр төркемдә бар. Психологик яктан караганда, бәйләнешле сөйләм эшчәнлеге аларның зиһенендә ана теленең грамматик һәм лексик берәмлекләре аша бара. Шунлыктан, югары уку йортында беренче ел укучы татар студентларының рус телендә фикер йөртү, иркен сөйләшү мөмкинлеге чикләнә. Студентның сөйләм телендәге мондый барьерны үзлегеннән үтәргә калдыру адаптация чорын зурайта.

«Рус теле һәм сөйләм культурасы» курсын укыту тәҗрибәсеннән

күренгәнчә, бездә укый торган студентлар рус һәм татар телләрен янәшә һәм билгеле бер дәрәҗәдә бәйләнештә булган телләр итеп кабул итәләр. Чөнки төрле милләт студентлары кече яшьтән үк рус телен аралашу чарасы итеп файдаланган, ә татар телен мәктәптә өйрәнгән, массакүләм мәгълүмат чаралары аша да татар теле билгеле бер дәрәҗәдә аларга таныш. Үзара тыгыз бәйләнештә яшәүче татарлар һәм руслар бер-берсенең гореф-гадәтләрен, дин һәм мәдәният нигезләрен шактый яхшы беләләр. Безнең фикеребезчә, студентлар «Рус теле һәм сөйләм культурасы» курсын өйрәнгәндә болар барысы да исәпкә алынырга тиеш. Билгеле булганча, студентларның тел белү дәрәҗәсе бертөрле түгел. Кайбер татар студентлары, русча белсәләр дә, артык активлык күрсәтмиләр. Махсус фәннәрне укытучы педагогларның да фикере шундый.

Шунлыктан, психологик, лингвистик-педагогик фәннәр өлкәсендә галимнәрнең эзләнү-тикшеренү нәтиҗәләрен өйрәнү, укыту технологияләрен сайлау стратегиясен барлау кирәклеге туа. Гомуми юнәлеш итеп координатив билингвизм алынды. Башка милләт вәкилләренә рус телен өйрәтүдә студентларның ана телендәге белем һәм күнекмәләре рус телендә бәйләнешле сөйләм үсешенең субординатив нигезен тәшкил итә. Бу безгә ике тел өчен охшаш, уртак булган күренешләрне барлап, сайлап, аларны файдалану мөмкинлеге бирде. Болар студентларга үз телендәге грамматик күренешләрне хәтергә төшерергә ярдәм итә. Студент рус телендә язганда яки сөйләшкәндә рус грамматикасы кагыйдәләрендә хата ясый икән, татар телендәге охшаш очракларны искә төшерергә һәм файдаланырга тәкъдим ителә. Тәҗрибә шуны раслый: студентның башлангыч белемнәре субординатив булган очракта, ул бу белемнәрне җиңел куллана ала. Тагын бер мисал: татар теле төп теле булган кайбер студентлар рус теленең орфоэпик нормаларында хата ясый. Рус теле авазларының әйтелеше туган тел орфоэпиясе йогынтысына элэгә. Студентка сөйләмендәге кимчелекләрен төзәтү өчен махсус өстәмә күнегүләр тәкъдим ителә.

Рус милләтеннән булмаган студентларның рус телендә иркен аралашуын тизләтү аларга махсус фәннәрне үзләштерүне тизләтергә мөмкинлек бирә. Анкета нәтиҗәләре дә студентларның танып белү эшчәнлегендә рус теленең коммуникатив әһәмиятен, телләрнең актуальләшүен, аларны үзләштерүгә омтылыш үскәнен күрсәтә.

ЭЧТӘЛЕК

1. **Шакирҗанов Р.Ә.** Татарча югары техник белем бирү учагы 3
2. **Нарбеков А.И.** Татар мәгърифәтчесе Вагыйз Фәтхуллин 7
3. **Зәкиев М.З.** Туган телне саклау һәм үстерүнең әһәмиятле юнәлеше 9
4. **Туктамышов Н.К.** Цели двуязычного образования в современных условиях Татарстана 12
5. **Галимов Д.Г., Даутов Г.Ю., Тимеркәев Б.А.** Югары уку йортларында татар телендә укыту проблемалары 14
6. **Вәлиев Р.Ә.** Милли-региональ компонент – дәүләти принцип 15
7. **Ибраһимов Т.И.** Яңа мәгълүмати технологияләр һәм татар телен нормалаштыру мәсьәләләре 19
8. **Мөхиярова Р.Х.** Исеме җисеменә туры килсен 20
9. **Мозафарова М.Г.** Гомуми урта һәм югары белем бирүче уку йортларында татар телендә укытуда дәвамчанлык 21
10. **Кадыров О.Х.** Язык, история, культура 24
11. **Асылгәрәев Ш.Н.** Россиядә татарча укыту тарихыннан 25
12. **Галимов Д.Г., Даутов Г.Ю., Тимеркәев Б.А**. Татар телен өйрәнүгә ихтыяҗ булдыру чаралары 27
13. **Вәлиев Р.Ә., Вәлиева Л.Ә.** Югары белемне татар телендә тормышка ашыру шартлары 28
14. **Закиров Р.А.** Югары уку йортларында милли-төбәк компоненты 31
15. **Әхмәтов М.С.** Казан дәүләт медицина университетында Татарстан тарихы курсын укытуның үзенчәлекләре 32
16. **Мөбәракҗанов Г.М.** Татар телендәге математик исәпләү кагыйдәләре һәм сөйләм терминнарының логик формалары 34
17. **Галиева Л.И., Галәветдинов И.Г., Хөснетдинов М.З.** Татар телендәге математика терминнары турында 36
18. **Камалов А.З.** Теоретик механаны татарча укытуның кайбер үзенчәлекләре һәм йомгаклары 37
19. **Мәрсәлимов М.Х., Хәкимов Р.Г.** Теоретик механикада атамалар дөньясына күзәтү 39

20. **Шакирҗанов Р.Ә.** «Корылма механикасы» дәресләгенең концепциясен гамәлгә ашыру 40
21. **Рамазанов Ф.Ф., Сәрвәров Ф.С., Таҗмиев Х.К.** Техник югары уку йортларында физика укытуның кайбер проблемалары 43
22. **Гайсин Н.К.** Гомуми физикадан лаборатор эшләр буенча кереш дәрес 44
23. **Газизуллин Р.Г.** Сызма геометрия, инженер һәм компьютер графикасы фәннәрен татарча укыту үзенчәлеге 46
24. **Мортазин Г.Р.** Метрология, стандартлаштыру, сертификацияләү фәнен татарча укыту үзенчәлекләре ... 48
25. **Мифтахова Н.Ш., Курамшин И.Я., Кузнецов А.М.** Татар халкына ана телендә табигый-фәнни белем бирү тарихына заманча караш 49
26. **Газизов М.Б., Кәримова Р.Ф.** Органик химияне татар телендә укытабыз 51
27. **Хисамиев Г.Г.** Югары уку йортлары өчен химиядән татарча дидактик материаллар төзү 52
28. **Камалова З.А., Сөләйманов А.М.** Төзү материаллары фәнендә техник терминнар куллану 55
29. **Мәүлүдова Л.Г.** Ботаника фәнен татар телендә укыту тәҗрибәсе 56
30. **Хөсәенов Ж.А.** География фәнен татар телендә укытканда русча-татарча аңлатмалы-белешмә сүзлекнең кирәклеге һәм аның бүгенге көн өчен әһәмияте 57
31. **Җомагылов Ә.Х.** Хезмәттәге иминлек фәне татар телендә: тел һәм иминлек бәйләнешләре 59
32. **Мортазина С.Г., Мортазин М.Г**. Гамәли дәресләрдә икетеллелек – югары белем бирүне камилләштерү ысулы 61
33. **Мортазина С.Г.** Агрономия факультетында туфрак белеме фәнен ике телдә укыту тәҗрибәсе 62
34. **Нуруллин Р.Г., Нуруллин Р.Р.** Кешенең психологик үзенчәлекләрен исәпкә алып халык педагогикасын заманча куллану 64

35. **Сәмигуллина Л.М.** Татар телен дәүләт теле буларак укытуның кайбер нигезләре 65
36. **Вьюгина С.В.** Булачак дәүләт хезмәткәрләренең сөйләм культурасын үстерү – татар телен өйрәнгәндә коммуникатив компонент 66
37. **Хөрмәтуллина Р.Ш.** Югары уку йортындагы күптеллелек шартларында татар телен һәм әдәбиятын укыту торышы 68
38. **Галләмов Ф.Г.** Татар телен укытуның һәм ике дәүләт телендә белгечләр әзерләүнең торышы турында 71
39. **Шарыпова Н.Х.** Региональ чынбарлыкка нигезләнеп татар телен укыту 72
40. **Харисов Ф.Ф.** Икетеллелек гамәлдә 74
41. **Харисова Ч.М.** Төрле сүз төркемнәренең килеш белән төрләнүе 76
42. **Һадиев Р.М., Хамизова Э.Ш., Һадиев К.Р.** “Тапкыр” web-сайты 77
43. **Биктимирова А.Р.** Күпканаллы телекоммуникация системасына караган терминология 79
44. **Имамов Р.Р., Мифтахов З.М., Вәлиев Р.Р.** Татар теленең аңлатмалы электрон сүзлеге 81
45. **Имамов Р.Р., Мифтахов З.М., Басыйров Р.Ш., Вәлиев Р.Р., Воронина Л.М., Малышев К.А.** Компьютерларны татарча-чуашча локальләштерүче программалар пакеты Jahat™ 82
46. **Имамов Р.Р., Малышев К.А.** Язу җайланмалары өчен чуаш клавиатурасы стандарты проекты 83
47. **Хайруллин М.Б.** Татарский язык в иноязычной аудитории 84
48. **Мухаметшина М.М.** Методика проведения практических занятий по татарскому языку 87
49. **Павлова Э.В.** Соблюдение лексико-стилистических норм татарского языка в речи 88
50. **Ахметова Я.М.** Из опыта преподавания татарского языка в энергетическом университете 90
51. **Маһиярова З.М.** Рус телен башка милләт вәкилләренә өйрәтүдә туган тел чаралары 91

ДВУЯЗЫЧИЕ В СИСТЕМЕ ВЫСШЕГО ПРОФЕССИОНАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ: ПРЕПОДАВАНИЕ ДИСЦИПЛИН НА ТАТАРСКОМ ЯЗЫКЕ

Материалы Республиканской научно-практической конференции

Редакторы:	Шакирзянов Р.А.,
	Нарбеков А.И.
Набор:	Соколова Г.Ш.
Верстка:	Шакирзянов Ф.Р.

ООО «Центр Оперативной Печати»
Лицензия на издательскую деятельность №0311 от 03.08.2000 г.,
Лицензия на полиграфическую деятельность №0195 от 03.08.2000 г.

Подп. в печать 21.03.06	Тираж 150 экз.	Заказ №104931
Усл. печ. л. 6,1	Уч. изд. л. 6,0	Формат 60х84/16

Отпечатано на RISO Бумага офсетная

Отпечатано с готового оригинал-макета
в ООО «Центр Оперативной Печати»
г. Казань, ул Х. Такташа, 105